В. Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты

«Татарстан хәзинәләре» сериясе

# ТАТАР ХАЛЫК УЕННАРЫ

*XX гасырның беренче яртысы татар халык уеннары җыентыгы*
*һәм әлеге уеннарны уйнату өчен методик ярдәмлек*

А. В. Тимирясова редакциясендә

Казан ■ КИУ «ПОЗНАНИЕ» НӘШРИЯТЫ ■ 2022

**УДК 373.2(07):394.3(=470.41)(08)**
**ББК 74.100.57я7+63.521(632)-73я92**
**Т23**

*В. Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты редакция-нәширият советы карары белән бастырыла*

**Проект Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән гамәлгә ашырылды**

**Рецензент:**
*Г. В. Хадиева,* Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы

**Редколлегия:**
*А. В. Тимирясова* (авторлар коллективы җитәкчесе);
*Р. Г. Шәрәфиева* (архивтан материал җыю);
*Г. Я. Дарчинова* (төзү, структурасын булдыру);
*Э. И. Сафина* (русчадан тәрҗемә итү);
*И. А. Фәхретдинова* (уеннарга иллюстрацияләр ясау)

**Т23** **Татар халык уеннары:** XX гасырның беренче яртысы татар халык уеннары җыентыгы һәм әлеге уеннарны уйнату өчен методик ярдәмлек / А. И. Скоробогатова, Р. Ф. Гатауллина, В. В. Тертычная, Д. О. Хәбибуллина, Д. М. Козина, Е. Л. Яковлева, Р. Р. Ханмурзина; А. В. Тимирясова редакциясендә. – Казан : Казан инновация университетының «Познание» нәшрияты, 2022. – 152 б. («Татарстан хәзинәләре» сериясе).

**ISBN 978-5-8399-0763-8**

Методик ярдәмлек татар халык уеннарының – балаларны командада эшләргә өйрәтә, интеллектуаль һәм физик яктан үстерә, җәмәгатьчелек кануннары белән таныштыра торган мәдәни феноменның үзенчәлекләрен ача. Хезмәт XX гасырның беренче яртысында татар журналларында, җыентыкларында басылган һәм әле дә актуальлеген югалтмаган хәрәкәтле, сюжетлы, зиһен сынаш һәм башка уеннарны үз эченә ала. Әлеге уеннарны уку-укыту, тәрбия бирү процессына кертү, балаларның ял вакытларында уйнату, предметлы-уенлы үстерелеш мохите булдыру буенча тәкъдимнәр бирелә.

Ярдәмлек тәрбиячеләр, башлангыч мәктәп укытучылары, педагогика юнәлешендә белем алучы студентлар, балалар клублары җитәкчеләре, мәктәпкәчә, кече һәм урта яшьтәге балаларның әти-әниләре һәм гомумән киң катлау укучылар өчен файдалы булачак.

УДК 373.2(07):394.3(=470.41)(08)
ББК 74.100.57я7+63.521(632)-73я92

ISBN 978-5-8399-0763-8

© Скоробогатова А. И., Гатауллина Р. Ф., Тертычная В. В., Хәбибуллина Д. О., Козина Д. М., Яковлева Е. Л., Ханмурзина Р. Р., 2022
© В. Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты, 2022

# ЭЧТӘЛЕК


СҮЗ БАШЫ .......... 4

КЕРЕШ.......... 7

ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР .......... 10

УЕННАР .......... 11

ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР .......... 11

КҮҢЕЛ АЧУ УЕННАРЫ .......... 29

СЮЖЕТЛЫ УЕННАР .......... 29

ЗИҺЕН СЫНАШ УЕННАРЫ .......... 39

ТАТАР ХАЛЫК УЕННАРЫН УКУ-УКЫТУ ПРОЦЕССЫНА КЕРТЕП ҖИБӘРҮ БУЕНЧА МЕТОДИК РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР.......... 55

БАЛАЛАРГА БЕЛЕМ-ТӘРБИЯ БИРГӘНДӘ ТАТАР ХАЛЫК УЕННАРЫН КУЛЛАНУ БУЕНЧА МЕТОДИК РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР .......... 62

КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ .......... 62

УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ .......... 68

ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕ.......... 75

МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ .......... 86

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТЕ ТАРИХЫННАН АЛЫНГАН ЭЛЕМЕНТЛАР КУЛЛАНЫП, УЕН ПРОЦЕССЫН ОЕШТЫРУ ТУРЫНДА МЕТОДОЛОГИК ЯЗМАЛАР.......... 98

ЭТНОПЕДАГОГИКАДА ФОЛЬКЛОР УЕННАРЫ ЧАГЫЛЫШЫ .......... 107

ТӘРБИЯЧЕНЕҢ УЕННАР ХӘЗИНӘСЕНӘ: УЕННАР ОЕШТЫРУ ӨЧЕН ИДЕЯЛӘР.......... 126

ГЛОССАРИЙ.......... 142

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ .......... 148

ПРЕДМЕТЛАР КҮРСӘТКЕЧЕ .......... 151

# СҮЗ БАШЫ

Татар галимнәре арасында балачакны өйрәнүнең мөһимлеге турында иң беренчеләрдән булып Каюм Насыйри әйткән. Үзенең «Тәрбия китабы»нда «Тәрбия кыйлмак вә тәрбия итмәк дигән сүз фәкать ашатып-эчертеп үстермәк мәгънәсендә генә түгелдер, бәлки ашатып-эчертеп үстермәк, вә баланың холкын, фигылен ислах кыйлмак вә төзәтмәк, вә хайванидан чыгарып инсаният дәрәҗәсенә китермәк, вә тәгълим бирмәк, вә үгрәтмәк, вә укытмак, вә әдәп нигезе бирмәк мәгънәсендәдер»[1], – дип, ул игътибарны балаларны физик яктан да, әхлакый яктан да тәрбияләргә кирәк икәнлегенә юнәлтә.

Тагын бер күренекле галимебез, мәгърифәтче, дин белгече Шиһабетдин Мәрҗани, якыннарының сөйләве буенча, кечкенәдән үк уеннар, күңел ачу чаралары уйлап чыгарырга яраткан. Бу да балаларның фантазиясен һәм күзаллауларын үстерү өчен бик мөһим. Бүгенге тиз үзгәрүчән социомәдәни шартларда үсеп килүче яшь буын өчен бигрәк тә[2].

Балалар өчен хикәяләр, шигырьләр, табышмаклар һәм уеннар басылган «Ак юл» журналының нашире Фәхрелислам Агиевны; «Балалар фольклоры», «Нәниләр шатлана», «Балалар дөньясы», «Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле 100 төрле уен» дигән җыентыклар авторы – танылган язучы һәм фольклорчы галим Нәкый Исәнбәтне; балалар фольклорын фәнни нигездә өйрәнеп, «Балалар фольклоры», «Татар халык уеннары», «Уеннар» кебек егермеләп фольклор җыентыгы бастырган Рәшит Ягъфәровны да балачак белгече дип атап булыр иде.

---

[1] Китаб-әт-тәрбия. URL: https://darul-kutub.com/books/2096/download/pdf (мөрәҗәгать итү вакыты: 09.02.2022).

[2] Шихабутдин Марджани. Сборник статей, посвященный 100-летию Ш. Марджани, изданный в Казани в 1915 г. URL: https://kartaslov.ru/книги/Шихабутдин_Марджани_Сборник_статей_посвященный_100-летию_Ш_Марджани/2 (мөрәҗәгать итү вакыты: 09.02.2022).

«Уен» сүзе татар телендә *уен-көлке, шаяру, күңел ачу, юаныч, музыка, тамаша* дигән мәгънәләрне дә, төрле уеннарны, спектакльләрне һәм гасырлар буена сыналган тәрбия процессын да үз эченә ала. Ул балаларга табигый рәвештә үсәргә, яшьтәшләре белән матур итеп аралашырга, мөгамәлә корырга ярдәм итә. Балаларны уйланырга, эзләнергә, фикер тупларга, берләштерергә, күнекмәләрне, гадәтләрне тормышта кулланырга өйрәтә торган көчле чараларның берсе буларак, уен балалар бакчаларында һәм башлангыч сыйныфларда белем һәм тәрбия бирүдә дә зур роль уйный.

2017 елда Казан инновация университетында рус, татар һәм инглиз телләрендә «Развивающие детские игры татар: по страницам журналов начала XX века» антологиясе басылып чыккан иде. Ул Казан шәһәре, Татарстан Республикасы шәһәр һәм районнары китапханәләрендә табылган татар халкы уеннары хәзинәсен балалар һәм өлкәннәр өчен чын мәгънәсендә өр-яңадан ачты. Китапка 1913 елда «Ак юл» журналында һәм 1928 елда «Уйлап уйнарга уеннар» җыентыгында (авторлары А. Гали һәм М. Әмиров) басылып чыккан уеннар кертелде.

Иң куанычлысы: хәтта цифрлы җәмгыять шартларында да китап шактый кирәкле һәм актуаль булып чыкты. 2019 елның декабрендә, дөньяның 29 иленнән татарлар җыелган «Татарстанның эшлекле партнерлары» XIV форумында, төрле илләргә сибелеп яшәгән милләттәшләребез әлеге китапны балалары һәм оныклары өчен тиз арада сатып алып бетерде. Россиянең төрле шәһәрләрендәге балалар учреждениеләре хезмәткәрләре, шушы басманы сорап, әлегә кадәр университетка мөрәҗәгать итәләр.

Китапка булган зур ихтыяҗ бездә аның тулыландырылган, эшкәртелгән яңа басмасын әзерләп бастыру теләге уятты. 2020 елда хезмәт 1945 елда дөнья күргән «Уеннар. Балалар площадкасы тәрбиячесенә ярдәмлек» җыентыгыннан яңа уеннар белән тулыландырылды. Өстәмә материал буларак, антологиягә әлеге уеннарга әзерләнү һәм аларны уздыру методикасы буенча Казан инновация

университетының педагогик психология һәм педагогика кафедрасы галимнәре коллективы әзерләгән киңәш-тәкъдимнәр өстәлде. Тәрбиячеләргә һәм укытучыларга яңа уеннар оештырырга яки традицион уеннарны үзара катнаштырып, үзгәртеп, төрләндереп кулланырга мөмкинлек биреп, алар уеннар хәзинәсен тагын да баетачак. Моннан тыш, уеннарны хәрәкәтле, сюжетлы, зиһен сынаш, күңел ачу уеннары дигән төрләргә бүлеп һәм балаларның яшь үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, аларның классификациясе эшләнде. Әлеге бүленеш китап белән эшләүне тагын да җиңеләйтә.

Җыентык татар халык уеннарын популярлаштырырга гына түгел, ә аларны хәзерге һәм киләчәк буыннар өчен саклап калырга да ярдәм итәр. Китапта тәкъдим ителгән һәр уен халкыбызның һәм милли мәдәниятебезнең үзенчәлеген чагылдыра. Әлеге уеннар нәниләрне халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, милли мәдәнияте, декоратив-гамәли сәнгате белән таныштыру өчен дә җирлек булыр. Балаларга уеннар ярдәмендә милли тәрбия бирү проблемасын күтәргән әлеге басма тәрбиячеләр, укытучылар, әйдаманнар, психологлар, җәйге һәм кышкы лагерьларда, санаторийларда эшләүчеләр, мәктәпләрнең тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары һ.б. өчен файдалы методик әсбап булып хезмәт итәчәк. Шуны онытмыйк, традицион уеннар баланың иҗади һәм танып белү потенциалын үстерә. Бу исә киләчәктә аңа уңышлы һәм гармонияле шәхес булырга ярдәм итәчәк.

***А. В. Тимирясова,***
*В. Г. Тимирясов исемендәге*
*Казан инновация университеты ректоры*

# КЕРЕШ

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә уку-укыту процессын оештырганда үзәккә бала үзе, аның кабатланмас эчке дөньясы куела. Шуңа күрә дә мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү оешмаларының төп бурычы – баланың яшенә туры килә торган, белем бирү программаларына муафыйк тәрбия ысулларын һәм формаларын сайлау.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар тормышында әйдәп баручы эшчәнлек – уен; уен аша алар әйләнә-тирәдәге чынбарлыкны кабул итә, кешенең эшчәнлеген, шөгыльләрен өйрәнә, соңрак гамәлгә ашырылачак мөнәсәбәт формаларын үзләштерә. Уен баланың танып белү сәләтен үстерә, аңа шәхес буларак формалашырга, сәламәтлеген ныгытырга ярдәм итә. Балаларның хәрәкәткә, танып белүгә, аралашуга булган ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Баланың дөньяга тәнкыйди карашы уеннар барышында формалаша.

Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт стандартларында, бала шәхесе формалашу өчен уен эшчәнлегенең әһәмияте ассызыклана, чөнки уен социаль-норматив яшь характеристикалары (ФДББСның 4.6 пункты) формалашуга йогынты ясый: бала уйнаганда төрле эшчәнлек ысулларын куллана, башкалар белән аралаша, аралашканда, уйнаганда, нәрсә дә булса төзегәндә мөстәкыйльлеккә өйрәнә; үзенә шөгыль таба, шул шөгыль өчен иптәш сайлый, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән үзара мөнәсәбәткә керә, уртак уеннарда катнаша.

Соңгы вакытта мәктәпкәчә яшьтәге балалар күбрәк компьютер яки планшетта уйнауга, мультфильмнар карауга өстенлек бирә. Халык уеннары уйналмый диярлек, чөнки яшь әти-әниләр аларны үзләре дә белми. Шуңа күрә дә балаларны милли хәзинәләребез белән таныштыру, һәрбер баланың милли үзбилгеләнүен саклау мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының аеруча мөһим бурычы булып тора.

Балалар бакчаларында халык уеннары балаларның үз-үзләрен тәрбияләү, белем алу, үзүсеш максатларында кулланыла. Буыннан буынга күчкән татар халык уеннары мәктәпкәчә яшьтәге баланың шәхесен үстерүгә, аның интеллекты, физик һәм әхлакый сыйфатлары формалашуга зур йогынты ясый, тарих һәм халык авыз иҗаты белән кызыксынуга этәрә.

Милли уеннар социаль, иҗтимагый күренешләрне һәм халкыбызның яшәү рәвешен, борынгы бабаларыбызның дөньяга карашын, гореф-гадәтләрен сеңдереп, саклап килгәннәр. Халык уеннары ярдәмендә бала кешеләр белән аралашырга өйрәнә, үзенә кадәр яшәгән буыннарның әхлакый, хезмәт һәм эстетик тәҗрибәсен үзләштерә. Җырлар, биюләр, мәзәкләр, табышмаклар, әкиятләр белән үрелеп баруы исә уеннарыбызны затлы һәм кыйммәтле мәдәни җәүһәр дәрәҗәсенә күтәрә. Димәк, уеннар милләтнең мәдәни мирасын һәм этник тарихын өйрәнүдә дә гаять әһәмиятле чыганак ролен үтиләр.

Халык уеннары педагогика һәм психология фәннәренең традицион чарасы булып тора, кешеләр тормышын, аларның бер-берсе белән мөнәсәбәтләрен, көндәлек мәшәкатьләрен, шөгыльләрен һ.б.ны күз алдына китереп бастыра, балаларны да шул тормышта «яшәргә» өйрәтә. Балаларның рухи яктан бай, физик яктан саусәламәт булып үсүләрендә уеннарның әһәмияте бик зур. Халкыбыз гореф-гадәтләре, йолалары, тормыш-көнкүреше чагылыш тапкан уеннар балаларда үз көченә ышаныч, ярдәмләшү, башкаларның хәленә керү кебек күркәм сыйфатлар тәрбияли. Моннан тыш, бала уен кагыйдәләрен үтәргә, үз эш-хәрәкәтләрен контрольдә тотарга, башкаларның гамәлләрен дөрес бәяләргә һ.б.га өйрәнә.

А. В. Тимирясова редакциясендәге «Развивающие детские игры татар: по страницам журналов начала XX века» (Серия «Сокровищница Татарстана»)[3] китабына нигезләнеп тәкъдим ителгән

---

[3] Развивающие детские игры татар: по страницам журналов начала XX века / под ред. А. В. Тимирясовой. Казань: Казанский инновационный университет, 2017. 148 с. (Серия: «Сокровищница Татарстана»).

әлеге методик рекомендацияләр татар халкында актив кулланылган уеннарны балалар бакчаларында укыту-тәрбия процессына кертеп җибәрү максаты белән эшләнде.

Методик рекомендацияләр мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогларга төрле яшь төркемнәрендә Татарстанның ике дәүләт телендә дә (шулай ук полилингваль балалар бакчаларында инглиз телендә дә) уеннар оештырганда файдалану өчен кызыклы булачак. Балаларның уен эшчәнлеген төрле телләрдә оештыру мәктәпкәчә яшьтәге балаларны алга таба укыту һәм мәдәниятара аралашу өлкәсен киңәйтү өчен тирәнтен әзерләргә, аларның туган телне һәм чит телләрне өйрәнү белән кызыксынуын арттырырга ярдәм итәчәк. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны мавыктыргыч уен эшчәнлеге аркылы тел мохитенә алып керү фольклорны, милли сәнгатьне, гореф-гадәтләрне өйрәнү зарурлыгын күздә тоткан тарихи-мәдәни юнәлешле принципны гамәлгә ашырырга һәм балалардаербөтен полимәдәни дөньяга караш үстерергә булыша.

Методик рекомендацияләрдә «Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә белем бирүнең инновацион программасы» (әлеге белем бирү программасы 2019 елда эшләнгән, анда мәктәпкәчә белем бирү оешмасында балаларны уку-укыту процессын оптималь оештыруның төп компонентлары күрсәтелгән) нигезендә предметлы-уенлы үстерелеш мохитен оештыру буенча күрсәтмәләр, балалар бакчасының төрле яшь төркемнәрендә укыту-тәрбия процессына татар халык уеннарын кертү буенча методик тәкъдимнәр, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларның уен эшчәнлеген оештыру өлкәсендә төп төшенчәләрне системалаштырырга мөмкинлек бирүче глоссарий урын алган.

# ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

 – Кечкенәләр төркеме

 – Уртанчылар төркеме

 – Зурлар төркеме

 – Мәктәпкә әзерлек төркеме

 – Хәрәкәтле уеннар

 – Күңел ачу уеннары

 – Сюжетлы уеннар

 – Зиһен сынаш уеннары

# УЕННАР




*Җыентыкка 1913 елда басылган «Ак юл» журналыннан[4] һәм 1945 елгы уеннар җыентыгыннан алынган татар халык уеннары кертелде[5]. Шул чорның рухын, үзенчәлекләрен сакларга тырышып, уеннар әдәби телгә яраклаштырып бирелде; кайберләренең исемнәре үзгәртелде.*

## АЮ ЯНЫНДА КАРА УРМАНДА

Балаларның берсе – аю, куаклык астында, җиргә сызып ясалган түгәрәк эчендә «өнендә» утыра. Калган балалар гөмбә, җиләк җыялар. Алар төркемнәре белән аю янына баралар һәм түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

*Аю бабай урманында*
*Җиләк, гөмбәләр җыям.*
*Аю өнендә утыра,*
*Балаларга акыра.*

Әлегә кадәр йокымсыраган кыяфәттә утырган аю, бу сүзләрдән соң кыймылдый, киерелә башлый һәм өненнән чыга. Балалар төрле якка йөгерешәләр, ул аларны тота. Тотылган бала аю ролен үти.

Аюның да, балаларның да актыкка сүзне әйтеп бетергәнчегә кадәр йөгерешеп китмәүләрен күзәтергә кирәк.

---

[4] Развивающие детские игры татар: по страницам журналов начала XX века / под ред. А. В. Тимирясовой. Казань: Казанский инновационный университет, 2017. 148 с. (Серия: «Сокровищница Татарстана»).

[5] Уеннар. Балалар площадкасы тәрбиячесенә ярдәмлек. Казан, 1945. 15 б. («Игры. В помощь воспитателю детского сада»).

## «КҮЗ БӘЙЛӘҮ»


Аю бабай урманында
Җиләк, гөмбәләр җыям.
Аю өнендә утыра,
Балаларга акыра.

## ЙОНЛАЧ КӨЧЕК

Уйнаучылардан берсе йонлач көчек була. Ул башын иеп утыра яки ятып тора. Балалар, түбәндәге текстны әйтә-әйтә, акрынлап кына аның янына киләләр:

*Әнә, ята йонлач көчек,*
*Борынын сузган ул ничек?*
*Йоклаганга да охшый,*
*Әллә, юриме мышный?*
*Уятыйк үзен – торсын!*
*Нәрсә булса да булсын.*

Балалар шигырьне әйтеп бетергәннән соң, көчекне сөяләр, аны тотып-тотып карыйлар. Көтмәгәндә көчек күзен ача, сикерә, өрә башлый. Балалар йөгерешеп китәләр, ул аларны тота. Тотылган бала «көчек» була.

## КУЫК

Уйнаучылар тыгыз гына тезелгән түгәрәк ясыйлар. Кулга-кул тотынышып, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, артка таба чигенеп, әкрен генә түгәрәкне киңәйтәләр:

*Өрел куык, зур булып,*
*Тик шартлый күрмә тулып;*
*Һаман да бул син матур –*
*Күперел, кабарып тор!*

Зур, киң түгәрәк ясала. Тәрбияче: «Куык шартлады!» – ди. Балалар кулларын җибәреп чүгәлиләр дә: «Һөп!» – диләр. Шул ук вакытта кул чабып, куык шартлаган тавыш чыгаралар. Аннан соң куык яңадан өрелә.

## БЕЗНЕҢ КАПКА ТӨБЕНДӘ

Уйнаучылардан чебен, озынборын, чикерткә һәм кырмыска сайлана. Калган балалар, әйлән-бәйлән ясап җырлый-җырлый, әле сул якка таба, әле уң якка таба йөриләр. Чебен, озынборын, чикерткә һәм кырмыска башта түгәрәкнең тышкы ягында торалар, аннан соң, акрынлап бер-бер артлы түгәрәк уртасына керәләр һәм җырның эчтәлеген хәрәкәтләр белән күрсәтәләр.

1

*Безнең капка төбендә*  
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә,*  
*Капкабызның төбендә*  
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә.*

2

*Чебен көйләп утыра*  
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә,*  
*Ничек көйләп утыра,*  
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә.*

3

*Озынборын кулында*  
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә,*  
*Скрипка сыздыра,*  
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә.*

4

*Биеп китә чикерткә*  
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә,*  
*Кырмыска тора читтә,*  
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә.*

5

*Кырмыска дус, әйдә әле,*  
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә*  
Бергәләп биик әле,  
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә.*

6

*Биер идем шатланып,*
*Арыдым, аяк атламый.*
*Лә-лә-лә, лә-лә-лә,*
*Арыдым, аяк атламый.*

Беренче, икенче һәм өченче куплетларның һәр юлы икешәр тапкыр җырлана. Дүртенче, бишенче һәм алтынчы куплетларның кушымталары гына «лә-лә...» дип кабатлана.

Икенче куплеттан соң түгәрәк уртасына чебен керә һәм безелди башлый. Өченче куплеттан соң озынборын керә, скрипкада уйнаган хәрәкәтләр ясый. Дүртенче куплетны җырлаганда бии-бии чикерткә килеп керә һәм ишарә белән кырмысканы биергә чакыра. Җилкәсенә авыр әйбер күтәргән кебек, кырмыска килеп керә. Бишенче куплетны чикерткә үзе генә җырлый. Ә алтынчы куплетны кырмыска җырлый һәм бик нык арыган кыяфәт чыгарып, егылган шикелле чүгәләп утыра.

Җырны җырлап бетергәннән соң чебен, озынборын, чикерткә һәм кырмыска түгәрәк уртасында «очалар» һәм балалардан үзләренә алмаш сайлыйлар. Уен кабатлана.

## МӘРЬЯМ ӘБИ МАЛАЙЛАРЫ

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясап басканнар, ә бер бала – түгәрәк уртасында. Балалар түгәрәк буенча йөриләр һәм җырлыйлар:

*Мәрьям әби сыенда*
*Җиде малай утыра;*
*Җидесе дә кашсызлар,*
*Менә шундый башлылар;*
*Колаклары – шундыйрак,*
*Ә күзләре – мондыйрак,*
*Сакаллары – мондыйлар,*
*Җидесе дә шундыйлар.*

«Җидесе дә кашсызлар» дигән сүзләрне әйткәндә балалар туктыйлар һәм алда җырланачак җырларның эчтәлеген хәрәкәтләр белән күрсәтәләр: кулларын колакларына куеп янга сузалар, баш бармак һәм имән бармактан боҗра ясап күзләренә куялар, кулларын баш өстенә куеп, зур баш гәүдәләндерәләр, сакалларын сыйпаган шикелле кыланалар.

Аннары тагын йөри башлыйлар һәм болай җырлыйлар:

*Ашамадылар алар,*
*Карап тордылар һаман,*
*Менә болай, менә болай,*
*Болай иттеләр алар.*

Түгәрәк уртасында басып торучы бала берәр төрле хәрәкәт күрсәтә, ә башкалар аны кабатлый. Аннан соң түгәрәк уртасына башка бала керә, уен шулай дәвам итә.

## ШАЯН КАЗЛАР

Ике бала «каз», ә бер бала «әби» була. Калган балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар һәм тәрбияче белән бергә җырлыйлар. Җырда нәрсә турында җырлана, казлар белән әби шуларны хәрәкәтләр белән күрсәтеп бара.

1

*Авылда бер әбинең*
*Ике казы бар иде,*
*Соры иде берсесе,*
*Ак иде икенчесе.*
*Икесе дә шаян каз,*
*Андый шаян казлар аз.*

2

*Муеннарын сузалар,*
*Бер-берсен уздыралар.*
*Соры иде берсесе,*
*Ак иде икенчесе.*
*Кайсының муены озын,*
*Карагыз әле сузып.*

3

*Су читенә бардылар,*
*Тәпиләрен юдылар,*
*Соры иде берсесе,*
*Ак иде икенчесе.*
*Шаярдылар, йөрделәр,*
*Суга кереп чумдылар.*

4

*Әзли әби – хәлдән тая:*
*– Казларым әллә кая!*
*Соры иде берсесе,*
*Ак иде икенчесе.*
*Каян табарга инде?*
*Югалырлар микәнни?*

5

*Казлар чыкты канаудан,*
*Башларын иде алар,*
*Соры иде берсесе,*
*Ак иде икенчесе.*
*«Ачуланма, әби!» – дип,*
*Торды алар баш иеп.*

Беренче куплетны җырлаганда әби казларны болынга куа. Казлар, алпан-тилпән килеп, бер-бер артлы баралар. Әби утыра, йокымсырый башлый.

Икенче куплетны җырлаганда казлар аллы-артлы торалар һәм муеннарын сузалар. Өченче куплетта алар сызык белән билгеләнгән җиргә – «канау» янына киләләр, аякларын юалар һәм яшеренәләр, канау кырыена чүгәләр. Дүртенче куплетта әби йокысыннан уяна, казларны эзли башлый. Соңгы куплетта шаян казлар яшеренгән җирләреннән чыгалар, әбигә башларын ияләр, әби казларны шелтәләгән, иркәләгән һәм өйгә куган кебек хәрәкәтләр ясый.

Балаларга бу уенны тәкъдим итәр алдыннан җырны яхшы итеп истә калдырырга кирәк.

## ОЧУЧЫЛАР

Балалар – очучылар, ә тәрбияче – аларның җитәкчесе. Очучылар эскәмиядә яки урындыкларда утыралар һәм сигнал көтәләр.

Җитәкче: «Очучылар очарга әзерме?» – дип сорый. Балалар аягүрә басалар һәм: «Әзер!» – дип җавап бирәләр. Җитәкче: «Моторны борып җибәр!» – дип боерык бирә. Балалар моторны борган шикелле куллары белән әйләнешле хәрәкәт ясыйлар. Җитәкче яшел флаг күтәрә: «Очарга мөмкин!» Тәрбияче радио аркылы: «Тыңлагыз. Тыңлагыз! Очучылар, кайтыгыз!» – дигәнгә кадәр самолетлар мәйдан буенча төрле юнәлешләрдә очып йөри.

Очкычлар кайтып туктагач, җитәкче алар тирәли әйләнеп, тикшереп чыга, аннан соң тагын очарга сигнал бирә. Уен кабатлана.

Зуррак (5–7 яшьтәге) балалар өчен бу уенны катлауландырырга да мөмкин. Очучылар бишәр-алтышар кеше булып төркемнәргә бүленә. Һәр төркемнең командиры һәм урнашу урыны сайлана. Җитәкче (тәрбияче) һәр төркемгә бирем бирә, мәсәлән, дошманның кайда булуын белергә, яралылар өчен дару китереп җиткерергә, командованиегә донесение белән пакет илтергә һ.б. Сигнал бирелү белән, төркемнәр күрсәтелгән

юнәлешләргә очалар. Биремнәрен үтәгәч, кире үз урыннарына кайталар. Командирлар очуның нәтиҗәсе турында хәбәр итәләр.

Очучыларның әйләнеп кайтулары алдыннан, аэродромга чыбыклардан яки нарат чикләвекләреннән очкычларның төшү урыннарын билгеләп куярга мөмкин. Һәр яңа очышка яңа бирем бирелә.

## КЫЗЫЛАРМИЯЧЕЛӘР

Балалар кызылармиячеләр, ә тәрбияче – аларның командиры була. Командир кызылармиячеләрне бер-бер артлы тезә һәм команда бирә: «Шагом марш! Бер, ике, өч! Сул аяктан, сул аяктан!» Кызылармиячеләр командирның командасын тыңлап һәм бер-берсе арасындагы ераклыкны дөрес саклап, марш йөриләр. Командир: «Туктагыз!» – ди. Кызылармиячеләр туктыйлар һәм командирдан башка команда көтәләр. Яңа команда бирелә: «Шагом марш!» Кызылармиячеләр күрсәтелгән юнәлешкә таба атлыйлар.

Зуррак яшьтәге балаларга командир төрле-төрле биремнәр бирә ала (урындыкларны кузгатмый гына, араларыннан үтәргә; идәннән 30–40 см биеклектә сузылган бау аркылы сикерергә; урындыкка яки эскәмиягә куелган флагларны узышлый алып йөгерергә һ.б.).

## ИШКӘН БАУЛАР

Уйнаучылар түгәрәкләнеп утыралар. Йөртүче кулына ишкән бау (икегә катлаган яулык, пута) тотып, түгәрәкнең тышкы ягында йөри. Йөртүче, балаларга сиздермичә генә, берәр баланың артына ишкән бауны салырга тырыша. Артка борылып карарга рөхсәт ителми, бауның салынуын-салынмавын белер өчен һәр бала үз артын кулы белән кармалап кына карый ала. Әгәр берәрсе ишкән бауның үз артында булуын сизсә, урыныннан тора да йөртүчегә каршы түгәрәк бу-

енча йөгерә. Бушаган урынга кем беренче килеп җитсә, шул утыра, ә килеп җитешә алмаган бала бау йөртүче була.

Әгәр бала ишкән бауның үз артында булуын сизә алмаса, йөртүче түгәрәк буенча йөреп, сизмәүчегә ишкән бау белән йомшак кына суга һәм: «Сизми калдың, йоклаган!» – ди. Алар түгәрәк буенча бер-берсенә каршы йөгерешәләр, һәрберсе буш урынга беренче килеп җитәргә тырыша.

Бары тик түгәрәкнең тышкы ягыннан гына йөгерергә мөмкин, түгәрәкнең эченнән үтеп чыгарга ярамый.

## КҮЗ БӘЙЛӘҮ

Уйнаучылар түгәрәкләнеп тезеләләр, түгәрәкнең уртасында ике бала басып тора. Аларның берсенең күзен бәйлиләр, ә икенчесенә кечкенә генә кыңгырау бирәләр. Беренче бала кыңгырау тавышы буенча иптәшен тотарга, ә икенче бала ничек кенә булса да тоттырмаска тырыша. Тотылганнан соң түгәрәк уртасына башка балалар керә.

## ТОТ, ТОТ

50–70 см озынлыктагы таякка нык бау белән, тоту өчен җайлы (мәсәлән, бөҗра яки материядән теккән) шар беркетелә. Ялгышлык белән берәр балага бәрелмәсен өчен, таякка йомшак әйбер элү күздә тотыла. Балалар түгәрәккә тезеләләр, тәрбияче түгәрәк уртасында кулына таякны тотып басып тора. Ул таякка эленгән әйберне чиратлап һәр балага якынлаштыра. Таякны әле балаларның куллары тигезлегенә кадәр төшереп, әле югары күтәреп, шаяра-шаяра: «Тот, тот!» – дип кабатлый. Таякка эленгән әйберне бер үк вакытта берничә бала тотып алганда уен күңеллерәк була.

«КҮЗ БӘЙЛӘҮ»



## КУЯННЫ ТОТ

«Кояш куяннары» кояш нурын пыяла аркылы үткәреп сындырудан килеп чыга. Тәрбияче, куянны көтелмәгәндә, бер урыннан икенче урынга күчереп, аны агачка, комга, өстәлгә юнәлдерә. Балалар чиратлашып «куянны» тоталар.

## БЕР-БЕРЕҢӘ ӘЙБЕР ТАПШЫРУ

Уйнаучылар түгәрәкләнеп утыралар, кулларын артка куялар һәм бер-берсенә нинди дә булса берәр әйбер тапшыралар. Йөртүче түгәрәк уртасында басып тора һәм әйбернең кемдә икәнен белергә тырыша. Әйберне алган бала җыр җырлый. Йөртүче аның янына йөгереп килә, ләкин бу вакытта ул инде әйберне икенче уйнаучыга тапшыра. Әйбер кемнән табылса, шул йөртүче була.

## УЗЫШЧЫЛАР

Һәр бала үзенә узышырга пар сайлый. Парлылар бер-бер артлы тезеләләр. Кая кадәр йөгерәчәкләре турында алдан ук сөйләшеп килешәләр (уйнаучылардан 20–25 метр ераклыкта урын сайлана), бу урын флаглар белән билгеләнә. Уйнаучылар: «Бер, ике, өч!» – дип хор белән әйтәләр. Шуннан соң беренче пар флагларга кадәр йөгереп барып, кире әйләнеп кайта. Һәрберсе иптәшеннән узарга тырыша. Кире әйләнеп кайткан балалар артка басалар, аннан соң икенче пар йөгерә.

Балаларның сигнал булганнан соң гына йөгерешеп китүләрен һәм билгеләнгән урынга барып җитүләрен күзәтергә кирәк. Парларны көчләре ягыннан тигез булуларын исәпкә алып сайларга кирәк.

## ҖИТЕЗ БУЛ

Уйнаучыларның һәрберсе чиратлап җитезлек, зирәклек, саклык таләп итә торган нинди дә булса эш үти. Мәсәлән: 1) җиргә сызылган түгәрәк сызык өстеннән йөрергә; 2) кагылмыйча гына, түбән итеп бәйләнгән бау астыннан чыгарга; 3) юл буенча сикереп чабарга; 4) күзне йомган килеш түгәрәкнең уртасыннан үз урыныңа кадәр килеп җитәргә; 5) төймәсенә тотынган хәлдә билгеле бер урынга кадәр сул аякта сикереп барырга; 6) кечкенә тупны агач кашык эченә салып, тупны төшерми тотып барырга; 7) уенчык чиләккә 2–3 стакан чамасы су салып, чайкалдырмыйча, суын түкмичә, тулы көенчә алып килергә; 8) баш түбәсенә фанера куеп, аны кул белән тотмый гына билгеләнгән урынга кадәр илтергә.

Тәрбияче һәрбер балага көченнән килерлек бирем сайлый: зуррак, көчлерәк һәм җитезрәк балаларга кыенракларны, кечкенәләргә, йомшагракларга җиңелрәкләрне бирә. Бер бала биремне үтәгәндә, калган балалар эскәмиягә яки үлән өстенә утырып, аны күзәтеп торалар.

## КОТКАРУЧЫ ТАЯК

Йөртүче, битен куллары белән каплап, стена кырыенда басып яки эскәмиядә утырып, уйнаучыларга арты белән тора. Аның янында коткаручы таяк ята. Йөртүче 15–20 гә кадәр саный. Бу вакытта калган балалар кача. Санап бетергәч, йөртүче күзен ача да таяк белән тукылдата-тукылдата: «Таяк килде, беркемне дә тапмады!» – ди һәм качкан балаларны эзләргә китә. Йөртүче берәр баланы күрү белән, ул да, бала да бер-берсен куып, коткаручы таяк янына йөгерешеп киләләр. Кем беренче килеп җитсә, шул таяк белән тукылдата. Йөртүче таяк янына беренче килеп җитсә, баланың исемен әйтә, мәсәлән, «Коткаручы таяк Мансурны тапты!» – ди. Әгәр эзләп табылган бала таякны беренче килеп тукылдатса: «Коткаручы таяк, коткар мине!» – ди. Йөртүче балаларны

эзләгән вакытта һәрбер качкан бала җайлы моментны сайлап, таяк янына йөгереп килеп коткарылырга тырыша. Йөртүче һәрвакытта да йөгерүче баладан узарга тырыша. Әгәр, качкан баланың иң ахырга калганы таяк янына йөртүчедән алда йөгереп килеп җитсә: «Коткаручы таяк, барыбызны да коткар!» – ди. Мондый очракта йөртүче үз ролен яңадан үти. Таяк янына йөртүче алдан килеп җитә икән, ул вакытта коткарыла алмаган балаларның беренчесе киләсе уенда йөртүче була.

## ЭЗЛӘР БУЙЛАП (уен урманда үткәрелә)

Балалар белән урманда йөргәндә, тәрбияче аларга нарат күркәләреннән яки вак ташлардан тезелгән йолдыз, өчпочмак шикелле фигураларга – «эзләргә» игътибар итәргә куша. Фигураларны алданрак барып мәктәп баласы тезә, тәрбияче бу турыда аның белән алдан сөйләшеп куя. Балалар аны күрмәгән булырга тиешләр. Эзләр балаларны нинди дә булса көтелмәгән бүләк (сюрприз) – уенчык, китап куелган билгеле бер урынга алып бара. Балалар шул урынга килеп җитүгә, ул уенчыклар белән уйнарга яки китапны укырга кирәк.

## ТӨЗӘГЕЧКӘ ТИДЕР

Агачка коршау яки тал чыбыгыннан ясалган боҗра эленә. Балалар чиратлашып шул боҗрага ком тутырылган капчыклар яки нарат күркәләре аталар. Һәр баланың ничә тапкыр төзәгечкә тидерүен санынйлар.

## ТУП ЯШЕРЕШ

Бу уенны урамда гадәттә малайлар уйный. Алдан ук бик зур булмаган чүпрәк яки резин туп әзерләп куелган була. Уйнаучылар үз араларыннан ике командага капитан сайлый. Капитаннар шобага салып яки санап уенны кем беренче баш-

лавын ачыклый. Уйнаучылар парлашалар һәм кем булачакларын үзара хәл итәләр (берсе бер нәрсә, икенчесе башка нәрсә була: берсе алтын, берсе көмеш; я берсе зәңгәр чәчәк, берсе ал чәчәк; я берсе табак-табак акча, берсе су буе бакча һ.б.). Аннан соң балалар парлап беренче капитан янына киләләр һәм аңардан: «алтынмы, көмешме?» – дип сорыйлар. Капитан «алтын» дисә, уен башында кайсы бала «алтын булам» дигән иде, шунысы аның ягында кала, икенчесе башка командага китә. Шулай итеп бөтен уйнаучылар икегә бүленеп бетә.

Бер иркенрәк җирдә уйнау мәйданы – дүртпочмак формасында урын билгелиләр. Аның нинди зурлыкта булуы уйнаучылар санына бәйле. Урынның һәр читенә таш кисәге яки агач кисәге куялар, кыш көне булса, кар тәгәрәтеп дүрт читкә дүрт түгәрәк ясыйлар. Беренче капитан үз ягындагы кешеләрне җыя да, алдан әзерләгән тупны алып, бер кырыйгарак китә. Аларны тыштагылар дип йөртәләр. Калганнары дүрт читле урынның эченә керә, алары эчтәгеләр була. Тыштагыларга билгеләнгән урынның эчке ягына керергә, эчтәгеләргә тышкы якка чыгарга ярамый.

Тыштагылар тупны үз командаларындагы бер балага бирәләр. Иң кызыгы, туп кемдә икәнне белгертмәс өчен, кулына туп тоткан кебегрәк итеп, барысы да кулларын яшереп йөри. Бераз йөргәч, үзендә туп булган кеше, җаен туры китереп, тупны эчтәге берәр кешенең аркасына ыргыта. Бу вакытта, тупны яңадан үзләренә ыргытмасыннар өчен, тыштагыларның барысы да төрле якка йөгереп китә. Тупны яшергән кеше эчтәгеләрнең берсенә туп белән бәрсә, ул туп тигән кеше уеннан чыга һәм читкә китеп тора. Тубы бер кешегә дә тими икән, үзе уеннан чыгарга тиеш була.

Тубы тиеп тә, эчтәгеләрдән берсе тиз генә тупны алып тыштагылардан берсенә сукса, эчтәге туп тигән кеше уеннан чыкмый, бары тыштагы соңыннан туп тигән кеше генә уеннан чыга.

Аннан соң тыштагылар, тагын тупны тидерергә теләп, эчтәгеләр тирәсендә әйләнеп йөри башлыйлар. Тупны ыргытканнан соң эчтәгеләрдән я тыштагылардан тагын берсе утыра. Шулай итеп, уйнаучылар һаман кими, уен эчтә я тышта бер кеше дә калмыйча, барысы да уеннан чыгып беткәнче бара. Бер командадагы кешеләр бар да уеннан чыгып беткәч, уенны яңадан башлыйлар. Кайсы команданың кешеләре алданрак уеннан чыгып беткән булса, бу юлы шул як эчкә керә, икенче як тышта кала. Алар тупны яшерергә читкә китәләр, уен яңадан башлана.

## КАРГА

Бу уенны малайлар да, кызлар да уйный ала. Аны урамда, ишегалдында яки тәнәфес вакытында мәктәптә дә уйнарга мөмкин. Уенда 7–8 кеше катнаша. Уйнаучыларның берсе карга, берсе чебешләр әнкәсе – тавык, калганнары чебешләр була. Чебешләр барысы да әнкәләре артына бер-бер артлы тезеләләр. Карга аларның каршыларына баса да тавыкның чебешләрен тотып алырга тырыша, ә тавык тоттырмау ягын карый. Чебешләр әнкәләре артында торган чакта карга аларны барып тота алмый.

Ул тавыкка: «Кар-р-р! Кар-р-р! Чебешеңне алам, алам, синең күзең болай гына, минем күзләрем болай! Кар-р-р! Кар-р-р!» – ди. «Синең күзең» дигәндә бармагы белән кечкенә генә итеп күрсәтә, «минем күзем» дигәндә, кулларын җәеп, зур итеп күрсәтә. Тавык: «Кыгъ, кыгъ, бирмим, күзеңнән дә курыкмыйм, кыгъ, кыт-кытыйк», – ди һәм койрыгын селкетә-селкетә хәрәкәтләнә башлый. Аның артындагы чебешләр дә тавыкның койрыгы борылган уңайга әле бер якка, әле икенче якка күчәләр. Карга шул вакытта бер чебине эләктереп калырга тырыша. Тота алса, оясына алып китә. Аннан соң яңадан килеп: «Кар-р-р! Кар-р-р! Чебешеңне алам...» – ди. Тавык: «Кыгъ, кыгъ, бирмим», – дип койрыгын болгый башлый. Карга тагын бер чебешне алып китә. Шулай итеп берәм-

берәм тавыкның чебешләрен алып бетерә. Соңгы чебешне алып киткәч, тавык үзе дә карга оясына бара һәм чебешләрен оядан ияртеп чыга. Шуннан соң башка бер бала тавык, икенчесе карга итеп сайлана һәм уен яңадан башлана.

## БУШ УРЫН

«Буш урын» уены бакча яисә матур ишегалдында уйнала. Уйнаучылар алтыдан ким булмаска тиеш. Араларыннан берсен буш урын эзләүче итеп сайлыйлар, калган уенчылар түгәрәкләнеп тезеләләр. Түгәрәкнең эче ике-өч адым хәтле буш булыр. Сайланган буш урын эзләүче, иптәшләренең артыннан әйләнеп йөргәндә, кулындагы бер нәрсә белән уйнаучылардан берәрсенең аркасына барып тамга салыр да, бара торган уңаена китәр (нәрсә белән һәм ничек тамга салуны уен башында хәл итәргә мөмкин). Тамга салынган иптәше дә тиз генә кузгалып каршы ягына йөгерер. Тезелгән түгәрәкнең әйләнәсендә кайсы алда килеп буш урынга туктаса, шул урында калыр, җитешмәгәне буш урын эзләүче булыр.

## ЙӨЗЕК ТАБУ

Бу уенны уйнау өчен ничә бала булса да ярый. Уйнаучылар күбрәк булган саен уен кызыклырак үтә. Янәшә басып, уйнаучы балалар бер түгәрәк ясыйлар. «Йөзек табучы» бу түгәрәкнең эчендә кала. Шуннан соң бер озын җеп алалар да, аны йөзек аша үткәреп, очларын бәйләп куялар. Бу җеп түгәрәккә тезелгән балаларның артыннан үтәргә тиеш. Йөзек яшерүче балалар йөзекне арттан бер-берләренә биреп, елыштырып торалар. Ләкин йөзекне шул хәтле оста елыштырырга, якынайтырга кирәк ки, «йөзек табучы» бу йөзекнең кем кулында икәнен һич тә белмәсен. Шуның өчен, кулларында йөзек булмаган балалар «йөзек табучы»ны юри алдар өчен, кулларын артта селкеткәләп торырга тиеш. Алданып, «йөзек табучы» анда таба караганда, чын йөзекне кулында тоткан бала «йөзек табучы»ның икенче

якка каравыннан файдаланып, кулындагы йөзекне тиз генә янындагы иптәшенә бирергә тиеш. Уен күңелле үтсен өчен, йөзекне бер җирдә генә тотарга кирәкми. «Йөзек тотучы» кем кулында йөзекне таба, шуның белән урыннарын алмашалар, ягъни әлеге «йөзек тотучы» түгәрәккә керә, ә йөзекне кулында тоттырган бала «йөзек тотучы» була.

## АРТ БЕЛӘН УЗЫШ

Уйнаучыларның саны урынның иркенлегенә карап билгеләнә. Уйнаучылар иркен генә бер сафка тезелә. Аларның арка якларында 25–30 адым ераклыкта бер метр чамасы биеклектә нечкә җеп сузып куелган була. Бер кеше команда биргәч, уйнаучылар артлары белән артка таба йөгерә башлыйлар. Кем элек арты белән җепне барып өзә, шул җиңгән санала.

## БЕР АЯК БЕЛӘН КӨРӘШ

Уйнаучылар кулга-кул тотынышып бер түгәрәккә тезеләләр. Уртага ике кеше чыгып, сул куллары белән сул аякларын тотып, уң кулларын артка куялар да, җилкәләре белән бер-берсен этә башлыйлар. Кем иң элек иптәшен җилкәсе белән этеп-төртеп ике аякка бастырса, шул җиңгән санала. Җиңүче белән көрәшергә тәртип буенча тагын икенчеләр чыга. Уйнаган вакытта җилкәдән башка урын белән этәргә ярамый. Бу уенны салкын вакытларда уйнау тагын да файдалы булыр.

Уенда хәйлә – синең белән көрәшүче иптәш җилкәсе белән этәргә килгәндә, янтаеп китәргә дә ярый. Ул тиз ике аякка басар.

## КУЯН

Балалар түгәрәкләнеп утыралар, ә куян түгәрәкнең уртасында тора. Балалар күмәкләшеп җырлыйлар һәм җырның эчтәлеген хәрәкәтләр белән күрсәтәләр. Куян җырның ахырындарак түгәрәк буенча ике аякта сикерә һәм берәр баланың алдына килеп туктый. Шул бала куян була.

*Ап-ак куян утыра,*
*Колагын селкеп тора,*
*Менә шулай, менә шулай,*
*Колагын селкеп тора.*

*Аңа тик тору кыен,*
*Җылыта ул тәпиен,*
*Һоп, һоп, һоп, һоп,*
*Җылыта ул тәпиен,*

*Куян тик торса, туңа,*
*Сикергәли ул шуңа,*
*Һоп, һоп, һоп, һоп,*
*Сикергәли ул шуңа.*

Балаларга җырны алдан өйрәтеп куярга һәм сүзләрне дөрес әйтүләрен күзәтеп торырга кирәк.

## ФАНТЛАР

Уйнаучылар түгәрәкләнеп утыралар. Йөртүче түгәрәкнең уртасында тора. Ул чиратлап һәр бала янына килә һәм: «Сезгә йөз сум акча җибәрделәр, теләгән нәрсәгезне сатып алыгыз, кара белән акны алмагыз, “әйе” һәм “юк” дип әйтмәгез. Нәрсә алырга телисез?» – ди. Алучы үзенә кирәкле әйберләрнең исемен әйтә (мәсәлән, курчак яки күлмәк). Йөртүче нинди төсле күлмәк кирәклеген сорый, ак яки кара төстәгене алырга киңәш бирә. Әгәр алучы уенның шартларын онытып, бу уенда тыелган сүзләрнең берсен әйтсә, ул фант түли (нинди дә булса берәр әйбер бирә). Аннан соң фантлар уйнала: һәр отучыга нәрсә кушылса, ул шуны эшләргә – җыр җырларга, шигырь сөйләргә, күрсәтелгән урынга йөгереп барырга, биергә тиеш була.

Сораулар бирү балаларга кыен булганлыктан, йөртүче ролен башта тәрбияче үти. Уенның кагыйдәләрен аңлаганнан соң балалар үзләре генә дә уйный ала.

## ЭНДӘШМӘ

Барлык уйнаучылар хор белән нинди дә булса берәр такмак яки шигырь әйтәләр. Соңгы сүзне әйткәннән соң бер бала да эндәшергә, көләргә һәм елмаерга тиеш түгел. Әгәр берәр бала түзә алмый көлсә яки берәр сүз әйтсә, ул бала фант түли. Балалар уенның барышында түземлек күрсәтергә тиеш булганлыктан, уен барышында ял итү өчен, фант уйнауны һәрбер уеннан соң үткәрергә кирәк.

## КӨЛДЕРҮЧЕ

Барлык балалар утыралар. Балалар арасыннан берсе, утыручыларның каршыларына баса һәм нинди дә булса берәр көлке әйбер сөйләп яки хәрәкәтләр күрсәтеп, уйнаучыларны көлдерергә тырыша.

Бер бала да көлмәскә тиеш. Көлгән яки елмайган бала фант түли һәм балаларны көлдерергә үзе чыгып баса.

## ТАВЫШСЫЗ МУЗЫКА

Һәрбер уйнаучы үзе өчен бер уен коралы билгеләгән була. Мәсәлән, скрипка, барабан, курай, мандолина, гармун, пианино һәм башкалар. Ул үзеннән һичбер нинди тавыш чыгармыйча, сайлап алган коралында уйнаган шикелле, төрлечә хәрәкәтләр ясый. Уйнаучылардан берсе капельмейстер итеп сайланырга тиеш. Ул бик тырышып оркестр белән җитәкчелек итә. Уен уйнаучылардан берсе көлеп яисә башкача тавыш чыгарып тынычлыкны бозганга кадәр дәвам итә. Көлүчегә җәза бирелергә тиеш.

Бу уенның кызыгы һәм файдасы – көлүдә.

## НИ ӨЧЕН ҺӘМ ШУНЫҢ ӨЧЕН (ЧӨНКИ)

Бөтен уйнаучылар тезелеп утыралар да һәркем үз күршесендәге кешенең колагына «ул шуның өчен...» дигән сүзләрдән нинди дә булса бер җөмлә әйтә.

Уйнаучылардан берсе торып һәрбер уйнаучыга аерым «ни өчен» дигән сүздән башланган сорау бирә. Һәрбер уйнаучы сораучының соравына күршесе әйткән сүз белән җавап бирергә тиеш. Мәсәлән, бер кырыйдан колакка әйтү китте. Бер кеше күршесенең колагына: «Ул шуның өчен, чөнки минем йокым килә», – диде. Бу сүзне алган кеше инде үзенең икенче ягындагы күршесенә бөтенләй икенче бер җөмлә әйтә. Әйтик: «Ул шуның өчен, чөнки яңгыр күктән ява». Моны алган кеше тагын үзе теләгән бер җөмлә әйтә. Шулай итеп һәр кеше башка бер җөмлә белән күршесенең колагына әйтеп чыга. Билгеле инде, сораучы сораулар биргәндә җаваплар туры килми, шуннан кызык туа. Әйтик: «Ник бүген көн суык икән?» – дигән сорауны бирде. Беренче кеше үз колагына әйтелгән җавапны бирә инде: «Ул шуның өчен, чөнки минем йокым килә», – ди. Ә сораучы сорауларын әнә шул бирелгән җавапларыннан ала, – димәк, икенче кешегә биргән соравын ул: «Синең ник йокың килә?» – диярргә тиеш. Икенче кеше:

«Ул шуның өчен, чөнки яңгыр күктән ява». «Яңгыр ни өчен күктән ява?» – «Ул шуның өчен, чөнки...» Шулай китә дә китә.

Бу уенның файдасы – көлүдә.

## ДӨНЬЯДА ЮК ХАЙВАН

Уйнаучылар берничә төркемгә бүленә. Уйнаучының санына карап, аларга ак кәгазь бирелә. Һәрбер төркемнең беренче кешесе, башкаларга күрсәтмичә, шул кәгазьгә кешенең яисә нинди дә булса бер хайванның башын ясый. Кәгазьнең үзе рәсем ясаган урынын бөкләп, муен турысына билге куеп, күршесенә бирә. Күршесе муенын, аркасын ясый. Ул да үз ясаганын бөкләп, икенчегә бирә. Бу кеше дә, икенче кеше кай урында туктап калган булса, шуннан башлап ясалмаган урынын (әйтик, бөтен гәүдәсен яисә аякларын) ясый. Ахырда, бөтен өлешләре ясалып беткәч, кәгазьне җәеп карыйлар. Монда инде бик кызык рәсем килеп чыгарга мөмкин. Мәсәлән, башы кешенеке, муены сарыкныкы, гәүдәсе дуңгызныкы, тояклары бөтенләй башка җанварныкы. Чынлап та, рәсемдә – дөньяда юк хайван!

## ФАНТ УЕНЫ

Гадәттә бу уен башка уеннарга өстәмә буларак, берәр уенны тәмамлаганда яки шул уенның бер кисәге кебек уйнала. Үзен генә уйнаган очракта да бик кызыклы. Тик аны төрлеләндереп һәм җанлы рәвештә алып барырга кирәк. Җәзалары күптөрле һәм кызыклырак булган саен яхшырак. Монда җәза өчен күп нәрсәләр табарга мөмкин: яхшы җырлаучыга – берәр көй җырларга, матур биючегә – биергә, тавышы колакка ягымлы булган кешеләргә – нәрсә дә булса сөйләргә кушарга. Җиңелрәк башваткыч, табышмаклар бирергә, берәр нәрсәне ясап күрсәтергә яисә берәр

спектакльнең кызыклы урынын уйнап күрсәтергә кушарга ярый һ.б. Әйтик, берәүгә һәйкәл булып берничә секунд торырга (көлмичә, селкенмичә таш кебек катып тору; берәр кызыклырак позада булса тагын да яхшы) кушыла, икенче берәүгә сүзсез, ягъни хәрәкәтләр, ишарәләр белән генә танышрак бер шигырь, хикәя сөйләргә әйтергә була. Иң мөһиме, боларның һәрберсен эшләгәндә кыюлык һәм җанлылык күрсәтергә кирәк. Уенның кызыгы бирелгән җәзаларның үзенчәлекле булуында түгел, ә җәзаның кызыклы, җанлы башкарылуында. Бирелгән җәзаларның ничек итеп һәм нинди теләк, дәрт белән үтәлүе зур роль уйный. Мәсәлән, сөйләүне дә төрлечә башкарырга мөмкин бит: кирәкле мәгънәләрне аңлату өчен тавышны үзгәртеп, әмма бернинди дә хәрәкәт ясамыйча һәм киресенчә, тавышны да үзгәртеп, хәрәкәтләр дә ясап һ.б. Биюдә дә шулай ук. Гадәттә, бию җәзасы бирелгән кеше, урыныннан торып, бер-ике тыпырдап чыга да яңадан урынына утыра. Әлбәттә, мондый биюләрне берәүнең дә карыйсы килми. Һәм киресенчә, бөтенләй бии белмәгән кеше дә, башкаларның күңелен күтәрим дип, җанлы рәвештә нинди дә булса берәр бию рәвеше чыгара, кызыклы хәрәкәтләр ясый ала. Һич булмаганда башкаларны көлдерә ала. Сөйләүдә, биюләрдә генә түгел, башка җәзаларны үтәгәндә дә кыюлык, җанлылык күрсәтү кирәк. Шунсыз фант уены күңелсез дә, файдасыз да булачак.

Шулай да, катлаулы, авыр җәзалар сайлаудан, бигрәк тә фант иясенең хәтере калырлык дорфа, күңелсез җәзалар бирүдән сакланырга кирәк. Урынсыз сүз яки гамәл белән берәрсенең күңелен калдырсаң, аның кәефсезлеге башкаларга да тәэсир итеп, уенның кызыгын бетерергә мөмкин.

Кул алышу, кочаклашу, үбешү кебек мәгънәсез, файдасыз җәзалар бирү дә уңышлы түгел. Бу җәзаларның, беренчедән, бернинди кызыгы юк, икенчедән, кеше күп урында үтәлүе күпләрне оялтырга, уңайсыз хәлгә куярга мөмкин.

СЮЖЕТЛЫ УЕННАР

## ПОЧМАКЛАР

Уйнаучылар агачлар янына яки җиргә сызылган түгәрәкләр эченә басалар. Балаларның берсе почмаксыз кала. Ул уйнаучыларның берсе янына килеп: «Тычкан, тычкан, почмагыңны сат!» – ди. Бу риза булмагач, ул икенче «тычкан» янына бара. Бу вакытта калган балалар тиз генә урыннарын алмашалар, ә йөрүче шул арада йөгерүчеләрдән берсенең урынын алып калырга тырыша. Әгәр ул урынны ала алса, почмаксыз калучы бала йөрүче була һәм уен яңадан башлана. Әгәр йөрүче почмакны озак вакыт ала алмаса, тәрбияче: «Мәче килә!» – дип кычкыра. Шул вакытта бар да берьюлы уңга таба түгәрәктән түгәрәккә йөгереп күчәләр, ә йөрүче берәрсенең урынын алып калырга тырыша.

## ӘТӘЧ КЫЧКЫРДЫ

Бу уенны кызлар яки малайлар гына да, кызлар һәм малайлар бергә дә уйный ала. Гадәттә ул өй эчендә уйнала. Уйнаучылар күбрәк булган саен яхшырак. Алдан ук уйнаучылар саныннан бергә ким (мәсәлән, ун уйнаучы булса, тугыз) урындыклар әзерлиләр һәм аларны түгәрәкләп берсен эчкә, берсен тышка каратып тезәләр. Бер җирдә кеше йөрерлек «капка» калдыралар. Уйнаучылар урындыкларга берсе түгәрәкнең эченә, берсе тышка таба карап утыралар, урындыкларның саны уйнаучылар санына караганда бергә ким булганлыктан, бер уйнаучыга урындык җитми кала. Урындыксыз калган бала капкадан керә дә иң кырыйда утырган баланың кулын-

нан тота. Бу бала эчкә карап утырган икенче баланың кулыннан тота, анысы өченче бала кулыннан тота. Шул рәвешле эчкә карап утырган балалар берсе артыннан берсе тагылып бетәләр. Аннан соң түгәрәктән тышка таба карап утырган балалар да берсе артыннан берсе куллары белән тотышып тагылалар. Барысы да тагылып беткәч, алдан бара торган бала, тотынышкан башка балаларны ияртеп, өйнең бер бүлмәсеннән бер бүлмәсенә алып кереп йөри һәм уйный торган бүлмәдән ераграк киткәч, кинәт кенә «Кикрикүк» дип кычкыра. Балалар «Әтәч кычкырды, әтәч кычкырды», – диеп урындыклар куйган бүлмәгә йөгерәләр һәм урындыкларга утырып калырга ашыгалар. Урындыклар саны уйнаучы балаларныкыннан бергә ким булганга, бер балага тагын урындык җитми кала. Урындыксыз калган балага моңа кадәр уйналган уенда алда йөргән бала бер җәза бирә (яттан шигырь сөйләргә, җырларга, эт я мәче булып кычкырырга һ.б.). Урындыксыз бала, җәзасын үтәгәч, уен башындагы кебек, башка балаларны үз артыннан ияртеп, бүлмәдән алып чыга. Тагын бер бүлмәдән бер бүлмәгә йөриләр. Алдагы бала «Кикрикүк» дип кычкыргач, тагын урындыклар янына йөгерешергә тотыналар. Уен шулай дәвам итә.

## ХАЙВАННАР АВЫЗЫННАН

Ат кешнидер: «Миһа-һа...
Безнең Әхмәт, – ди, – кайда?»
Кәҗә әйтә: «Мә-ә-ә...
Әхмәт китте мәктәпкә!»
Сыер мулый: «Му, му...
Әхмәт яхшы укыйму».
«Уау.., уау, – диеп эт өрә, –
Безнең Әхмәт күп белә!"
Кычкыра үрдәк: «Бәк-бәк-бәк,
Күп белсә, аңар рәхмәт!»

Күгәрченнәр авызыннан:
Гөлдер, гөлдер...
Бигрәк чибәр, кемдер бу?
Тарап үргән чәчләре
Өсте, башы бик ару.
Гөлдер, гөлдер...
Бу әдәпле кыздыр бу,
Мәктәп атлы бакчада
Чәчәктер бу, гөлдер бу!

## МАЭМАЙ ПОЧМАКТА

Бу уенга катнашучы балаларның саны уен бүлмәсендәге почмаклар саныннан бергә артык булырга тиеш. Ягъни, уен бүлмәсендә дүрт почмак булса, уйнаучылар бишәү булырга тиеш.

Уйнаучыларның берсе маэмай (яки мәче) булып, бүлмә уртасында кала. Калган балалар һәрберсе бер почмакта урын ала. Болар инде тычканнар булалар. Тычканнар үз почмакларында торган вакытта маэмай аларга тимәскә тиеш. Әмма тычканнар вакыт-вакыт йөреп, урыннарын алмашып торалар. Нәкъ менә шул урын алмашкан чакта берсен маэмай тотып алырга тырыша да инде. Шуңа күрә, урыннарын алмаширга җыенган тычканнар иң элек бер-берләренә ишарә ясап (күз белән, кул белән яки тамак кырып, йөткергәләп), «әйдә урыннарны алмашабыз», – дигәнне аңлатырга тырыша. Шулай алдан серләшеп алганнан соң, тычканнар үз почмакларыннан чыгалар да берсе икенчесенең почмагына таба чаба башлыйлар. Урын алмашкан чакта маэмай кайсы тычканны тота, алга таба шул тычкан маэмай булып уйнаячак. Ә әлеге маэмай буш почмакны алып, тычкан була.

## БҮРЕ

Бу уенны уйнар өчен ничә бала булса да ярый. Уйнаучыларның берсе бүре, икенчесе көтүче, ә калганнары сарыклар була.

Бүренең урыны өстәл, караваt астында яки мич артында. Шундый урыннарның берсендә әлеге бүре качып тора. Уен бүлмәсенең бер очында сарык көтүе, икенче очында – көтүче. Бервакыт көтүче үзенең сарыкларын: «Әйдәгез, өйгә китик инде», – дип чакыра. Моңа каршы сарыклар: «Өйгә бара алмыйбыз, бүредән куркабыз», – дип җавап кайтаралар. Көтүче аларга: «Курыкмагыз, бүре китте инде», – ди. Шуннан соң

«БҮРЕ»



сарыклар чабышып килә башлыйлар, яшеренеп торган бүре, урыныннан чыгып, сарыкларның берсен тотарга тырыша.

Уен һәрбер сарыкны аерым-аерым тотып бетергәнче дәвам итә.

## ЯҢАЧА МӘЧЕ ҺӘМ ТЫЧКАН УЕНЫ

Барлык уйнаучылар солдатлар кебек берничә рәт булып сафка тезеләләр, берсенеке берсенекенә тияр-тимәс итеп кулларын сузалар. Сафта торган кешеләр арасыннан ике уенчы чыгып, берсе мәче, берсе тычкан була. Мәче тычканны куа башлый. Инде мәче тычканны тотам дигәндә генә уенны оештыручы «уңга» яки «сулга» дигән команда бирә. Уйнаучылар кулларын сузган килеш команда буенча уңга яки сулга борылып торалар. Алар борылганнан соң мәче белән тычкан әллә кайда аерылып кала. Мәчегә дә, тычканга да күтәрелгән куллар аша йөрергә ярамый, алар иркен булган рәт араларыннан гына йөри ала. Мәче тычканны тота икән, бу уенчылар икесе дә сафка баса, башкалар мәче-тычканга әйләнә. Уенны никадәр кызу алып барсаң, тычкан белән мәче никадәр кызу йөрсә, уен шуның кадәр җанлырак, кызыграк үтә.

## ТАБЫШМАКЛАР

Ике төркемгә бүленеп, балалар чиратлашып бер-берсенә табышмак әйтәләр. Беренче төркем балалар алдан үзара сөйләшеп табышмакларга җавап табарга тиешле төркем янына киләләр.

– Исәнмесез, балалар!

– Исәнмесез.

– Сез кайда булдыгыз, кырдамы? (Урманда, бүлмәдә, урамда.)

– Сез нәрсә эшләдегез? Уйлап табыгыз әле.

Балалар уйлаган нәрсәләрен ишарә белән күрсәтәләр (мәсәлән, кавалеристлар ничек атта чаба, кызылармиячеләр ничек ата, трактор ничек бара һ.б.).

Табышмакларны тапканнан соң балалар йөгерешеп китәләр, ә табышмакларны табучылар аларны тотарга тиеш. Тотылган балалар тотучылар төркеменә күчә. Аннан соң рольләр алмашына, табышмакка җавап тапкан балалар табышмак әйтүче була. Әгәр табышмакка җавап таба алмасалар, яңадан табышмакларны беренче төркем әйтә.

## РӘСЕМДӘ НӘРСӘ СУРӘТЛӘНГӘННЕ БЕЛ

Балаларга төрле әйберләр – хайваннар, үсемлекләр сурәтләнгән картинкалар бирелә. Янында утыручыга күрсәтми генә һәрбер бала үзенең рәсемен карый. Аннан соң балалар, бер-бер артлы, исемен әйтмичә генә, картинкада сурәтләнгән әйберне аңлаталар. Калган балалар рәсемдә нәрсә сурәтләнгәнне аңларга тиеш.

## КАЧЫШ-ТАБЫШ

Уйнаучыларның саны күпме булса да ярый. Бу уенны уйнар өчен качарга да, кайда да булса яшеренергә дә кирәк түгел. Табучыга да чабып йөреп эзләргә туры килми. Уйнарга дип утырган балаларның берсе үз алдына уйлый да, иптәшенә карап: «Я, тап, мин качтым», – ди. Үзе шулвакыт качкан урынын уйлый. Мәсәлән: «Казанга качтым», «Мәскәүгә качтым», «Мөхәммәдия мәдрәсәсенә качтым», «Сөембикә манарасына качтым» һ.б. Эзләүче, табарга җиңелрәк булсын өчен, качкан балага төрле сораулар бирә. Мәсәлән, «Еракмы качтың, якынмы качтың? Үз шәһәребездәме, чит шәһәрдәме?» Шулай итеп уен сузыла.

## НЫК УЙЛА

Уенда утызга якын кеше катнашып, уйнаучылар тигез итеп ике төркемгә бүленәләр. Өстәл өстенә 15–25 кә якын төрле вак нәрсәләр куела. Күренеп тормасын өчен, өсләренә яулык кебек берәр нәрсә ябыла. Уенны алып бару өчен бер аерым кеше сайланып, ул өстәлгә куелган бөтен нәрсәләрнең исемнәрен язып ала. Өстәлгә куелган нәрсәләрне уенны алып баручыдан башка берәү дә белмәскә, күрмәскә тиеш. Алып баручы, әйберләрнең өсләре ябулы килеш өстәл янына ике төркемне дә чакырып алып: «Тыныч булыгыз», – дип әйтә дә, әйберләрнең өстен ачып, күңеленнән бишкә кадәр саный һәм тиз генә кире ябып куя. Төркемдәге һәр кеше хәтерләрендә калган нәрсәләрнең аерым исемлекләрен төзеп, бер-берсенеке белән чагыштырып карыйлар. Кайсы төркем күбрәк яза, шул җиңгән булып санала.

«КАЧЫШ-ТАБЫШ»



## МУЗЫКАНЫ НЫК ТЫҢЛА

Бу уенны берәр эштән арып туктаганнан соң үткәрү аеруча яхшы. Уйнаучылар тезелешеп урындык, эскәмияләргә утыралар (уенны яланда үткәргәндә җиргә утырырга да була). Бер уйнаучы читкә китә һәм башкаларга карамый тора. Бу вакытта уйнаучылар үз араларыннан берәрсенең өч әгъзасының берсен (мәсәлән, кулын, аягын яки башын) уйлап куялар да, бергәләп җырлый башлыйлар (гармун яки башка музыка коралларында уйнарга да була).

Читкә киткән кеше, уйнаучылар янына килеп, һәрберсе яныннан әкрен генә үтеп йөри башлый. Билгеләнгән кешегә якынлаша башласа, җырлаучылар җырларының тавышын әкрен-әкрен генә түбәнәйтә башлыйлар. Әгәр дә ераклаша башласа, киресенчә, җыр тавышын күтәрәләр. Билгеләнгән кеше янына килеп җитсә, бөтенләй түбән тавыш белән җырлыйлар. Шулай итеп, түбәнәйгән тавыш буенча билгеләп, кешесен таба. Хәзер инде аңа уйнаучылар әлеге кешенең кайсы әгъзасын сайлаган икәнне белергә кирәк. Моның өчен ул әлеге кешенең югарыда күрсәтелгән өч әгъзасының берсенә генә (үзе теләгәненә) кулын сузарга тиеш. Әгәр дә билгеләнгән әгъзага кулын әйтеп тигезсә, утырган кеше кул чаба да, үзе аның урынына читкә китә, элеккеге кеше кебек җыр яки музыка тавышы буенча эзли башлый. Әгәр дә эзләүче билгеләнмәгән кешегә кул сузса, утырган кеше аның кулына сугып җибәрә. Эзләүче яңадан эзли башлый. Инде билгеләнгән кеше булып та, билгеләнгән әгъзасына кулын сузмаса, утыручы эзләүчене сызгырып ирештерергә тиеш.

## КОМ — СО — МОЛ

Уйнаучылар түгәрәкләнеп утыралар. Алып баручының кушуы буенча, бер кешедән башлап, кеше аша (1, 3, 5, 7...) һәрбер уйнаучы «комсомол» дигән сүзнең берәр кисәген тиз генә әйтеп чыга. Мәсәлән: беренче кеше «ком», өченче кеше «со»,

бишенче кеше «мол», җиденче кеше тагын «ком» дип әйтәләр. Ялгышкан кешеләр уеннан чыга бара. Икенче мәртәбәдә бу сүзләрне 2, 4, 6, 8... нче кешеләр әйтергә тиеш. Бу уен түгәрәктә ике генә кеше калганчы бара, шулар җиңгән булып санала.

Уенда башка сүз кулланырга да була.

## БЕЛМӘСӘҢ, ҮЗЕҢ ҖЫРЛАРСЫҢ

Уйнаучылар, яттан булмаса да, укып яки ишетеп 10–12 шигырь, җыр белергә тиеш. Шигырь, җырлар озын булмыйча, шуларның берәр куплеты гына алынып, тәртип буенча тезелгән кеше саен берәр сүзе бүленеп бирелә. Сүз ияләре үзләренә бирелгән сүзләрне яхшы белергә тиеш. Уйнаучылар үзләре арасыннан бер кешене читкә җибәрәләр дә, сүзләрне үзара бүләләр. Киткән кеше кабат яннарына килә дә, команда булгач, уйнаучылар бар да бертоташтан тиз генә шул сүзләрне әйтәләр. Тыңлаучы кеше нинди җыр, шигырь икәнен әйтеп бирергә тиеш. Әгәр дә белмәсә, җәза урынына үзе берәр җыр җырлый яки берәр нәрсә сөйли. Белсә, бу бурычны кычкыручылардан берәр кеше үти. Хәтергә сеңеп калсын өчен, бу уенны күмәкләшеп җыр, шигырь китаплары укыганнан соң үткәрергә була.

## ТИЗ УЙЛА

Әлеге уенны уйнар өчен алдан ук кечкенә катыргы кисәкләренә аерым-аерым төрле хәрефләр язып әзерләп куела (күбрәк булган саен яхшырак). Уйнаучылар һәммәсе дә җидешәр хәреф алып, нинди хәрефләр икәнлеген карамый торырга тиешләр. Уенны оештыручы кеше команда биргәннән соң, бар да тиз генә шул хәрефләрдән берәр сүз төзеп, аңа китереп күрсәтергә ашыгалар. Кем беренчерәк китереп күрсәтсә, шул җиңгән булып санала. Кем 20 секундта китереп өлгертә алмый, берәр төрле җәза, бирем үтәргә тиеш (нинди җәза буласын уен башында ук хәл итеп кую яхшы).

Уенда әшәке сүзләр кабул ителми. Сүз төзегәндә артык хәрефләрне кулланмый калдырырга да ярый.

Бу уенны укырга, язарга өйрәнүчеләр арасында үткәрү тагын да файдалы һәм кызыклы булыр.

## КҮП МӘГЪНӘЛЕ СҮЗЛӘР

Җирәбә ташлап яисә үзе теләгән бер уйнаучыны, мондагы сөйләшүләр ишетелми торган урынга – икенче бүлмәгә чыгарып җибәрәләр. Шул арада үзләре күп мәгънәле бер сүз билгелиләр һәм һәркем үзенә шул сүзнең бер мәгънәсен сайлап ала. Мәсәлән, «ат» сүзе. Моның бездә өч төрле мәгънәсе бар: 1) ат – җигеп йөри торган хайван; 2) ат – атарга кушу; 3) ат – исем. Башка бүлмәдәге кеше керә дә уйнаучыларның һәрберенә аерым-аерым өчәр сорау бирә башлый. Шул җаваплар буенча билгеләнгән сүзне табарга кирәк. Әмма уйлаган сүзне бер тапкыр гына әйтергә ярый. Бер әйтүдә дөрес әйтмәсә, уйнаучы яңадан чыгып китә.

Табучы кемнең җавабыннан соң уйланган сүзне әйтә, алга таба шул җавап биргән кеше «табучы» булырга тиеш. Аңа инде башка сүз билгеләнә.

*Уенның шарты:* сорауларны да, җавапларны да кызу алып бару. Кем җавап биргәндә буталып кала яисә туктап тора, аңардан фант алалар. Сораулар кинәт кенә әле бу башта, әле теге башта утырган кешеләргә бирелсә, уен кызыграк барыр. Әмма иң элек һәр кешегә өч сорауның өчесен дә биреп бетерергә кирәк.

Сораулар күптөрле булырга һәм төрле кешегә төрлесен бирергә мөмкин. Әйтик:

1. Син уйлаган нәрсә кайда була ул?
2. Син үзең аны яратасыңмы?
3. Нишләтәләр аны яисә ул үзе нишли?

Җаваплар уйланган мәгънәгә карап кына булырга тиеш.

Мәсәлән: табучы кеше тарафыннан югарыдагы өч сорау бирелгән булса, «ат – хайван» мәгънәсен билгеләгән кеше:

1. Төрле вакытта, төрле урында (йортта, урамда, яланда, юлда, оясында).

2. Яратам, яратмаучылар булырга мөмкин (һәм киресенчә).

3. Хезмәт иттерәләр, хезмәт итә.

«Ат – атарга кушу»ны билгеләүче:

1. Һава дулкынында (табучының соравына карап, «берәүне үтерергә теләгәндә» кебек җаваплар бирергә мөмкин).

2. Яратмыйм (арттырырга мөмкин: «эшләргә дә, тыңларга да яратмыйм» яисә «сугышта дошманга каршы барганда яратам»).

«Ат – исем» мәгънәсен сайлаучы:

1. Барлык кешедә, барлык нәрсәдә, ансыз нәрсә юк.

2. Яратканнарым бар, бар яратмаганнарым (яисә, «яратам, үземнекен бигрәк тә, уйнаучылардан берсенең исемен әйтеп» аныкын яратам, моныкын юк кебек җаваплар белән мөмкин).

3. Һәркем үзе белән йөртә, һәрнәрсә үзендә саклый, хуҗасына ябышып йөри.

Менә шуңа охшаш җаваплар.

Ә теге күп мәгънәле сүзләрне табуы җиңел булыр.

Мәсәлән:

«Кара» – моның өч мәгънәсе бар.

«Яшь» – ике.

«Табак» – ике.

«Бу» – өч.

## ИГЕЗӘК ИҖЕКЛӘР

Моны уйнау «Күп мәгънәле сүзләр»не уйнауга охшаган. Тик монда нинди сүз икәнлеген аңларга тиешле уйнаучы өчен «күп мәгънәле сүзләр» урынына «игезәк иҗекләр» сайлана. Мәсәлән, «карчык» сүзе ике иҗектән тора. Беренче иҗек – «кар», икенче иҗек – «чык» һәм әлеге иҗекләрнең

һәрберсенең үз мәгънәсе бар. Уйнаучылар ике төркемгә бүленәләр. Әйтик, уйнаучыларның берсе сүзнең беренче иҗеген («кар»ны), аның янәшәсендә утыручы икенче иҗекне («чык»ны) ала да, һәрберсе үзе алган иҗекнең мәгънәсенә туры китереп, табучы биргән сорауларга җаваплар кайтара. Монда да «күп мәгънәле сүзләр»дәге кебек үк, бер кешегә өч төрле сорау һәм өч җавап. Калган уйнау рәвешләре дә «Күп мәгънәле сүзләр»дәгечә.

Җаваплардан бик аңлашылмыйча, табучы кеше тиешле сүзне һаман әйтә алмый торса, уенны өч төрле җавапчыларга бүлеп уйнарга мөмкин. Ул менә болай. Җавапчылардан беренче кешегә табарга алынган сүз иҗекләргә бүленмичә бөтен көенчә бирелә һәм сүз бөтен көенчә нинди мәгънәгә ия булса, җавапчы шуңа карап җаваплар бирә.

Әйтик, табар өчен «күлмәк» сүзе алынган. Беренче кеше әнә шул «күлмәк»кә карата җаваплар бирә. Ә аның күршесендәге икенче һәм өченче кешеләр башта күрсәтелгәнчә иҗекләргә бүлеп алалар (күл, мәк).

Әлбәттә, моның шулай өчкә бүленгәнен һәм кемдә сүз бөтен мәгънәсе белән, кемдә беренче, кемдә икенче иҗек икәнен табучыга әйтергә кирәк.

Шушы ук уенны «җилемле сүзләр»гә (парлы сүзләргә) алыштырып уйнарга мөмкин. Җилемле сүзләр: егет-җилән, күрше-күләм, бала-чага кебекләр. Бу очракта, беренчедән, парлы сүзләрне «Игезәк иҗекләр» дәге кебек бөтен килеш алып булмый, икенчедән, «җилемле сүзләр»нең һәрберсе аерым-аерым берәр мәгънәгә ия булырга тиеш. «Кыз-кыркым» кебек беренче сүз (кыз) бер мәгънә аңлатып та, икенчесе (кыркым) бер мәгънә дә аңлатмый торган яисә бер төрле генә аңлап һәм аңлатып булмый торган сүзләрне алырга ярамый. «Игезәк иҗекләр»не күп табарга мөмкин. Мәсәлән, чүлмәк (чүл – мәк), аккош (ак – кош), башкорт (баш – корт).

## ӨЧ СҮЗ

Уйнаучылардан берәү «башлык» булып билгеләнә һәм ул һәрбер кешегә берәм-берәм өч төрле исем – сүз әйтеп чыга. Һәркем үз чиратында үзенә бирелгән өч исемнән бер җөмлә төзергә тиеш. Бу җөмлә төзү эше бик үк җиңел булмаганлыктан, җавап бирүне артык ашыктырырга кирәкми. Шул ук вакытта бик озакка сузарга да ярамый. Билгеле вакыт эчендә җавап бирә алмаган яисә үзенә бирелгән сүзләрнең өчесен дә кулланмыйча җөмлә төзегән кешегә җәза бирелергә – фант алынырга тиеш. Әйтик: берәүгә «каләм», «класс», «кара» дигән өч исем сүз бирелде. Ул бу сүзләрдән «Мин каләмемне дә, карамны да алып класска кердем» яисә «Мин каләмемне класска алып кердем, ә карам онытылып калган» кебек җөмләләр төзи ала.

Бу уенның кызык ягы шунда: кайвакытта җөмләләр бик көлкеле килеп чыга. Мәсәлән, берәүгә «карандаш», «балта», «чиләк» сүзләре бирелсә, аңа «Мин карандашымны балта белән очладым да, чиләккә ташладым» диюдән башка юл юк.

Иң мөһим шарт – җөмләнең мәгънәсе булырга тиеш. Әйтик, шул ук «карандаш», «балта», «чиләк» сүзләреннән «Балтаны карандаш белән саплап, чиләкне яргаладым» дигән җөмлә төзегән очракта, ул җөмләне мәгънәле һәм дөрес дип булмас иде. Чөнки моның булуы мөмкин түгел. Андый җөмләләр төзегән кешегә җәза бирелә.

## ОЧА

Уйнаучылар түгәрәкләнеп утыралар. Бер кырыйга ялгызы «башлык» утыра. Ул бөтен уйнаучылар күренерлек урынга утырырга тиеш. Уйнаучылар кулларын тезләренә куялар. Башлык бер-бер артлы төрле хайваннарның, кошларның, кешеләрнең, кыскасы, үзе теләгән нәрсәләрнең исемнәрен тезеп китә һәм һәрбер исем артына «оча» дигән сүзне куша. Әгәр башлык чынлап та оча торган нәрсәнең исемен әйтсә,

һәрбер уйнаучы кулларын иңбашларына кадәр күтәрергә һәм тиз генә төшерергә, әгәр башлык очмый торган нәрсәнең исемен әйтсә, тик утырырга тиеш.

Кирәкле вакытта кулларын күтәрмәгән яисә тиешсез урында күтәргән кеше башлыкны алмаштыра.

Сүзләрне тизрәк әйткән саен уен кызыграк килеп чыга.

## ҖИЛӘК-ҖИМЕШ БАЗАРЫ

Уйнаучылар түгәрәкләнеп утыралар. Бер уйнаучы һәр кешедән «Син нинди җиләк-җимеш сатасың»? дип сорап чыга. Барысы да алдан уйлап куйган җиләк-җимешнең исемен әйтәләр. Бер үк җиләк-җимеш исемен ике яисә өч кешегә бирергә ярамый. Уйнаучылар нинди җиләк-җимеш сайлауларын яхшы истә калдырырга тиеш. Уен башлана. Кырыйдан берәү: «Алма сатам, алма сатам. Күршем минем хөрмә сата», – ди. Кемгә хөрмә бирелгән булса, шул кеше хәзер үк эләктереп алып, «хөрмә сатам» дип кычкырып китәргә һәм үзенекеннән башка нинди дә булса бер җиләк-җимешнең исемен әйтергә тиеш: «Хөрмә сатам, күршем минем лимон сата».

Уйнаучылар арасында үзе билгеләгән җиләк-җимеш хакында әйтелеп тә, аптырап калучыларга (мәсәлән, берәү мандарин сүзен уйлап куйган иде, әмма берәр уйнаучы «күршем мандарин сата» диюгә, тиз генә «мандарин сатам, күршем минем … сата» дип кычкырып өлгерә алмый) җәза бирелә – фант алына.

## ШУЛАЙ, ӘЙЕ ҺӘМ ЮК

Уйнаучылар түгәрәкләнеп утыралар. Арадан берәү «сораучы» булып билгеләнә һәм һәрбер уйнаучыга аерым-аерым берничә сорау бирә. Уйнаучылар җавап кайтаралар. Ләкин бу уенда җавап биргәндә өч сүзне кулланырга ярамый. Алар: «шулай», «әйе» һәм «юк».

Мәсәлән, «сораучы» мондый сораулар бирә: «Минемчә, көн бүген бик суык, синеңчә ничек?» Җавап «шулай», «әйе», «юк» түгел, ә башкача булырга тиеш. Мәсәлән, «Минемчә дә суык».

Ялгышып кына рөхсәт ителмәгән өч сүзнең берсен кулланган, җавап бирә алмыйча озак көттереп торган уйнаучы берәр төрле җәза үти яисә «сораучы»ны алмаштыра.

## ҖИР, СУ, ҺАВА ҺӘМ УТ

Уйнаучылар утыралар. Арадан сайланган «башлык» торып, очраклы рәвештә әле бер кешегә, әле икенче кешегә югарыда күрсәтелгән дүрт сүзнең берсен әйтә. Мәсәлән, бер уйнаучыга «һава» ди. Теге уйнаучы хәзер үк һавада була торган бер нәрсәнең исемен әйтергә тиеш. Әйтик: «Аэроплан, болыт, лачын».

«Су» диелсә, суда була торган берәр нәрсәнең исемен әйтергә тиешләр (мәсәлән, кызылканат, үрдәк, каз, бака һ.б.).

Башлык кинәт кенә әйткәндә аптырап калмас өчен, уйнаучы дүрт сүзнең һәрберсенә тиешле җаваплар әзерләп куярга мөмкин. Тик кайвакыт уйнаучыга бу да ярдәм итми. Яхшылап тыңлап утырмаган уйнаучы монда да ялгышырга: я бер мәртәбә әйтелгән исемне кабатларга (уенда алай рөхсәт ителми), я ялгыштырып бутап әйтергә мөмкин (башлык аңа «су» дигәндә, «күгәрчен» дию кебек).

Дөрес җавап бирмәүче башлыкны алмаштыра.

Башлык «ут» дигәндә, бер сүз дә әйтмичә, урыннан торып, бер аяктан әйләнеп кире урынга утырырга кирәк.

## ӨЗЛЕКСЕЗ

Уйнаучылар утыралар. Баштагы берәү үзенең күршесенә нинди дә булса бер исем әйтә. Күршесе ул әйткән сүзнең ахыргы хәрефеннән башланган икенче бер исем әйтергә тиеш. Аның күршесе дә шулай ук. Шул юл белән бөтен уйнаучы берәр сүз әйтеп чыга.

Әйтик, беренче кеше «өстәл» ди, икенче кеше «лом», өченче «мәк», дүртенче «күмәч», бишенче «чәй» һ.б.

Бу уенның шарты: сүзләрне бик кызу алып бару. Тиз әйтә алмаган яисә ялгыш әйткән кеше фант бирә яисә тезләнә. Бу уенны, үзара килешеп, шәһәр, елга, кеше исемнәрен генә әйтүне шарт итеп уйнарга мөмкин. Ул вакытта тагын да файдалырак, зиһенне баетырлык булыр.

## БАР, ЮК

Уйнаучылардан ике кеше сайлана. Алар, читкәрәк китеп, нинди дә булса бер хәреф уйлап киләләр. Башкалар бу ике кеше уйлаган хәрефләрне табарга тиеш. Уйнаучылар янына килгәч, һәрбер уйнаучы аларга берәр сүз әйтеп чыга. Сораучының шул сүзендә уйланган хәреф булса, сайланучылар «бар» дияләр. Булмаса, «юк» диләр.

Дикъкать белән, нинди сүзләргә «бар», нинди сүзләргә «юк» җавабы бирелгәнне тыңлап утырып, уйланган хәрефне табарга мөмкин. Кем элегрәк таба, шул кеше үзе теләгән бер кешене иптәшкә алып, хәреф уйларга китә, алар уйлап килгән хәреф тә шулай ук табыла.

Әйтик, уйланган хәреф – «к».

«Йорт»та – юк, «өй»дә – юк, «келәт»тә – бар, «күмәч»тә – бар...

Уенда бик кыска (мәсәлән, бер иҗекле сүзләр) әйтергә киңәш ителми. Ул очракта уйланган хәреф бик тиз табылыр һәм уенның кызыгы калмас иде.

Уйнаучылар бик күп булганда, уенны ике төркемгә бүлеп уйнарга мөмкин. Ул вакытта һәр төркем үзләреннән берәр кеше сайлый. Ике төркемнән сайланган ике кеше киңәшләшеп берәр хәреф сайлап киләләр. Беренче төркемнән сайланган хәреф икенче төркемгә, икенченеке – беренче төркемгә була. Уйланган хәрефне кайсы төркем тизрәк тапса, ул җиңүче булып исәпләнә.

## БЕР ХӘРЕФКӘ СҮЗЛӘР

Уйнаучылардан һәрберсенең кулында карандаш, кәгазь булырга тиеш. Нинди хәрефкә башланган һәм нинди темага караган сүзләр язу турында алдан сөйләшеп куела. Бер үк вакытта уйнаучыларның һәммәсе үз кәгазьләренә яза башлый. Язу өчен берничә минут вакыт билгеләнә. Вакыт үтүгә үк язудан туктарга кирәк. Арадан берсе үзенең язганнарын кычкырып укый башлый. Башкалар үз язганнарына карап, чагыштыра баралар, теге кеше укыган сүз үз кәгазьләрендә дә чыга икән, ул сүзне сызарга тиешләр. Ахырда кемнең кәгазендә башкаларда язылмаган сүз табыла, шул кеше җиңүче була.

Әйтик, «б» хәрефе алынган һәм бары тик хайван һәм кош исемнәре язарга килешенгән булган. Берәү яза: бүре, бөркет, былбыл, болан, бозау һ.б. Бу кешенең язганнары арасындагы бер яисә берничә исем башкаларның язуында булмаска мөмкин, ул вакыт бу кеше җиңүче булып чыга.

## ФИКЕРЛӘР ҖЫЮЧЫ

Бу да, әдәп саклап алып бара алган очракта, шактый кызыклы, файдалы уен.

Җирәбә буенча яисә үзе теләгән берәр уйнаучыны «фикер иясе» итеп сайлыйлар. Язып тору өчен тагын бер кеше билгеләнә. Язучыга каләм, кәгазь бирелгәч, «фикер иясе» башка бер бүлмәгә чыгып тора. Калган уйнаучылар барысы да язучы кешегә «фикер иясе» булган кеше хакында үзенең фикерен яздыра (бу фикер җыюны башка төрле дә эшләргә мөмкин: һәркемгә аерым кәгазь, каләм бирелә һәм һәркем үз кәгазенә фикерен язып бер билгеле урынга сала. Кәгазьләр җыелып беткәч, берәм-берәм алып укыла). Фикер язу беткәч, «фикер иясе» булган кешене чакырып кертәләр дә, язылган фикерләрне укыйлар.

Үзеңнең фикереңдә «фикер иясе»нең яхшы якларын әйтеп мактарга, килешмәгән, урынсызрак якларын әйтеп тәнкыйть

әйтергә мөмкин һәм шул килешмәгән хәрәкәтләрен төзәтү, җую өчен юллар күрсәтергә, киңәшләр бирергә була. Бу уенның бөтен файдасы да шунда. Ләкин тәнкыйть әйтәм дип, берәүнең кимчелекле якларыннан, зәгыйфьлегеннән көләргә яисә дорфа, начар сүзләр белән мыскыл итәргә ярамый, чөнки болай эшләүдән файда урынына зур зарар гына киләчәк. Шуның өчен язучылыкка билгеләнгән кеше мондый «фикер»ләрне язмаска тиеш (язучы итеп шул эшләрне аңлый алырлык кешене сайларга тырышырга кирәк).

Язылган фикерләр укылып беткәч, «фикер иясе» үзе нинди фикерне яздырган кешенең чыгуын тели, шул кеше «фикер иясе» була.

## ЯРТЫ СҮЗ

Түгәрәкләнеп утырып, уйнаучылар бер-берсенә яулык яки туп ыргыталар. Ыргытучы нинди дә булса бер сүзнең беренче яртысын (беренче иҗеген) әйтә, тотучы икенче яртысын (иҗеген) әйтеп, яулыкны тотып ала. Берәү, сүзен әйтә алмыйча озак уйлап торса яисә башта әйтелгән сүзнең яртысын төгәлләр өчен әйтелгән сүзнең икенче яртысы урынсыз булып, ике яртыны бергә кушканда мәгънәсез сүз чыга торган булса (мәсәлән, «ар-на»), уенда гаепләнүче саналып, тезләнергә тиеш.

Уен башта бик җиңел һәм бик тиз бара, әмма соңрак сүз табуы да авырлаша, тезләнүчеләрнең саны артканнан-арта, тезләнү еш була башлый. Уйнаучыларны тезләнеп торудан коткару өчен аларга яулык ыргытырга кирәк. Алар яулык ыргытучы әйткән беренче иҗеккә кушыла торган иҗек әйтсәләр, тезләнүдән котылалар. Тезләнүче үзен-үзе дә коткара ала. Моның өчен ул уртада ыргытылып йөргән яулыкны тотып алырга тиеш.

Уенны бераз катлауландырыр өчен бары тик бер төрле хәрефкә генә башланган сүзләр әйтүне шарт итеп куярга

мөмкин. Әйтик, бөтен сүзләрнең беренче иҗеге «б» хәрефенә башланырга тиеш булса, беренче кеше түбәндәге иҗекләрне әйтә ала: бар, бик, бир, бак... Икенче кеше (яулыкны тотучы) мондый иҗекләр әйтергә тиеш: дым, сез, дең, ча... (бардым, биксез, бирдең, бакча).

## ХИКӘЯ

Кышкы озын кичләрдә бер аулак бүлмәдә җыелып утырган вакытларда күңел ачып, көлешеп алу өчен, файдасыз әкиятләр урынына күмәкләп хикәя сөйләү яхшырак булыр. Күмәкләп хикәя сөйләү болай була.

Арадан кем дә булса үзеннән уйлап бер хикәя сөйли башлый (хикәянең җитди яисә көлкеле булуы, шулай ук аны озакка сузу, кыска тоту сөйләүченең үз ихтыярында). Хикәянең кызык кына бер җиренә җиткәч, сөйләүче кинәт туктый. Аның күршесендә утыручы икенче кеше, өзелгән җиреннән башлап, хикәяне дәвам итәргә тиеш. Икенче кеше дә шулай ук теләгән җиренә кадәр сөйли дә туктый. Аңардан соң өченче кеше, өченчедән соң дүртенче... Башта сөйләргә ризалык биргән һәркем үз чиратында азмы-күпме сөйләп хикәяне сузалар, сузалар.

Хикәянең ахырын башта башлаган кеше сөйләп бетерә. Шул рәвешле күмәк авторлар тарафыннан уйланган бербөтен хикәя килеп чыга. Әлбәттә, һәркемнең сөйләгәне хикәянең бөтен эчтәлегенә туры килерлек булырга тиеш. Үз чиратында сөйли алмый аптырап торган яисә буталган кешегә нинди дә булса җәза бирелә.

Хикәя сөйләүнең кызыгы шунда: берәү бер-ике сүз белән генә үз чиратын үткәреп, күршесен уңайсыз хәлдә калдырырга мөмкин. Хикәя сөйләгәндә гомумән кызыклы хәлләр сөйләнелеп көләргә, күңел ачарга мөмкинлек күп булачак.

## ПЕШМИ КАЛГАН ҖЫР

Уйнаучыларның һәммәсенә кәгазь һәм карандашлар бирелә. Беренче язучы кәгазьнең бер читенә нинди дә булса үзе теләгән бер җырның беренче юлын яза да, шул язулы урын күренмәсен өчен, бөкләп, күршесенә бирә. Күршесе дә шулай ук үзе белгән бер җырның икенче юлын язып (беренче кеше беренче юл, икенче кеше икенче юлны яза), язуын каплый һәм күршесенә бирә. Бу күршесе дә баштагылар кебек эшли һәм кәгазьне ары җибәрә. Шулай һәркем үзе белгән бер җырның беренче яисә икенче юлын язып чыга. Азактан берәү, тавыш белән бу җырларны укый. Монда

*Ак Иделнең аръягында бер инәгә бер сыер,*
*Кызыл бишбармакча бирер идем әниеңә*
*әйтерсең дип куркам...*

кебек пешми калган җырлар килеп чыга. Араларында бик кызыклары булырга мөмкин, шулары көлке тудырачак та инде. Бу уенны шигырь язу белән дә уйнарга ярый. Ул очракта пешмәгән шигырь килеп чыгачак.

# ТАТАР ХАЛЫК УЕННАРЫН УКЫТУ-ТӘРБИЯ ПРОЦЕССЫНА КЕРТЕП ҖИБӘРҮДӘ ПРЕДМЕТЛЫ-ҮСТЕРЕЛЕШЛЕ МОХИТ ОЕШТЫРУ БУЕНЧА МЕТОДИК РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР

Предметлы-уенлы үстерелеш мохите – баланы әйләндереп алган материаль объектлар ул. Һәм әлеге объектларга мөнәсәбәтле рәвештә ул рухи һәм физик яктан үсә. Предметлы мохитнең дөрес оештырылуы беренче чираттагы бурычлардан санала, чөнки кабинетның, уйнау зоналарының нинди инвентарь, әсбаплар белән җиһазландырылуы балаларның уен эшчәнлеге сыйфатына турыдан-туры йогынты ясый. Предметлы-уенлы үстерелеш мохитен оештыру дигәндә, төрле объектларны балаларның уен тирәлегенә кертү күздә тотыла. Әйтик, тирәлектә төрле архитектура-ландшафт һәм табигый-экологик объектлар, уен һәм спорт мәйданчыклары булырга мөмкин. Бу бигрәк тә күп урын таләп ителә торган хәрәкәтле уеннар оештырганда мөһим. «Туп ялшереш», «Буш урын», «Бер аяк белән көрәш», «Куык», «Мәрьям әби малайлары», «Шаян казлар», «Очучылар», «Кызылармиячеләр», «Тот, тот», «Куянны тот», «Узышчылар», «Җитез бул», «Коткаручы таяк» уеннары шундыйлардан.

Балалар уйный торган мохит эре габаритлы конструктор модульләре белән җиһазландырыла ала. Аларның зурлыгы балаларның буена туры килергә тиеш. Аларны балаларның хәрәкәтле уеннарында да файдаланырга мөмкин (әйтик, «Почмаклар» уенында).

Кабинетның җиһазландырылышы турында сүз алып барганда, аның тематик уенчыклар, аудиовизуаль чаралар, ярдәмлекләр, сәнгать һәм башка студияләр белән баетылуы турында искәртү урынлы булыр. Уен эшчәнлеге өчен билгеләнгән урын балаларга хәрәкәтле уеннар уйнарга да,

төрле материаллар белән эшләргә дә мөмкинлек бирергә тиеш. Ул үзгәртеп корыла алса бигрәк тә әйбәт. Бу фактор балаларны тәрбияләгәндә һәм аларга белем биргәндә уңайлы шартлар тудырырга ярдәм итә.

Балалар уеннарын тиешенчә оештыру өчен бүлмәдә матлар, йомшак модульләр, ширмалар булса әйбәт. Алар балаларның кызыксынуларыннан чыгып мохитне үзгәртергә мөмкинлек бирә. Балаларның уен пространствосын төрле каркаслар, тукымалар, эре җиңел модульләр белән дә бик ансат кына үзгәртеп була. Төзелеш һәм конструкторлык эшчәнлеге җыелмалары белән идәндә дә, өстәл артында да уйнарга була, мондый җыелмаларны балалар бик ярата. Балаларга тагын да кызыклырак булсын өчен әлеге блокларны төрле төстәге клеенкалар белән тышларга мөмкин. Поролон блок һәм мендәрләр бик җиңел булганлыктан, аларны кулланып, балалар үзләре үк төрле уен мәйданчыклары төзи ала. Түгәрәкләп урнаштырганда, әлеге блоклар урындык ролен үти, аларны «Йөзек табу», «Ишкән баулар», «Бер-береңә әйбер тапшыру» уеннарын уйнаганда файдаланырга мөмкин.

Кечкенәләр төркеме өчен якты төсләрдәге эре уен җиһазлары кулай. Алар балаларның буе җитәрлек урында урнаштырыла. Әлеге җиһазлар атна саен алыштырылып торса әйбәт. Уен өчен кирәкле материалларның бик күп булуы да хупланмый. Аларны тәртипкә салып, киштәләргә урнаштыру артык күп вакыт таләп итә. Шуның өчен дә бөтен уен материалын берьюлы урнаштыру мәҗбүри түгел. Әмма шунысын онытмыйк: уеннар, уенчыклар, материаллар һәм җиһазлар балаларны кызыксындырырлык дәрәҗәдә төрле булырга тиеш. Бу бик мөһим, чөнки уенда баланың фантазиясен эшкә җигәрлек ни дә булса җитми калса, уен эшчәнлеге туктала. Ә яңа предметлар барлыкка килү, киресенчә, уенны стимуллаштыра. Беренче карашка бик бай тоелган уенчыклар арасында да теге яки бу уенда кулланырлыклары булмаска мөмкин.

Мохитнең иң әһәмиятле параметрларыннан берсе – аның һәркем өчен, шул исәптән, мөмкинлеге чикләнгән балалар һәм инвалидлар өчен дә уңайлы булуы. Балалар уеннарга, уенчыкларга, материалларга үзләре үрелә алырга тиеш. Мохитнең куркынычсызлыгы турында да онытырга ярамый, аның ышанычлы булуы зарур.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә материаллар һәм җиһазлар сайлаганда түбәндәге кагыйдәләрне истән чыгарырга ярамый:

1. Кабинетның уен материалы һәм җиһазлар белән оптималь тәэмин ителеше. Ул мохитнең бөтенлеген, күпфункциялелеген һәм үзгәрә алучанлыгын тәэмин итәргә тиеш. Материаллар артык күп тә, бик аз да булмасын.

2. Традицион һәм заманча материаллар балансы сакланырга тиеш. Шул вакытта гына милли уеннар тирәлеге искелек калдыгы дип түгел, ә заманча булып кабул ителер. Шулай ук традицион уен һәм материалларның файдалы якларын да онытырга ярамый, замана җилләре аларны кысрыклап чыгармасын иде.

3. Тирәлектәге уен һәм материаллар һәр ике җенес өчен дә туры килерлек булса әйбәт. Бу балалар 4–5 яшькә җиткәндә аеруча актуаль булачак, чөнки шушы яшьләрдә алар җенес аермаларына игътибар итә башлый.

«Туганнан алып мәктәпкә кадәр» («От рождения до школы») инновацион программасына караганда, мохитнең төрле өлешләргә (үзәкләргә) бүлеп җиһазландырылуы балаларның мөстәкыйль уйнаулары өчен алшарт булып тора. Мондый бүленеш булганда балалар зурлар ярдәменнән башка да уйный ала. Бу үзәкләрдә тәкъдим ителә торган материалларны балалар өстәмә аңлатмаларсыз да куллана алачак.

Уен үзәкләре аермачык итеп билгеләнергә тиеш. Моның өчен өстәл, тәбәнәк стеллаж, келәмнәр файдаланыла. Үзәк аша үтеп йөрүчеләр анда уйнаган баланы уеннан аермаска

тиеш. Шуңа күрә дә үтеп йөрү юлларын уйлап планлаштырырга кирәк. Сюжетлы-рольле уеннар өчен аерым, театральләштерелгән (драматик) уеннар өчен аерым, өстәл уеннары өчен аерым үзәкләр билгеләнергә мөмкин. Уен үзәкләре, курчаклар өчен җиһазлар булган очракта, ял урыны итеп тә кулланыла ала.

Мәктәпкәчә яштәгеләрнең предметлы-уенлы мохите уеннар тупланмасын (игротека) да үз эченә ала. Кабинетта аңа аерым урын билгелиләр. Уеннар тупланмасы дидактик, зиһен сынаш, логик-математик уеннардан тора. Андый төр уеннар зурлар төркемендәге балаларда чагыштыру һәм классификация операцияләрен формалаштыра.

Зурлар төркемендәгеләрнең кроссвордлар, танып белүгә корылган биремнәр белән дә кызыксынуы арта. Бу кызыксынуны үстерү өчен ковролинга ябыштыргыч тасмалар ярдәмендә хәрефләр, башка төрле биремнәр беркетергә мөмкин. Зурлар төркемендәге предметлы үстерелеш мохите фонематик ишетү сәләтен үстерә торган уеннарны да үз эченә алырга тиеш. Болар – предметның исемендәге авазларны белүгә, аларны әйтелеш буенча төркемнәргә бүлүгә корылган уеннар. «Тиз уйла», «Табышмаклар», «Эндәшмә», «Өч сүз», «Шулай, әйе һәм юк», «Бар, юк», «Өзлексез», «Ярты сүз», «Хикәя», «Шигырь-җыр» татар халык уеннары бигрәк тә кызык.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның күпмедер дәрәҗәдә танып белү тәҗрибәсе формалашкан була, аны инде тагын да тирәнәйтергә, ныгытырга, гомумиләштерергә кирәк. Бу юлда «Оча», «Җиләк-җимеш базары», «Җир, су, һава һәм ут», «Эзләр буйлап» уеннарын оештыру файдалы булыр.

Бүлмәләрдә сенсор үзәк булу да үзенең нәтиҗәлелеген күрсәтте. Бу үзәктәге предметлар һәм материаллар баланың сизү органнарына тәэсир итәргә тиеш. Болар музыкаль һәм тавышлы инструментлар, рәсемнәр, калейдоскоплар, хушбуй һәм башка исле матдәләр булырга мөмкин. Алар барысы да

баланың ишетү, күрү, сизү анализаторларын камилләштерергә ярдәм итә. Бу юлда «Музыканы нык тыңла», «Белмәсәң, үзең җырларсың», «Тавышсыз музыка» уеннары ярдәмгә килә ала.

Иң мөһиме, сюжетлы-рольле уеннар уйнала торган бүлмәне яхшы җиһазландырырга, әлеге төр уеннар өчен бар яктан уңайлы итәргә кирәк. «Гаилә» булып уйнар өчен аерым, төрле һөнәр ияләре булып уйнар өчен аерым урыннар бүлеп бирергә мөмкин. «Гаилә» уеннары өчен түбәндәге материал һәм атрибутларны кулланырга була:

– төрле зурлыктагы курчаклар;

– уйнау процессында кулланып була торган төрле предметлар – бала чүпрәкләре, одеяллар, имезлекләр, шешәләр;

– малай һәм кыз курчаклар өчен төрле ел фасылларында киелә торган киемнәр;

– төрле зурлыктагы бала арбалары (колясκалар);

– йорт җиһазлары, диваннар һәм кәнәфиләр, аш бүлмәсе гарнитуры, плитә, суыткыч;

– савыт-саба һәм йорт кирәк-яраклары;

– уенчык ризыклар.

Икенче очракта түбәндәге һөнәр ияләре булып уйнар өчен предметлар һәм материаллар кирәк була:

– табиблар;

– янгын сүндерүчеләр;

– полиция хезмәткәрләре;

– чәчһәвәсләр;

– кибетчеләр;

– хәрбиләр һ.б.

Театральләштерелгән (драматик) уеннар үткәрелә торган урында да җайланмалар һәм материаллар дөрес сайланган булырга тиеш. Бу үзәктә театральләштерелгән тамашалы драматик уеннар өчен аерым, гадирәк театр уеннары (курчак театры, өстәл уеннары) өчен аерым урыннар бүлеп бирергә мөмкин. Беренче очракта түбәндәге җайланмалар кирәк:

– ачыла-ябыла яки җәелә-җыела торган зур пәрдә (ширма);
– костюмнар өчен кием элгечләр;
– костюмнар;
– төрле битлекләр (йорт хайваннары, ерткыч хайваннар һәм аларның балаларыныкы);
– әкият персонажлары битлекләре;
– театральләштерелгән уеннар өчен төрле артибутлар;
– костюм элементлары (эшләпә, шарф, итәк, сумка, кулчатыр, муенсалар һ.б.).

Икенче очракта түбәндәгеләр кирәк:
– өстәл театры өчен кечкенә ширма;
– кечкенә һәм уртача зурлыктагы фигуралар;
– күләмле һәм яссы персонажлар ясау өчен әзерләнгән материаллар;
– өстәл уеннарында һәм «бармак театрлары»нда кулланыла торган декорацияләр;
– атрибутлар җыелмасы;
– бармакка кия торган курчаклар, пирчәткә курчаклар.

Костюмнар һәм битлекләр балаларга яхшы таныш «Карга», «Әтәч кычкырды», «Маэмай почмакта», «Бүре», «Яңача мәче һәм тычкан уены», «Аю янында кара урманда», «Йонлач көчек», «Куян» һәм башка татар халык уеннарын да төрләндереп җибәрә ала.

Өстәл уеннары почмагында түбәндәге җайланмалар һәм материаллар була:
– өстәл һәм урындыклар, әйберләр кую өчен ачык стеллаж;
– киселгән картиналар һәм пазллар;
– рәсемле кубиклар;
– «Лото», «Домино» кебек уеннар;
– балаларның яшенә туры килерлек һәм кагыйдәләре булган йөртеп уйнала торган өстәл уеннары;
– шашка, шахматлар;

– башваткыч уеннар, уйлап уйнала торган уеннар һ.б.

Балаларның мөстәкыйль уеннары мөмкин кадәр күбрәк файда бирсен өчен, төркемдә төрле әсбаплар һәм материаллар уйлап һәм дөрес сайланылган булырга тиеш. Моны гамәлгә ашыру өчен түбәндәге шартларның үтәлүе зарур:

– материалларның тәртиптә булуы;

– аларның җитәрлек күләмдә булуы;

– материалларның төрле булуы;

– яшь үзенчәлекләренә һәм индивидуаль мөмкинлекләргә туры килүе;

– куллану өчен җайлы, уңайлы булуы;

– автодидактика;

– даими рәвештә яңартылып торуы;

– балаларны кызыктырырлык булуы;

– чыдам һәм зарарсыз булуы.

Психология, педагогика буенча заманча инновацион хезмәтләр, төрле яшьтәге балалар өчен үзләрен чолгап алган мохиттә татар халык уеннарын оештырганда, күпьеллык тәҗрибәләрне кулланып хәл итәргә тиешле төп бурычларны билгеләргә мөмкинлек бирә.

# БАЛАЛАРГА БЕЛЕМ-ТӘРБИЯ БИРГӘНДӘ ТАТАР ХАЛЫК УЕННАРЫН КУЛЛАНУ БУЕНЧА МЕТОДИК РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР

**КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ**

Беренче һәм икенче кечкенәләр төркемендә уеннар план буенча оештырыла һәм, әлеге план үтәлгән очракта, уен уңышлы килеп чыга. Татар халык уеннарын планга алдан ук кертеп кую дөрес булыр. Татар халык уеннарын уйнату нинди дә булса милли бәйрәм уңаеннан оештырылган бер тапкыр гына үткәрелә торган чарага әйләнеп калмасын иде. Алар системалы рәвештә кулланылган һәм балалар үсешенең, тәрбиясенең табигый бер өлеше, элементы булган очракта гына зур файда китерәчәк.

Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр төркемендәге балаларның уеннары белән җитәкчелек итү өчен тәрбияче түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:

– уенны дидактик материаллар һәм кирәкле атрибутлар белән тәэмин итәргә;

– балаларның әйләнә-тирә дөнья турындагы күзаллауларын киңәйтергә, аларны уен белән кызыксындырырга;

– кирәк икән, уенның кагыйдәләрен кабатларга (яңа уен булган очракта, балаларны аның кагыйдәләре белән таныштырырга);

– җитәкчелек итүнең төп ысулын кулланырга – ничек уйнарга, нәрсә эшләргә кирәклеген күрсәтергә;

– рус һәм татар телләрендә нәрсә эшләргә кирәклеген әйтергә, уенның юнәлешен билгеләргә;

– үзара аралашып, килешеп уйнасыннар өчен, мәктәпкәчә яшьтәге балаларны бер-берсе белән кызыксындырырга, мөгамәлә корырга булышырга;

– уенга йомгак ясарга, аның балаларга ошау-ошамавын ачыкларга.

Тәрбиячеләр, укытучылар уенны оештыручы ролендә генә калмыйча, балаларга кызык булсын, яратып һәм теләп уйнасыннар дип, күп очракта үзләре дә уенга кушылып китәләр. Шунысын да билгеләп үтү мөһим: бу яшьтә балалар әле бергә түгел, ә янәшә уйныйлар. Әмма башка балаларның уеннары белән кызыксына башлыйлар, үзләре дә сизмәстән, бик озакка булмаса да, төркемдәшләре белән уйнап, аралашып алалар, хәрәкәтле күмәк уеннарга бик теләп кушылалар.

Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр төркемендә уеннар бик гади. Бу яшьтәге балаларның игътибары күбесенчә предметка – уенчыкка юнәлә. Тәрбияче баланы иптәшләре белән уйнарга өйрәтә. Башта бала уенчык белән уйный, аннары зур иптәше – тәрбияче белән уйный башлый, аннан соң гына әле яшьтәшләре белән уйнарга өйрәнә.

## Сюжетлы-рольле уеннар уйнату

Тәрбияченең сюжетлы-рольле уеннарда катнашуы мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр төркемендә мондый уеннар оештыруның төп алымнарыннан берсе булып тора. Тәрбияче белән бергә уйнау балаларның кызыксынуын, игътибарын арттыра, аларның эш-хәрәкәтләрен тагын да төгәлрәк, дөресрәк итә.

Әлеге уеннарда тәрбияче төрле рольләр башкарырга мөмкин. Мәсәлән, әни, сеңел, машина йөртүче, китапханәче һәм башкалар була ала. Шулай итеп, берничә бала күмәк уен өчен берләшә, ә нинди дә булса роль алган тәрбияче, үз чиратында, аларга үрнәк булып тора. Тәрбияченең рольле уеннарда катнашуы, балалар белән бергә уйнавы нәниләргә уен про-

цессына тизрәк керәп китәргә, кыюрак булырга ярдәм итә. Чөнки ул балалар белән сөйләшә, аларга теге яки бу уенчык белән нәрсә эшләргә кирәклеген аңлата, күрсәтә һәм әле алай гына да түгел, уен кагыйдәләре буенча, үзе дә шул ук эшгамәлләрне башкара. Бу яшьтәге балаларны татар халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыру, бигрәк тә табышмаклар өйрәтү һәм аларны бер-берсенә әйттереп карау, бергәләшеп җавап эзләү һәм башкалар мөһим.

## Дидактик уеннар уйнату

Икенче кечкенәләр төркемендәге балаларда мөстәкыйльлеккә омтылыш барлыкка килә. Дидактик уеннар үткәргәндә, тәрбияче әлеге омтылышны кулланып, аны оста гына кирәкле юнәлешкә борып җибәрә алса, бигрәк тә яхшы. Шул ук вакытта, элеккеге кебек үк, бала тәрбиячене күптөрле мәгълүмат чыганагы буларак кабул итә, аңа тәрбияче белән уйнау, аралашу бик кызык.

Дидактик уенда күрсәтү, аңлату кебек «җитәкчелек итү» алымнары һәм методлары уен тиешенчә барып чыксын, кагыйдәләргә туры килерлек итеп һәм төгәл уйналсын өчен кулланыла. Татар халкының дидактик уеннарын өйрәткәндә, үсә төшкәч тә уйный алсыннар өчен, кечкенәләр төркемендәге балаларга предметларның атамалары рус телендә дә, татар телендә дә өйрәтелә.

## Хәрәкәтле уеннар уйнату

Хәрәкәтле уеннар оештырганда түбәндәге шартларны күз уңында тотарга кирәк:

– балаларның физик һәм акыл мөмкинлекләрен;
– хәрәкәт мөмкинлекләренең дәрәҗәсен;
– көндәлек режим үзенчәлекләрен;
– ел фасылын;
– һәр баланың сәламәтлек дәрәҗәсен;

– үткәрү урынын;

– балаларның кызыксынуларын.

Балаларның яшенә һәм хәрәкәтчәнлек дәрәҗәсенә карап, хәрәкәтле уеннар катлаулана бара. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән түбәндәге татар халык уеннарын уйнарга була.

## КУЫК

*Уенның максаты:* балаларны түгәрәк ясап басарга һәм шул түгәрәкне әкренләп киңәйтергә һәм тарайтырга, тәрбияче әйткәннәрне ишетергә, игътибарлы булырга өйрәтү.

Бу уен өчен иркенрәк урын кирәк. Түгәрәкне киңәйткән, зурайткан вакытта балалар өстәл-урындыкларга, җиһазларга бәрелерлек булмасын. Тәрбияче сүзләрне ачык һәм аңлаешлы итеп әйтергә тиеш.

## ШАЯН КАЗЛАР

*Уенның максаты:* балаларны образлы хәрәкәт белән бию хәрәкәтләрен берләштерергә өйрәтү, хор белән җырлау күнекмәләрен арттыру.

Җырга ияреп хәрәкәтләр ясаганда, балалар кул-аякларын, гәүдәләрен, җыр мәгънәсенә туры китереп, хәрәкәтләндерү, импровизацияләү осталыкларын арттыра. Уенны оештыру өчен балаларны җырчыларга һәм актерларга бүләргә кирәк. Аннары рольләр алмашына.

## КУЯН

*Уенның максаты:* балаларның сөйләмен үстерү, бию хәрәкәтләрен берләштерү осталыкларын арттыру. Балаларны тәрбияче әйткәннәрне ишетергә, игътибарлы булырга өйрәтү.

Әлеге уен өчен балаларга шигырьне алдан ук өйрәтеп куярга, сүзләрнең дөрес әйтелешен күзәтергә кирәк. Балалар түгәрәкләнеп утыралар, куян түгәрәкнең уртасын-

да кала. Җыр яңгыраган вакытта балалар җырда әйтелгән хәрәкәтләрне күрсәтәләр. Җыр беткәч, куян кайсы бала алдында туктый, алга таба шул бала куян була.

## КУЯННЫ ТОТ

*Уенның максаты:* «кояш куяны»н тоту.

Тәрбияче «кояш куяны»н бер предметтан икенче предметка күчерә, балалар чиратлашып аны тоталар.

## ЙОНЛАЧ КӨЧЕК

*Уенның максаты:* балаларның сөйләмен үстерү, бию хәрәкәтләрен берләштерү осталыкларын арттыру.

Әлеге уен өчен балаларга алдан ук шигырь өйрәнеп куярга кирәк. Бер бала «көчек» итеп сайлана. Калган балалар шигырь сөйлиләр. Сөйләп бетергәч, «көчек» янына килеп, аны сыйпый башлыйлар. «Көчек» күзләрен ача, сикерергә, өрергә тотына. Балалар кача, көчек аларны куа. Кемне тота, алга таба шул бала алып баручы була.

Хәрәкәтле уеннар оештырганда балаларның сөйләмен татар сүзләре белән баетырга тырышырга кирәк.

### Театральләштерелгән уеннар уйнату

Тәрбияче алдан ук әзерләнә: куеласы әсәрне, кирәкле предмет һәм җиһазларны сайлый, алга куелган бурычларны хәл итү өчен, төрле чаралар кулланып, репетицияләр үткәрә. Спектакльдә педагог матур курчаклар куллана, музыка сайлый, сәнгать чаралары белән оста эш итә.

Иң мөһиме, эчтәлекле һәм мәгънәле материал сайларга кирәк. Чөнки бу яшьтәге балалар әхлак тәрбиясе бирә торган уен һәм әкиятләрне дә, юморны да аңлап кабул итә. Театральләштерелгән әсәр балаларның күңелен күрү, көлдерү өчен генә түгел, ә нинди дә булса файдалы фикер сеңдерерлек, тәрбия бирерлек тә булырга тиеш. Балаларның

мөстәкыйльлеккә омтылышын хуплап, тәрбияче бу юнәлештә дә эш алып бара, аларның фикерләре белән кызыксына, бергәләшеп уйлау, сөйләшүне оештыра. Татарстанның балалар бакчаларында даими куела торган татар халык әкиятләрен театральләштерү файдалы булачак.

Билгеле инде, кечкенәләр төркемендә уйный торган тирәлек театральләштерелгән тамашага туры килерлек көнкүреш предметлары, уенчыклар, костюмнар белән баетылган булырга тиеш.

Кайбер хәрәкәтле уеннарны, мәсәлән, «Йонлач көчек»не, костюмнар кулланып, сюжетын үстереп, театральләштерелгән уен итеп уйнарга да мөмкин.

## УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕ

Уртанчылар төркемендәге балалар берберсе белән күбрәк аралаша, шуңа күрә аралашу, рольләр бүлешүгә корылган күпсанлы татар халык уеннарын куллану бик уңышлы була. Бергә уйнау, кызыксынулары бертөрле, аралашу өчен темалар күп булу балаларның активлыгын һәм әңгәмә кору, үзара сөйләшү-аралашу дәвамлылыгын тагын да арттыра.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның кечкенәләр төркеменнән аермалы буларак, уртанчылар төркемендәге балалар инде янәшә генә түгел, ә бергә уйный, аларның сөйләшүләре дә эчтәлеклерәк һәм дәвамлырак була бара. Уеннарның мәгънәсе рольле гамәлләрнең сыйфатын билгели. Чынбарлыктагы һәм уен барышындагы гамәлләр һәм үзара тәэсир итешүләр бер-берсеннән аерыла башлый. Балаларның үз ролен аңлавы аларның тормыш тәҗрибәсенә нигезләнә. Тәҗрибә күрсәткәнчә, әлеге уеннар өчен еш кына бары тик кызлардан яисә малайлардан гына торган кечкенә төркемнәр хасил була. Балалар уеннарны җенескә карап та (малайлар яисә кызлар уены), социомәдәни мохитне исәпкә алып та сайлый. Уеннарның нинди темага каравы балаларның тормыш тәҗрибәсенә дә бәйле. Кызлар күбесенчә гаилә тематикасына кагылышлы уеннарны үз итә. Биредә гаиләдәге мөнәсәбәтләрне чагылдыра торган татар халык уеннарын сайларга була. Малайлар төрле йортлар, биналар төзергә, атышып уйнарга ярата. Уеннарда балаларның лидерлык сыйфатларына ия булу-булмавы да күренә башлый. Уеннар кызу, күңелле үтә, аларны гел төрләндереп тору таләп ителә башлый. Кагыйдәләрне төгәл үтәүнең әһәмияте арта.

Уку-укыту процессында татар халык уеннарын куллану тагын да нәтиҗәлерәк булсын өчен, балаларның көн режимында уңайлы, иркен (беркем дә комачауламый, ашыктырмый торган) вакыт аралыгын сайларга кирәк. Шул ук вакытта, балаларның активлыгын, кызыксынуын арттыру өчен, режимдагы кайбер шөгыльләрне дә, мәсәлән, иртәнге зарядканы, татар халык уеннары рәвешендә уздырырга була. Балаларның иҗади үсеше өчен мөмкинлекләрне арттыру максатыннан, уеннарда өлкәннәрнең роле акрынлап кими бара.

Уртанчылар төркемендә татар халык уеннарын көн режимына да кертергә мөмкин. Иртән, бөтен балаларның килеп бетүен көткән арада (биш минуттан алып ярты сәгатькә кадәр) «Аю янында кара урманда», «Йонлач көчек», «Куык» уеннарын уйнау кызыклы. Соңгысын иртәнге зарядка ясаганда да уйнап була.

## КУЫК

*Уенның максаты:* балаларны түгәрәк ясап басарга һәм башта ул түгәрәкне әкренләп киңәйтергә, аннары тарайтырга, тәрбияче әйткәннәрне ишетергә, игътибарлы булырга өйрәтү.

Бу уен өчен иркен урын кирәк. Түгәрәкне киңәйткән, зурайткан вакытта балалар өстәл-урындыкларга, җиһазларга бәрелерлек булмасын. Тәрбияче сүзләрне ачык һәм аңлаешлы итеп әйтергә тиеш.

Укыту-тәрбия процессында, ягъни балалар озак вакыт хәрәкәтсез торган чакларда, дәрес, шөгыль араларында «Аю янында кара урманда», «Йонлач көчек», «Куык» уеннарын уйнатырга була (2–5 минут).

Ә саф һавада булу – балаларның актив уйнау вакыты. Татар халык уеннарының күпчелеге нәкъ менә урамда үткәрелә (бер сәгатьтән алып сәгать ярымга кадәр).

Төрле дәресләр вакытында уку-укыту процессына татарча табышмаклар, дидактик уеннар кушып җибәрергә дә мөмкин.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның уртанчылар төркеменә йөрүчеләрнең уйнау тәҗрибәсе кечкенәләр төркемендәге балаларныкына караганда зуррак. Димәк, бу яшьтәге балалар өчен, яңа кагыйдәләр кертелеп, сюжеты үстерелеп, уеннар әкренләп катлаулана бара.

Уен – ирекле шөгыль, димәк, балаларга үзләре теләгәнне уйнарга мөмкинлек бирергә кирәк. Тәрбияче бары тик уйнау өчен шартлар тудыра, балаларда кызыксыну уята һәм, уенның кызыклы һәм тиешенчә баруын күзәтеп, кирәк очракта төзәтмәләр кертә, юнәлеш кенә бирә ала. Мөстәкыйльлекләре артканнан-арта барса да, балалар барыбер тәрбиячене идеяләр һәм мәгълүмат чыганагы итеп күрәләр.

Татар халык уеннарын мәктәпкәчә яшьтәге балаларның театральләштерелгән эшчәнлегенә кертү өчен, түбәндәге кагыйдәләр үтәлергә тиеш:

– театральләштерү өчен татар халык әкиятләрен тәкъдим итү;

– балаларга төрле рольләрдә уйнарга мөмкинлек бирү;

– үзләренә сюжетны үстерергә тәкъдим итү, уенны катлаulандыру;

– куелыш турындагы фикерләрен белешү;

– кую өчен иҗади төркемнәргә берләшергә өйрәтү;

– тәрбияче әзерләгән атрибутларны (татар костюмнарын, көнкүреш элементларын, милли уенчыкларны) кулланырга өйрәтү;

– төркемдә аралашуның демократик стилен саклау;

– балаларны импровизация ясарга өйрәтү, үз төркемендәге балалар һәм аларның әти-әниләре алдында чыгыш ясау белән кызыксындыру.

Театральләштерү өчен әкиятләрне нинди сыйфатлар тәрбияләү, нинди күнекмәләр булдыру бурычы куелудан чы-

гып сайларга кирәк. Бер үк вакытта күңел ачу гына түгел, тәрбияләү чарасы да булганлыктан, театральләштерү алымы тәрбиячегә балалар бакчасындагы уку-укыту процессына татар халык уеннарының бөтен тәрбияви потенциалын кертергә мөмкинлек бирә.

Уртанчылар төркемендә хәрәкәтле татар халык уеннарын уку-укыту процессына кертү бу яшьтәге балаларның хәрәкәт активлыгы һәм мөстәкыйльлекләре арту белән аңлатыла.

«Маэмай почмакта», «Яңача мәче һәм тычкан уены», «Аю янында кара урманда», «Йонлач көчек», «Куык», «Безнең капка төбендә», «Шаян казлар», «Очучылар», «Кызылармиячеләр», «Күз бәйләү», «Тот, тот», «Куянны тот», «Бер-береңә әйбер тапшыру» кебек хәрәкәтле татар халык уеннары аеруча файдалы булыр.

## ШАЯН КАЗЛАР

*Уенның максаты:* балаларны образлы хәрәкәт белән бию хәрәкәтләрен берләштерергә, хор белән җырларга өйрәтү.

Җыр сүзләренә туры килерлек хәрәкәтләр ясаганда, балалар кул-аякларын, гәүдәләрен җыр мәгънәсенә туры китереп хәрәкәтләндерү, импровизацияләү осталыкларын арттыра. Уенны оештыру өчен балаларны җырчыларга һәм актерларга бүләргә кирәк. Аннары рольләр алмашына.

## ПОЧМАКТА МАЭМАЙ

*Уенның максаты:* балаларның реакция тизлеген, хәрәкәтләрен координацияләү осталыкларын арттыру. Әлеге уенны бүлмәдә дә, урамда да уйнарга мөмкин. Әмма, урамда үткәрелгән очракта, балалар качарга тиешле урынның чикләрен билгеләп куярга кирәк. Почмакларны шартлы рәвештә җиргә сызыклар сызып та билгеләргә мөмкин. Иң мөһим шарт: уйнаучыларның саны бүлмәдә почмаклар санына карап билгеләнә, димәк, бер үк вакытта биш бала уй-

ный. Кичен, балалар берәм-берәм өйләренә таралганда, яисә иртән, әле барлык балалар да килеп җитмәгән вакытта, уйнарга киңәш ителә. Шулай ук азсанлы төркемнәрдә дә уйнарга ярый.

## ЯҢАЧА МӘЧЕ ҺӘМ ТЫЧКАН УЕНЫ

*Уенның максаты:* балаларны үзләренең хәрәкәтләрен дөрес билгеләргә, игътибарлы булырга өйрәтү.

Уенның үзенчәлеге – алып баручының әйтүе буенча, уйнаучыларның урын алмашып, уен барышының тиз үзгәреп торуында. Уен иркен урында уйнауны таләп иткәнлектән, аны саф һавада уйнау яхшырак.

«Аю янында кара урманда», «Маэмай почмакта» уеннары балаларны сабыр булырга өйрәтә (әйтелергә тиешле сүзләрне әйтеп бетергәннән соң гына аюдан качарга ярый).

## АЮ ЯНЫНДА КАРА УРМАНДА

*Уенның максаты:* балаларны җитез, өлгер булырга өйрәтү.

Аю булып уйнаучы йоклаган булып кылана. Йокыга талган аю үзен ничек тота? Ничек яткан? Ничек сулый? Театральләштерү элементлары кулланып, балаларның игътибарын иң элек шуңа юнәлтеп алырга мөмкин. Уенда кулланыла торган такмакны өйрәнүнең дә файдасы бар, балалар аны һәрвакыт күмәкләшеп әйтә торган булалар, хәтерләре яхшыра, игътибарлырак була башлыйлар.

Әлеге уенны оештырганда, уйный торган мәйданчыкның иркенләп йөгерерлек булуына игътибар итәргә кирәк. Ул урындыклар, уенчыклар белән тулган булып, уен барышында балалар бәрелерлек булмасын.

## КЫЗЫЛАРМИЯЧЕЛӘР

«Кызылармиячеләр» уены аеруча кызыклы, чөнки бу уенда балалар үзләренең җитезлек, өлгерлек сыйфатларын гына түгел, ә сафта басып тору, бирелгән командаларга игътибарлы булу сәләтләрен дә арттыралар.

Уенның максаты: балаларның сафка басу, бер-берсе арасындагы ераклыкны дөрес саклау, сафта басып тору кагыйдәләрен үтәү, бирелгән командаларга игътибарлы булу сәләтләрен, җитезлек сыйфатларын арттыру. Бу уенны физкультура залында яки урамда спорт белән шөгыльләнгән вакытта да уйнап була. Физкультура дәресләрендә берәр нәрсәгә өйрәнгән (мәсәлән, предмет аша сикерергә) вакытта әлеге уен элементлары кулланыла. Мәсәлән, командир кызылармиячеләргә берәр нәрсә аша сикереп чыгарга куша һ.б. Шулай итеп, башкарыла торган эшчәнлеккә тәрбияче даими рәвештә кызыксыну уятып тора. Баштарак тәрбияче үзе командир ролендә булып, алга таба бу рольне берәр актив балага бирергә мөмкин. Уенны оештыру алдыннан, балаларга кызылармиячеләр сурәтләнгән иллюстрацияләр күрсәтү, аларның кем булуларын аңлату, полиция, солдат һ.б.ның эшчәнлекләре белән чагыштыру да файдалы.

## КУЯННЫ ТОТ

«Куянны тот» уенын оештырганда балалар белән табигатьне күзәтергә, аларга кояш турында мәгълүмат биреп, аның бөтен тереклек өчен әһәмияте турында сөйләргә мөмкин.

*Уенның максаты:* балаларда җитезлек, өлгерлек сыйфатларын арттыру.

Уйный башлар алдыннан кояш яктысы турында әңгәмә корырга, төрле өслекләрне карарга (нинди өслекләр яктылыкны чагылдыра, ниндиләре – юк) мөмкин. Шул рәвешле хәтта хәрәкәтле уен да әйләнә-тирәне күзәтү, балаларда танып белүне үстерү, кызыксынучанлыкны арттыру чарасы булып тора ала. «Кояш куяннары» артыннан йөгергәндә,

балалар бер-берсенә бәрелмәсен, егылмасын өчен, бу уенны үткәргәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен сакларга һәм «кояш куяны»н балалар тота алырлык җиргә генә юнәлтергә тырышырга кирәк.

Балалар бакчасының уртанчылар төркемендәге дидактик уеннар, нигездә, балаларның хәтерен һәм игътибарын үстерүгә юнәлтелгән.

**«НЫК УЙЛА»** дип аталган уен уртанчылар төркемендә җиңелчәрәк итеп үткәрелә. Өстәлдәге барлык предметларның исемнәрен тәрбияче язып бара. Уен өчен көнкүреш предметлары, геометрик фигуралар һәм төсләрне билгели торган төрле үрнәкләр кулланырга, аларның татар һәм рус телләрендә ничек аталуларын искә төшерергә, исемнәр бирергә мөмкин. Тәрбияче барлык предметларны да тукыма белән каплагач, уйнаучылар өстәлдә нәрсәләр бар икәнлеген искә төшерергә тиеш булалар. Тәрбияче балалар әйткәнне язып бара, җавапларның санына һәм дөрес булуына карап, җиңүче билгеләнә.

Шулай ук бу яшьтәгеләр өчен дидактик уеннар мозаикадан катлаулы булмаган татар бизәкләре, геометрик формалардан көнкүреш предметлары төзүне дә үз эченә ала. Өстәл уеннары ераклыкны дөрес билгеләргә өйрәнү һәм кул хәрәкәтләрен координацияләү өчен кулланыла. Уенның йөреше, тәртибе бозылмасын, балаларның игътибары кимемәсен өчен, дидактик уеннар уйнаганда тәрбияче барысын да контрольдә тота, кирәк вакытта уенны җайлап җибәрә. Шул ук вакытта күрсәтү, аңлату кебек турыдан-туры җитәкчелек итү алымнары да кулланыла.

Балалар бакчасының уртанчылар төркемендә тәрбияче татар халык уеннарын кулланып кына калмый, уенның кайсы урыннары, элементлары аеруча зур кызыксыну уятуын, балаларга нәрсә ошау-ошамавын, нәрсә кыенлык тудыруын карап-күзәтеп тора, аларның кызыксыну дәрәҗәсен ачыклап, уйнау потенциалын үстерә.

Д. Б. Эльконин тикшеренүләре буенча, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның зурлар төркемендә уен оештыруның түбәндәге мөһим этапларын аерып чыгарырга мөмкин:

1. Уенда беренче урында – «башка кешеләргә мөнәсәбәткә бәйле гамәлләр үтәү» (башка кешеләр ролендә – башка балалар)[6].

2. Хәзер инде бала «үз-үзен бертөрле генә тота ала. Балаларның роль функцияләре бер-берсенекенә нык бәйле. Сөйләүче роле аша да, сөйләм юнәлтелгән бала роле аша да сөйләмнәрендә рольләр ачык сизелә»[7].

3. «Балалар уенның төрле персонажлары белән элемтәгә керә алалар»[8].

4. Уенның кагыйдәләрен бозмыйлар, «кагыйдәләрдә каралмаган кирәксез, урынсыз хәрәкәтләр ясамыйлар»[9].

Зурлар төркемендәге балалар уендагы хәрәкәтләрнең, эш-гамәлләрнең үтәлү-үтәлмәвен генә түгел, ә ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен дә тикшереп торалар. Аларга үз рольләрен чын-чынлап һәм тиешенчә, җиренә җиткереп үтәү мөһим. Әмма кайвакыт шартлы рәвештә генә үтәлә торган гамәлләр дә була ала (мәсәлән, «йөреп килгән кебек булу» һ.б.).

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның зурлар төркеменә йөрүчеләрнең уеннары аларның үзләрен чолгап алган мохитне белүен, шартларга җайлашу осталыкларын күрсәтә. Шуңа бәйле рәвештә уенның шартлары да катлаулана бара. Уен

[6] Эльконин Д. Психология игры. М.: Владос, 1999. 360 с.
[7] Шунда ук.
[8] Шунда ук.
[9] Шунда ук.

тагын да төгәлрәк уйнала, хәрәкәтләрнең дөрес үтәлешенә, фразаларның әйтелешенә игътибар ителә башлый. Уенда теге яки бу рольдә иптәшләренә үзләрен ничек тотарга, нәрсә эшләргә, нәрсә әйтергә, нинди предметлар кулланырга кирәклеге турында уйлый-уйлый, балаларның күзаллау осталыклары да үсә. Шуңа күрә, татар халык уеннарын оештыру өчен, зурлар төркеменең уен бүлмәсендә төрле көнкүреш предметлары, милли уенчыклар, иллюстрацияләр, китаплар җитәрлек булырга тиеш.

Зурлар төркемендәге балаларның уен барышында бер-берсе белән аңлашып, уртак фикергә килә алу, үз фикерләрен дәлилләү, төркемдәшләренең сүзләре белән килешү-килешмәүләрен белдерү, рольләрне, уенчыкларны бүлү, алып баручы сайлау осталыкларын үстерүнең мөһимлеге тагын да арта.

### Дидактик уеннар уйнату

Зурлар төркемендә зиһен сынаш уеннарының дидактик әһәмияте тагын да арта. Бигрәк тә кагыйдәле уеннарның:

– өстәл уеннары (зурлар төркемендәге мәктәпкәчә яшьтәге балалар предметларны төс буенча аера (предметның нинди төстә булуын ике телдә – русча һәм татарча әйтә баралар), ел фасылларының билгеләрен саныйлар һ.б.);

– сүзле уеннар («Рәсемдә нәрсә сурәтләнгәнне бел», «Оча», «Җиләк-җимеш базары»).

## РӘСЕМДӘ НӘРСӘ СУРӘТЛӘНГӘННЕ БЕЛ

*Уенның максаты:* балаларның күзаллауларын, игътибарлылыгын һәм лексик байлыкларын арттыру, монологик сөйләмнәрен үстерү.

Рәсемдә нәрсә сурәтләнгәнне балаларга русча да, татарча да сөйләргә кушарга мөмкин, бу аларның ике телдә дә иркен сөйләшү осталыкларын арттырачак. Уен барлык балалар рәсемдә нәрсә сурәтләнгәнне сөйләп бетергәнче дәвам итә.

Төп билгеләрне бик үк мөһим булмаган билгеләрдән аерырга өйрәтеп, уен мәктәпкәчә яшьтәге балаларның фикерләвен үстерергә булыша.

## ОЧА

*Уенның максаты:* зурлар төркемендәге балаларның игътибарлылыгын (ирекле игътибар), реакция тизлекләрен һәм сүзлек байлыгын арттыру.

«Оча» фигыле белән күп тапкырлар уйнаганнан соң, балаларның фигыль запасын арттыру өчен, *бара, чаба, шуыша* кебек башка фигыльләр кулланырга да була. Бу шактый катлаулы тема. Ул хәрәкәтне белдерә торган фигыльләрне истә калдырырга, аларның мәгънәләрендәге аермаларны аңларга, сүзләрне бер-берсе белән дөрес кулланырга өйрәнергә ярдәм итәчәк. Уен келәмгә яки урындыкларга утырган килеш уйнала. Сүзләр тиз-тиз әйтелергә тиеш.

## ҖИЛӘК-ҖИМЕШ БАЗАРЫ

*Уенның максаты:* хәтерне яхшырту, игътибарлылыкны арттыру, сүзлек запасын җиләк-җимеш темасына караган исемнәр белән баету.

Уен безне иҗтимагый тормышның кайнап торган гаҗәеп почмагына – базарга алып китә. Бүгенге заман балалары, сатучыларның сатып алучыларныерактан ук эндәшеп чакырып алып, матур итеп сөйләшә-сөйләшә, үз товарларын мактый-мактый сатуларын белмиләрдер дә әле. Юк икән, бу хакта тәфсилләп язылган әкиятләр ярдәмендә аңлатып үтәргә мөмкин.

Әлеге уенга «фант» дигән төшенчә килеп керә. Оттырган очракта, балалар нәрсә белән булса да түләү тиеш икәнен белсеннәр! Кайсыдыр уенда оттырган кеше берәр этапны яңадан үтәргә тиеш, кайсыдыр уенда очколар, баллар кимetelә. «Җиләк-җимеш базары» уенында исә, башкалар үзе сайлаган җиләк-җимеш исемен атагач, кайсы катнашу-

чы уенны дәвам итә алмый, шул фант бирә. Фантның яки биремнең нәрсә булачагы алдан ук билгеләнеп куела (шигырь укырга, җырларга, биергә, бер аякта сикерергә, нинди дә булса хис-кичерешләрне күрсәтергә, берничә тапкыр чүгәләргә, кемгәдер комплимент әйтергә һ.б.). Фант биремнәре күп вакыт алырлык һәм биремне үтәүчене дә, башка балаларны да кимсетерлек булмасын. Уенны алга таба дәвам итәр өчен, биремнәр кыска һәм гади булырга тиеш.

Турыдан-туры уку-укыту процессына да кертеп җибәрергә, көндәлек режимның башка вакытларында да файдаланырга мөмкин булган уйлап уйнала торган уеннарның (башваткычлар), табышмакларның роле аеруча зур.

Геометрик формалар һәм төрле төстәге предметлар кулланып уйнала торган дидактик күнегүләр аеруча мөһим урын алып тора. Алар ярдәмендә катлаулырак татар орнаментлары төзелә. Кием-салым һәм көнкүреш әйберләрен балалар гадәти татар орнаментлары белән дә бизи ала.

Дидактик уеннар уйнатканда балаларның мөстәкыйльлеген үстерергә, уен белән кызыксынуларын хуплап торырга тырышырга кирәк. Уен кагыйдәләрен яхшы аңлаган баланы күрүгә, тәрбияче аңа алып баручы булырга тәкъдим итә. Соңрак барлык балаларны да алып баручы ролендә уйнатып чыгарга тырышырга кирәк. Алга таба инде алар уеннарны да, алып баручыларны да мөстәкыйль рәвештә үзләре сайлый алачак.

Зурлар төркемендәге балалар арасында ниндидер сәбәпләр аркасында уйный белмәүчеләр дә булырга мөмкин. Бәлки аларның яшьтәшләре белән аралашуда кыенлыклары бардыр яисә аларны уенга катнаштырмыйлардыр. Андый очраклар була икән, тәрбияче балаларның ни өчен уйнамау сәбәпләрен ачыклый һәм барлык балаларны да уенда катнаштыру юлларын эзли, аларны үзара мөгамәлә корырга, дус һәм тату гына бергә уйнарга өйрәтә.

Зурлар төркемендә уйнала торган татар халык уеннарының күпчелегендә билгеле бер биремнәрне, эш-гамәлләрне үтәмәгән өчен фант бирү (нинди дә булса өстәмә бирем үтәү) каралган. Күбесенчә фантлар дидактик уеннар барышында кулланыла, әмма «Фант уены» дигән аерым уен да бар.

Тәрбияче «Фант уены»нда тәкъдим ителгән фантларны (биремнәрне) кулланырга яисә, уйнаучылар белән киңәшеп, үз биремнәрен тәкъдим итәргә мөмкин. Иң мөһиме, фантлар белән уйнау балалар тарафыннан ниндидер бер шаяру, уен кебек кабул ителсен һәм алар өчен катлаулы булмасын иде.

Уен-көлкегә корылган күңел ачу уеннары аерым игътибарга лаек.

## КӨЛДЕРҮЧЕ

*Уенның максаты:* позитив эмоциональ фон булдыру.

Физик, танып белү һәм рухи үсешкә үтә сизгер затлар буларак, балалар һәрдаим уңай атмосферага мохтаҗ. Әлеге уен балаларда яшьтәшләренә карата дусларча мөнәсәбәт, сабырлык тәрбияли (күңел ачуга корылган күмәк уеннар балалардан бер-берсе белән дә, өлкәннәр белән дә аралашу кагыйдәләрен үтәүне таләп итә). «Көлдерүче» уены уку-укыту процессын җанландырып җибәрә һәм балаларның төрле шөгыльләре арасында бәйләүче чара булып хезмәт итә.

## КАЧЫШ-ТАБЫШ

*Уенның максаты:* балаларның игътибарлылыгын арттыру, хәтерләрен яхшырту, йөгерек сөйләшергә өйрәтү.

Бу уенны Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм алардагы әһәмиятле, данлыклы урыннар турында әңгәмәдән башлап җибәрергә мөмкин. Уен вакытында катнашучылар алып баручыга сораулар бирә. Әлеге сораулар «әйе» яки «юк»

дип җавап бирә алырлык булырга тиеш. Бу дөрес итеп сорау бирергә һәм, сорауның төренә карап, дөрес һәм урынлы җавап бирергә өйрәтә. Әлеге уенны әйләнә-тирә дөнья белән таныштыруга, туган якны өйрәнүгә багышланган дәресләрдә, чараларда кулланырга мөмкин. Нәтиҗәдә, балаларның үзләре яши торган урын турындагы белемнәре, патриотик хисләре арта.

Уенны оештырганда балаларга таныш символика куллану яхшы нәтиҗәләр бирә. Балалар белән берлектә, тәрбияче үзе дә төрле предметларның модельләрен ясап куя ала. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар үзләрен чолгап алган бар нәрсәне дә сүз белән генә түгел, график яктан да билгеләргә мөмкин булуын күрәчәк. Мисал өчен:

– бала яшәгән йорт, урам, ул йөри торган балалар бакчасының һ.б.ның урнашу схемасын ясау;

– баланың бакчага йөри торган маршрутын төзү;

– шәһәрдәге мөһим урыннарны – кибетләр, цирк, зоопарк, музейларны һ.б.ны билгеләү өчен бергәләшеп шартлы билгеләр уйлап табу.

Схемалар ясау барлык балаларга да үзләре яшәгән урынны, өйләреннән бакчага килү юлларының озынлыгын билгеләргә һәм траекторияләрне чагыштырырга ярдәм итә.

## Хәрәкәтле татар халык уеннарын уйнату буенча киңәшләр

Зурлар төркемендәге балалар өчен хәрәкәтле уеннарны ике блокка бүлеп була:

### *1. Хәрәкәтле сюжетлы татар халык уеннары*

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның зурлар төркеменә йөрүчеләрнең әйләнә-тирә мохит, кешеләр һәм хайваннар тормышы турында күпмедер белемнәре һәм күзаллаулары бар инде. Алар хайван һәм кош тавышларына охшатып

«сайрарга», кычкырырга, нинди рольдә уйнауларына карап, интонацияләрен, йөрешләрен, үз-үзләрен тотышларын үзгәртергә мөмкиннәр. Билгеле булганча, хайваннарның кайбер сыйфатлары аларның даими билгеләренә үк әверелгән (мәсәлән, төлке хәйләкәр, куян куркак). Нәкъ менә шундый сыйфатлар уен сюжетын үстерү өчен нигез булып тора да инде. Уен кагыйдәләрен дә балалар үзләре билгели.

Беренче планда – хайваннарның үз-үзләрен тотышларын күрсәтү, алар кебек йөрү, сикерү, кычкыру, яту һ.б.

## ЯҢАЧА МӘЧЕ ҺӘМ ТЫЧКАН УЕНЫ

*Уенның максаты:* балаларның игътибарлылыгын арттыру, фикер киңлеген, логик фикерләвен үстерү.

Беренче карашка әлеге уен аз хәрәкәтле булып тоелырга мөмкин. Ул никадәр тизрәк уйнала, шулкадәр кызыграк. Аны төркемнең саф һавадагы мәйданында да, урын иркен булган очракта, кабинетта да уйнарга була. Әлеге уен элементар математик күзаллауларны үстерү өчен әзерлек этабы булып тора, чөнки балаларга пространстволы күзаллауларны яхшырак үзләштерергә ярдәм итә.

## БҮРЕ

*Уенның максаты:* җитезлек, игътибарлылык, җәһәтлек, өлгерлек сыйфатларын үстерү.

Уен авыл халкы тормышыннан бер сюжетны – сарыклар көтүенә бүре һөҗүм иткән вакытны күз алдына китереп бастыра. Бүре кагылган икән, сарык тотылган дип санала. Шунысы игътибарга лаек: гадәттә балаларның күбесе бүре булып уйнарга тели. Ә инде теләүче табылмый икән, аны шобага салып яисә санау ярдәмендә сайларга кирәк. Уен саф һавада уйнау өчен яхшы. Күпмедер уйнагач, «бүре чокырда» дигән вариант тәкъдим итеп, уенны бераз үзгәртергә дә мөмкин. Моның өчен җирдә ике сызык сызыла. Сызыклар

арасында – бүре йөгерә торган чокыр. Сарыклар шул чокыр аша бер яктан икенче якка сикерәләр. Иң мөһиме, балалар алып баручы әйткәннән соң гына йөгерә башларга тиеш.

### ПОЧМАКЛАР

*Уенның максаты:* тизлек, өлгерлек сыйфатларын үстерү, бер-берсе белән сөйләшеп килешергә өйрәтү (алып баручыга сиздерми генә, почмак алыштыру турында уенчылар тиз арада үзара килешеп алырга тиешләр).

Уен катнашучылар арыганчы дәвам итә ала. Арыганлык билгеләре – сүлпәнлек сизелү, уенчыларның тизлеге кимү, тыннары бетү, уенны дәвам итү теләкләре булмау. Бу очракта балаларны ял иттереп алырга кирәк. Ә инде уен физкультура дәресендә саф һавада уздырыла икән, уенчыларга төрлечә хәрәкәт итәргә (туктый-туктый йөрү, сикергәләп йөрү һ.б.) кушарга мөмкин. «Йорт» итеп мәйданчыкта үсә торган агачларны кулланырга яки җирдә түгәрәкләр ясарга, спорт залында уйнаган очракта, идәнгә коршаулар, бөҗралар куярга була. Балаларга алдан ук аңлатып куярга кирәк: алып баручы уйнаучыга кулын тидереп ала икән, бу инде ул тотылган дигән сүз. Чөнки уйнау барышында төрле хәлләр булырга мөмкин (алып баручы уйнаучыга ябышкан һәм аны җибәрмәскә тырыша, ә тегесе ычкынырга тели һ.б.). Мондый очракта уенны туктатып, кагыйдәләрне тагын бер тапкыр аңлатып алу сорала.

### *2. Хәрәкәтле сюжетсыз татар халык уеннары*

Хәрәкәтле сюжетлы уеннарда балалар төрле хайваннарга охшатып, аларның холык-фигыльләрен, үз-үзләрен тотышларын кабатларга, шул хайваннарга хас авазларны чыгарырга тырышсалар, хәрәкәтле сюжетсыз татар халык уеннарында да шул рәвешле рольгә туры китереп уйнау дәвам итә. Димәк, бу ике төр уеннар бер-берсенә охшаган, бары тик

икенчеләрендә сюжет кына юк. Болар «Тот, тот», «Житез бул», «Коткаручы таяк», «Узышчылар», «Качыш-табыш», «Бер аяк белән көрәш» һәм башка уеннар.

**«БЕР АЯК БЕЛӘН КӨРӘШ»** уены ярдәмендә мәктәпкәчә яшьтәге балалар ярышларда, Сабантуйда катнашырга өйрәнәләр. Тик бу уенны кыш көне урамда уйнау яхшырак. Балалар бер-берсен этәргә тиеш булганлыктан, кышкы киемнәрдән йомшак карга егылу алар өчен бернинди куркыныч тудырмас, киресенчә кызык кына булыр.

## ТӨЗӘГЕЧКӘ ТИДЕР

*Уенның максаты:* ераклыкны күз белән чамаларга өйрәтү, хәрәкәт координациясен үстерү, моториканы яхшырту.

Тимерчыбыктан ясалган бөҗра урынына баскетбол кәрҗинен элеп куярга мөмкин. Кәрҗингә ташлый торган предметлар төрле зурлыкта һәм формада булса яхшырак. Ул очракта балалар төрле авырлыктагы предметларны кәрҗингә кертерлек итеп ташларга, ягъни, ташлау юнәлешен һәм үз көчләрен дөрес исәпләргә өйрәнәләр.

## КОТКАРУЧЫ ТАЯК

*Уенның максаты:* тизлек, өлгерлек сыйфатларын үстерү, игътибарлылыкны арттыру.

Уенны башта алып баручы сыйфатында тәрбияче башлап җибәрә. Аннары уенчыларның берсе алып баручы итеп сайлана. Уен барышында качарга һәм качкан кешене эзләп табарга кирәк, шунлыктан әлеге уенны качар урыннары булган иркен кабинетларда, бүлмәләрдә үткәрү яхшы.

## УЗЫШЧЫЛАР

*Уенның максаты:* балаларның тизлек, өлгерлек сыйфатларын үстерү, хәрәкәтчәнлекләрен арттыру.

Узышу өчен пар билгеләгәндә, тәрбияче һәр баланың хәрәкәтчәнлеген, тизлеген исәпкә алырга тиеш. Чагыштырмача бердәй тизлек белән йөгерүчеләрне түгел, ә әкрен бала белән җитез баланы парлаштырган очракта, балаларның мотивациясе булмаячак, әкрен йөгерүче бала тиз йөгерүче иптәшенең үзеннән алда барып җитәчәген белеп, беренче булырга тырышмаячак та, «барыбер мине узачак инде» дип, узыша башлаганчы ук «җиңеләчәк». Уен өчен узыш атрибутлары – кечкенә флаглар куллану яхшы.

Хәрәкәтле сюжетсыз татар халык уеннарын оештыру процессында шуны истә тотарга кирәк: әлеге уеннар сюжетлы уеннар белән чагыштырганда күбрәк мөстәкыйльлек, өлгерлек, җитезлек таләп итә. Кагыйдәләрне үтәү мәҗбүри шарт булып тора.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның зурлар төркемендә әйлән-бәйлән уеннары аеруча зур урын алып тора. Мисал өчен, **«МӘРЬЯМ ӘБИ МАЛАЙЛАРЫ»** уены шундыйлардан.

Әйлән-бәйлән уйнау өчен түгәрәк ясау үзе үк балаларны күп нәрсәгә өйрәтә. Һәр баланың түгәрәкнең үзәгенә бердәй ераклыкта басуы аларга барысының да тигез икәнлеген тоярга ярдәм итә. Кулга-кул тотынышып түгәрәк буйлап йөргәндә балалар кагыйдәләргә һәм музыкага туры китереп атлауның мөһимлеген аңлыйлар. Түгәрәкнең тулы, төгәл булуы һәр баланың ничек йөрүеннән тора бит. Моны аңлау балаларда җаваплылык хисен арттыра, барысының да бер үк хәрәкәтләр, бер үк уртак эш башкаруы төркемне тагын да дус, бердәм итә.

«Мәрьям әби малайлары» – музыкаль-ритмик уен. Түгәрәк буенча йөреп, балалар музыка тактына өстәмә хәрәкәтләр

ясыйлар. Уен музыканы тыңларга, ишетергә өйрәтә, хәрәкәт координацияләрен яхшырта. Шаян һәм көлкеле булганлыктан, бу уен балаларның күңелләрен күтәрә, аларга ачылырга мөмкинлек бирә.

Татар халык уеннары хәзинәсендә билгеле бер шөгыльдән, эшчәнлектән ял иттерә торган уеннар да бар. Шундыйларның берсе – «Музыканы нык тыңла» уены иркен мәйданда үткәрелә (кабинетта, мәйданчыкта). Бу уен барышында музыкаль инструмент кулланырга да, музыкасыз гына җырларга да мөмкин. Уенның максаты – музыкаль ишетү сәләтен үстерү, музыканы игътибар белән тыңларга, аңларга өйрәтү. Бу уен балалар нинди дә булса шөгыльдән арыган вакытта, аларны ял иттереп алу өчен үткәрелә ала.

Музыка кулланып уйнала торган уеннарның тагын берсе – **«ТАВЫШСЫЗ МУЗЫКА»**.

*Уенның максаты:* балаларны татар халык музыка уен кораллары белән таныштыру, күзаллауларын, актерлык осталыкларын үстерү.

Әлеге уенның кыйммәте шунда: ул татар халкының музыка уен кораллары белән таныштыра. Дирижерның роле аеруча җаваплы: аңа барлык музыка уен коралларының ничек яңгыравын күз алдына китерергә һәм әлеге инструментларның барысы да оркестрга кушылырлык итеп дирижерлык итәргә тырышырга кирәк. Димәк, балаларны алдан ук татар халык музыка кораллары белән таныштырып куярга, алай гына да түгел, аларда тавыш чыгарып, уйнап карарга мөмкинлек бирергә кирәк. Алга таба татар халкының музыка уен коралларын кечкенә концертлар, чаралар, бәйрәмнәр оештырган вакытта да файдаланырга мөмкин.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме**

Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының рольләре, уен хәрәкәтләре, кагыйдәләре дә күбрәк, тематикалары да күптөрле. Рольләрне тәрбияче бүлеп бирә торган зурлар төркеменнән аермалы буларак, мәктәпкә әзерлек төркеме балаларында оештыру сәләте барлыкка килә, лидерлык сыйфатлары сиземләнә.

Уен башланганчы ук балалар бер-берсе белән килешеп, рольләрне бүлә, планнар кора, уенчыклар сайлый башлый. Кагыйдәләр төгәл үтәлсен дип, алар уен барышын игътибар белән күзәтеп баралар. Шуңа күрә аларның «менә шулай дөрес була» яки «алай эшләргә ярамый» дигән сүзләрен еш ишетергә мөмкин. Уйнау өчен тупланган төркемнәр дә гомуми кызыксынулар нигезендә оеша.

Татар халык уеннарын мәктәпкә әзерлек төркеменең уку-укыту эшчәнлегенә кертү буенча тәрбияченең бурычлары:

– мөстәкыйль рәвештә уен барышын уйлап таба белү күнекмәләрен үстерү; уеннарда татар көнкүрешенә, татарларның традицион шөгыльләренә бәйле сюжетлар кулланырга өйрәтү; татар халык дидактик уеннарын катлауландырырга, аларга яңа элементлар кертергә мөмкин;

– балаларны уен барышында төркемдәшләрен тыңларга, башкалар фикерен исәпкә алырга, килешергә мөмкин булган конфликтларны тыныч хәл итәргә өйрәтү;

– балаларның яңа уеннар үзләштерүгә кызыксынуларын үстерү;

– танып белүгә кызыксыну уяту, оештыру күнекмәләрен формалаштыру. Танып белүгә кызыксыну уяту өчен төркемнең предметлы-уенлы үстерелеш мохите милли символикалы предметларга баетыла;

– лидерлык сыйфатларын, оештыру осталыкларын камилләштерергә ярдәм итү;

– һөнәрләр турындагы белемнәрен арттыру һәм аларны уеннарда куллану. Балаларны Татарстандагы традицион профессияләр белән таныштыру;

– кагыйдәләрне үтәргә өйрәтү. Кагыйдәләрне рус телендә дә, татар телендә дә бирергә мөмкин;

– чын предметлар һәм аларны алыштыра торган предметлар кулланып, уен мохите булдыру. Татар халык уеннарында кулланыла торган чын булмаган, уенчык предметларны балалар белән бергәләшеп ясарга да була;

– ир-ат һәм хатын-кыз рольләре турында искә төшерү, булган белемнәрне ныгыту. Уйнау барышында әлеге рольләрне дөрес бүлә белсеннәр, малайлар – ир-ат, ә кызлар хатын-кыз башкара торган эш-хәрәкәтләрне үтәсеннәр өчен шартлар тудыру (әлеге бурычларны үтәүдә татар халык уеннарын куллану бик нык ярдәм итәчәк, чөнки уйный-уйный балалар үзләре дә сизмәстән тормышта, көнкүрештә ир-ат һәм хатын-кыз рольләренә әзерләнә, алар башкарырга тиешле эшләргә (бала карау, ашарга пешерү, машина йөртү һәм башкалар) керешеп китә;

– балаларга кайбер әхлак нормаларын үзләштерергә ярдәм итү. Татар халык уеннарында – халкыбызның гасырлар буе туплаган тәҗрибәсе, төпле акылы. Ныклы әхлакый нигезе булган әлеге уеннар баланы әйләнә-тирә дөнья белән гармониядә булырга өйрәтә;

– уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү.

Мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбиятченең уендагы роле көннән-көн кими бара. Татар халык уеннарын уку-укыту һәм

тәрбия процессына керткәндә, балаларның инде үзләре оештырган кечкенә төркемнәре булуын исәпкә алу, куркыбрак, оялыбрак торган балаларны да уенга җәлеп итү, кагыйдәләрне үтәүнең мөһимлеген ассызыклау, уенны үзләренә сайларга һәм төрле вак мәсьәләләрне үзара килешеп хәл итәргә мөмкинлек бирү аеруча мөһим.

Татар халкының сюжетлы-рольле уеннарын мәктәпкә әзерлек төркемендә уйнатканда, тәрбияче балаларның төрле вакытта төрле рольләр алырга тиешлеген онытып җибәрмәсен иде (мәсәлән, «Очучылар» уенында рольләр бик күп, вакыт-вакыт балалар рольләрен алмашып торырга, уен барышында үз сюжетларын тәкъдим итәргә дә мөмкиннәр).

## ОЧУЧЫЛАР

*Уенның максаты:* балаларны команданы үтәргә, тиз арада сафка (яки билгеле бер тәртиптә) тезелергә яисә таралырга өйрәтү.

Әлеге уенны оештыру өчен «очкыч төшә торган урын»ны һәм очкыч ташыячак «йөкләр»не әзерләп куярга кирәк. Уйнаучыларның вазифалары артсын, эшләре катлаулана төшсен өчен, уен барышында биремнәрне үзгәртеп торырга да була.

Уен шулай ук патриотик хисләрне, миһербанлык, шәфкатьлелек сыйфатларын үстерергә дә ярдәм итә (яралыларга дарулар китерү, яраларын бәйләү сюжетын керткән очракта). Ул ил тарихы белән кызыксыну уята, очучылыкка бәйле кайбер һөнәрләр турында беренчел күзаллаулар формалаштырырга ярдәм итә.

## КЫЗЫЛАРМИЯЧЕЛӘР

*Уенның максаты:* тиз арада сафка тезелү яки таралу күнекмәләрен ныгытырга, командаларны тиз һәм төгәл үтәргә өйрәтү.

«Кызылармиячеләр» уенын оештырыр алдыннан тәрбияче балаларга кызылармиячеләр турында мәгълүмат биреп үтә. Биремнәрнең физик сыйфатларны үстерүгә юнәлтелгәннәрен генә түгел, катлаулыракларын да бирергә мөмкин (мәсәлән, килешә белү, үзара вазифаларны бүлешү һ.б.). Уенны оештыру өчен уйный торган тирәлекне дә бераз үзгәртергә, биремнәрне үтәү өчен берничә киртә оештырып куярга кирәк. Тәрбияче әлеге киртәләрнең, каршылыкларның балалар өчен куркынычсыз булуын тәэмин итәргә һәм, балаларның кызыксынулары кимемәсен өчен, даими рәвештә уенның барышын күзәтеп торырга тиеш. Уенны бераз үзгәртергә һәм аңа заманча һөнәрләр белән бәйле исем бирергә дә була («Солдатлар», «МЧС хезмәткәрләре» һ.б.). Бу уенда балаларның күбесе командир булырга теләячәк, шуңа күрә аларга рольләрне бүлүнең төрле ысулларын алдан ук өйрәтеп куярга кирәк (шобага салу, санау ярдәмендә һ.б.).

«Кызылармиячеләр» уенында ярдәмләшү элементларын үз эченә алган биремнәр, «Очучылар» уенында «яралыларны» госпитальгә китерү кебек биремнәр куллану да балаларда кирәкле әхлакый сыйфатлар формалаштырырга ярдәм итә.

Мәктәпкә әзерлек төркемендә балалар белән хәрәкәтле татар халык уеннары оештырганда, тәрбиячегә түбәндәгеләрне белергә кирәк:

– балаларны уеннарны мөстәкыйль рәвештә сайларга һәм кирәк очракта аларны үзгәртеп уйнарга өйрәтү;

– уенның кагыйдәләрен үтәп уйнау омтылышы формалаштыру;

– уенның барышын һәм нәтиҗәләрен гадел бәяләү теләген үстерү;

– хәрәкәтле татар халык уеннары белән кызыксынуларын арттыру;

– яңа татар халык уеннары өйрәнү теләге уяту. Мисал өчен, балалар туганнарының нинди уеннар уйнап үсүе белән кызыксына алалар.

Хәрәкәтле татар халык уеннарына түбәндәгеләрне кертергә мөмкин: «Туп яшереш», «Карга», «Буш урын», «Әтәч кычкырды», «Йөзек табу», «Арт белән узыш», «Бер аяк белән көрәш», «Очучылар», «Ишкән баулар», «Күз бәйләү», «Тот, тот», «Бербереңә әйбер тапшыру», «Узышчылар», «Почмаклар», «Җитез бул», «Коткаручы таяк», «Төзәгечкә тидер». Әлеге уеннарның кайберләре аз хәрәкәтле булса да, күпчелеге шактый иркен уен мәйданы, югары темп, тизлек, җитезлек таләп итә.

Бу яшьтәге балалар үзләрен чагыштырмача иркен тотсалар да (мәктәпкә әзерлекнең тагын бер критерие), әлеге күнекмәләр тиешенчә формалашып җитмәгән, балаларның үз-үзләрен тотышлары һәм реакцияләре әле һаман да импульсив булып кала бирә. Димәк, әлеге төркемдә кагыйдәле уеннарга зур игътибар бирелергә тиеш. Психологик-педагогик күзәтүләр күрсәткәнчә, нәкъ менә кагыйдәле уеннарны үзләштерү әлеге зурлар төркемендәге балаларның мәктәптә укырга әзерлегенең мөһим күрсәткече булып тора да инде. Ярышу, узышу, белем сынашуны таләп итә һәм балаларда кызыксыну уята торган татар халык уеннары шундыйларга керә. Уеннарның әлеге төрләре мәктәпкә әзерлек төркемендәге кагыйдәләргә туры килерлек эш-гамәлләр кылырга өйрәтә. Күзәтүләр буенча, кагыйдәле уеннарны җиңел үзләштергән балалар мәктәптә укыганда да югарырак нәтиҗәләр күрсәтә.

## ТУП ЯШЕРЕШ

*Уенның максаты:* балаларның күзәтүчәнлеген, җитезлеген үстерү, тиз хәрәкәтләнергә, туры итеп ыргытырга, түзем булырга өйрәтү.

Бу уенда командалар формалаштыруның гадәти булмаган ысулы тәкъдим ителә: уенчылар үзләренә пар табарга

һәм кемнең кем булуын үзара килешеп хәл итәргә тиешләр (балаларның берсе – бер предмет, икенчесе – шуңа охшаш предмет, мәсәлән, берсе – көмеш, берсе – алтын, берсе – зәңгәр чәчәк, икенчесе – алсу чәчәк һ.б.).

Аннан соң балалар парлап беренче капитан янына киләләр һәм аңардан: «алтынмы, көмешме?» – дип сорыйлар. Капитан «алтын» дисә, уен башында кайсы бала «алтын булам» дигән иде, шунысы аның ягында кала, икенчесе башка командага китә. Шулай итеп бөтен уйнаучылар икегә бүленеп бетә. Әлеге сөйләшүләр, килешүләр балаларның актив сүз запасын арттыра, иҗади сәләтләрен, күзаллауларын үстерә.

Уен урамда яки спорт залында үткәрелә. Тупны башка уенчыга сиздермичә генә тапшырырга кирәк булганлыктан, уен балаларны үзләренең эш-хәрәкәтләрен җайга салырга өйрәтә. Уен малайлар өчен каралган, әмма аңа кызлар да кушыла ала. Иң мөһиме, тигән вакытта авырттырмасын, имгәтмәсен өчен, туп йомшак материалдан булырга тиеш (чүпрәк яки резин туп куллану яхшы). Күп балалар катнаша алу уенның тагын бер уңай ягы булып тора.

## КАРГА

*Уенның максаты:* балаларны җитез булырга, төгәл һәм уйланылган хәрәкәтләр ясарга өйрәтү.

Уенда 7–8 кеше катнаша. Аны балалар бүлмәсендә дә, урамда да уйнарга була. Иң мөһиме, уенны башлаганчы ук, кайсы очракларда карга чебешне «тотты» дип саналуын (кулы белән тигәчме, әллә тоткач, эләктергәчме) һәм кайсы вакытларда (тавык, тотучыга тидерерлек итеп, канатлары белән кагынгандамы) карганың чебешләргә якынлаша алмавын балалар белән сөйләшеп куярга кирәк. Уен шактый экспрессив, шуңа күрә тәрбияче балаларны да, кагыйдәләрнең үтәлешен дә бик нык игътибар белән күзәтеп торырга тиеш.

## БУШ УРЫН

*Уенның максаты:* балаларның хәрәкәт тизлеген, җитезлеген арттыру.

Уен урамда – балалар мәйданчыгында уйнала. Катнашучыларның саны алтыдан да ким булмаска тиеш. Уйнаучылар күбрәк булган саен күбрәк йөгерергә туры киләчәк. Балаларның аркаларына нәрсә белән һәм ничек тамга салуны уен башында ук хәл итеп куярга кирәк. Түгәрәк буенча йөгергәндә уйнаучыларның бәрелешү ихтималын күздә тотып, тәрбияче балаларны дикъкать белән күзәтергә, куркынычсызлык кагыйдәләрен саклауны контрольдә тотарга тиеш.

## ӘТӘЧ КЫЧКЫРДЫ

*Уенның максаты:* балаларның өлгерлеген, хәрәкәт тизлеген, җитезлеген арттыру.

Бу уенны балаларның йокы бүлмәсе дә уен зонасы итеп файдаланыла ала торган төркемнәрдә уйнарга була. Уенда кызлар да, малайлар да катнашырга мөмкин. Уен көннең икенче яртысында уйнала. Уен барышында балалар урындыкларны аударып та җибәрергә мөмкин, шуңа күрә алар шактый нык булырга тиеш. Шулай ук балаларны этешмичә, төртешмичә уйнарга өйрәтергә тырышырга кирәк. Урындыксыз калган бала нинди дә булса бирем үти (шигырь сөйли, җыр җырлый).

## ЙӨЗЕК ТАБУ

*Уенның максаты:* балаларның җитезлеген, өлгерлеген арттыру, төгәл һәм уйланылган хәрәкәтләр ясарга өйрәтү.

Уен аз хәрәкәтле. Аны балаларның кулларын ял иттереп алырга кирәк булган вакытларда төркем бүлмәсендә дә үткәрергә була. Бožра һәм озын бау кирәк булачак. Йөзекне

биргән кыяфәт ясап, балалар хәйләләргә һәм, киресенчә, йөзекне бирүләрен сиздермәскә мөмкиннәр. Бу үз-үзеңне тотарга, тиешле вакытта сабыр, түзем булырга, ситуациягә карап фикер йөртергә, эш-гамәл кылырга өйрәтә.

## АРТ БЕЛӘН УЗЫШ

*Уенның максаты:* хәрәкәт координациясен, җитезлекне, күзаллауны үстерү, урынга җайлашырга өйрәтү.

Әлеге уенны зур бүлмәдә уйнарга мөмкин. Уйнаучыларның артында бер метр чамасы биеклектә нечкә җеп сузып куела. Команда буенча уйнаучылар артлары белән артка таба йөгерә башлыйлар. Җепне өзгән уенчы җиңгән санала. Уен бик күңелле үтә. Ул йөгерүнең гадәттәгечә булмавы белән дә кызык.

## ИШКӘН БАУЛАР

*Уенның максаты:* балаларның игътибарлылыгын, хәрәкәт тизлеген арттыру.

Эчтәлеге белән әлеге уен «Буш урын» уенына охшаган, тик биредә өстәмә реквизит – кыска бау яки яулык кирәк була. Тагын бер аермасы – монда балалар чүгәләп утыра. Шуңа, аяклары арымасын өчен, «Ишкән баулар» уенын озак уйнарга ярамый. Гомумән, башка уеннарда да, балалар күп вакыт бер торышта гына булмасын яки бөтенләй хәрәкәтсез тормасын өчен, активлыкны гел контрольдә тотарга кирәк.

Мәктәпкә әзерлек төркемендә хәрәкәтле татар халык уеннары уйнатуның үз мантыйгы бар:

– нинди уен уйнау, уенның башлануын белдерү өчен нинди сигнал (кыңгырау, шөлдерле барабан яисә, уен спорт чаралары белән бәйле булган очракта, сыбызгы) куллану турында балалар белән алдан ук сөйләшеп кую мөһим. Бу очракта балаларның кайсы канал (визуаль, аудиаль, кинестетик) аша

яхшырак кабул итүен исәпкә алырга кирәк. Уйнаучыларны уенга җыю эшен берничә балага кушарга мөмкин. Иң мөһиме, җыелу процессы озакка сузылмасын, алайса балаларның уйнарга теләкләре дә сүнәргә мөмкин;

– татар халык уеннары оештыру өчен кирәкле атрибут һәм әсбапларны алдан ук әзерләп куярга кирәк;

– тәрбияче кирәкле атрибутларны балалар һәм әти-әниләр ярдәмендә үзе дә әзерләргә мөмкин. Мисал өчен, «Почмаклар» һәм «Җитез бул» уеннары өчен кирәк әйберләрне балалар белән дә ясап була.

Уен шартларын аңлатканда балаларны дөрес урнаштыру аеруча мөһим. Күп кенә хәрәкәтле татар халык уеннары мәйданны интенсив куллануга бәйле. Шул ук вакытта, барлык катнашучылар да тәрбиячене яхшы күрергә һәм ишетергә тиеш. Уеннарны аңлатканда, иң элек аның исемен рус һәм татар телләрендә әйтергә, рольләрнең үзенчәлеген аңлатырга, катнашучыларның мәйданчыкта ни рәвешле урнашуын күрсәтергә, уен барышын аңлатып бирергә, кагыйдәләрне үтәмәгән өчен җәза билгеләргә кирәк (бу йөрешнең күчүе, бирем үтәү һәм башкалар булырга мөмкин).

Мәктәпкә әзерлек төркемендә уенны алып баручы булып гадәттә балалар үзләре сайлана. Яңа уеннарда тәрбияче алып баручы булырга мөмкин.

Гендер тәрбия мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен аеруча мөһим, шуңа күрә, рольләрне, биремнәрне бүлгәндә, тәрбияче әлеге үзенчәлекләрне һичшиксез исәпкә алырга тиеш.

Балаларны уен кагыйдәләрен үтәргә өйрәтү зур бурычлардан санала. Кагыйдәләрне үтәмәгән өчен җәзалау алымын түгел, ә аларны үтәгән өчен мактау алымын куллану яхшы нәтиҗәләр бирә. Балалар бер уйнауда ук кагыйдәләрне истә калдырып, үзләштереп өлгермиләр яки уен барышында мавыгып онытып җибәрәләр икән, моның өчен шелтәләргә кирәкми. Йомшак, ягымлы тон белән кагыйдәләрне үтәүнең

мөһимлеген искә төшерергә һәм уйнаганда җитез, өлгер, тапкыр булулары өчен мактап алырга мөмкин.

Хәрәкәтле татар халык уеннары уйнау барышында кызулана, катлаулана барырга тиешләр. Көндезге йокыдан соң тизлек, җитезлекне арттыру, хәрәкәтне координацияләүгә юнәлтелгән хәрәкәтле уеннар уйнату киңәш ителми.

Бик күп йөгерү, сикерүне таләп итә торган уеннарны («Туп ящереш», «Карга», «Буш урын», «Әтәч кычкырды», «Очучылар», «Ишкән баулар», «Күз бәйләү», «Тот, тот», «Бер-береңә әйбер тапшыру», «Узышчылар», «Почмаклар», «Җитез бул», «Коткаручы таяк», «Төзәгечкә тидер») өч тапкыр гына кабатларга ярый, ә «Йөзек табу» кебек салмак, әкрен уеннарны бер-бер артлы 4–6 тапкыр уйнарга да мөмкин. Шул ук уенны яңадан кабатлар алдыннан, әз генә паузалар ясап (мәсәлән, сүзләр әйтешеп, шигырьләр сөйләп), балаларны ял иттереп алу яхшы.

Уен тәмамланганнан соң, балалар белән сөйләшеп (уен ошаганмы, юкмы; кем бөтен кагыйдәләрне дә үтәгән, кайсы бала уен хәрәкәтләрен яхшырак башкарган, кем иптәшләренә булышкан һәм башкалар) кыска гына йомгак ясап алырга мөмкин. Икенче тапкыр уйнаганда җиңү яулау, тагын да яхшырак нәтиҗәләргә ирешү өчен нәрсә эшләргә кирәклеген ул очракта инде балалар үзләре үк әйтеп бирә алачак.

Театральләштерелгән татар халык уеннарын мәктәпкә әзерлек төркеменең уку-укыту, тәрбия бирү процессына кертү мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйльлеген үстерүгә юнәлдерелгән; театральләштерү өчен мөстәкыйль рәвештә әсәр сайлау (яисә берәр төрле хәрәкәтле яки дидактик уенны үзгәртеп куллану), үзара рольләр бүлешү, реквизитлар әзерләү, эмоцияләрне белдерергә, персонажның үз-үзен тотышын һәм холкын уйнарга, интонация сайларга өйрәнү аларда аеруча зур кызыксыну уята.

Татар халык уеннарының күпчелеген мәктәпкә әзерлек төркеменең уку-укыту, тәрбия процессына кертергә мөмкин. Балалар элек өйрәнгән «Оча», «Җиләк-җимеш базары», «Табышмаклар», «Фантлар», «Рәсемдә нәрсә сурәтләнгәнне бел» уеннарын да бик яратып уйнауларын дәвам итәләр.

Бу яшьтә балаларны актив рәвештә мәктәптә укуга әзерлиләр, шуңа күрә сүз байлыгын, сөйләм күнекмәләрен арттыру, үзләрен дөрес тотуга юнәлтелгән уеннар бик мөһим.

Күзаллауны, фантазияне үстерергә ярдәм итә торган «Дөньяда юк хайван», «Хикәя», «Фантлар» уеннары файдалы.

Әзерлек төркемнәре өчен балаларның сөйләмен үстерә торган татар халык уеннары бик күп. Фонематик кабул итү, актив һәм пассив сүз запасын арттыру, бәйләнешле диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү өчен «Игезәк иҗекләр», «Күп мәгънәле сүзләр», «Ни өчен һәм шуның өчен (чөнки)», «Бер хәрефле сүзләр», «Өч сүз» уеннары файдалы. Әлеге уеннарның кыйммәте шунда ки, аларны төрле телләрдә уйнарга мөмкин. Бу очракта сүзләрне өйрәнү процессы җиңел һәм кызык булачак, лексик материал тагын да яхшырак үзләштереләчәк. Сүзләрне истә калдырырга ярдәм итә торган уеннарны даими рәвештә бер-бер артлы берничә тел материалын кулланып уйнаган очракта, бала үзе өчен табигый тирәлектә – уен мохитендә үк берничә телнең нигезләрен үзләштерә дигән сүз.

Татар халык уеннары арасында балаларга иҗат дәрте өсти, аларны илһамландыра, яңадан-яңа ачышларга этәрә торган музыкаль уеннар аерым игътибарга лаек. Халык җырлары, милли музыкаль уеннарыбыз аша мәктәпкәчә яшьтәге балалар татар халкының мәдәнияте белән таныша.

Балаларга сәнгать тәрбиясе бирүдә җыр-музыка ысулын куллану һәрвакыт актуаль булып кала бирә. Җырлы-биюле уеннар нәниләрнең күңелләренә халык моңнарын сеңдерә,

аларның иҗади фикерләвен, күзаллавын үстерә, сәнгать образларын аңларга, дөньяны музыка аша тагын да матуррак кабул итәргә өйрәтә.

«Музыканы нык тыңла», «Белмәсәң, үзең җырларсың», «Тавышсыз музыка» уеннарын уйный-уйный да балалар үзләре өчен күпме яңалык ача. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: уенда кулланыла торган музыкаль әсәрләр балалар тарафыннан бербөтен буларак кабул ителергә тиеш. Шул ук вакытта, уен кагыйдәләренә бәйле рәвештә, тege яки бу музыкаль тәэсирлелек чараларын аерып күрсәтергә дә кирәк булачак.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТЕ ТАРИХЫННАН АЛЫНГАН ЭЛЕМЕНТЛАР КУЛЛАНЫП, УЕН ПРОЦЕССЫН ОЕШТЫРУ ТУРЫНДА МЕТОДОЛОГИК ЯЗМАЛАР

Уен гаять зур потенциалга ия уникаль мәдәни феномен булып тора. Ул баланы үз дөньясына алып кереп китә дә, интеллектуаль, физик яктан үстерә, өйрәтә, аңа социаль нормаларны сеңдерә. Уенның роле, әһәмияте турында, Платон һәм Аристотельдән башлап, бик күп акыл ияләре язып калдырган. Уеннарны укыту-тәрбия процессында инде күп гасырлар дәвамында кулланалар.

Укыту-тәрбия эшенең бер компоненты буларак, уен аерым бер максатларга хезмәт итә торган механизмга әверелгән. Алай булган очракта да, балалар өчен һәр уен үзенчә кызыклы. Мавыгып китеп, уен барышында күпме яңа белем туплый, күпме яңа тәэсирләр ала бит алар. Моңа уенның структуралы булуы да ярдәм итә.

Аның әлеге үзенчәлеген балаларга уен технологияләре ярдәмендә белем бирергә теләгән тәрбиячеләр һәрдаим истә тотарга тиеш. Ю. Левада фикеренчә: «Уен структурасы – эшчәнлекнең социомәдәни төре буларак абстракт уенны сурәтли торган идеаль-типик категория. Ул аерым уен төрләренә бәйләнмәгән, бу категория ярдәмендә төрле эшчәнлекнең уен аспектларын билгеләргә мөмкин»[10].

Чынлап та, уеннар гаять күптөрле, аларны гомуми бер эталон кысаларына кертергә тырышу уен төзелешенең түбәндәге өч компонентын аерып чыгарырга ярдәм итә: уен мөнәсәбәтләре урнаштырылу, уен мәйданы формалаштырылу, уен башлану – уен дөньясы барлыкка килү. Уйна-

---

[10] Левада Ю. А. Игровые структуры в системах социального действия // Системные исследования. 1984. С. 273.

учылар өчен әлеге этапларның һәрберсе мөһим, алар уен технологияләре кулланып, куелган максатларга ирешергә ярдәм итә.

Шунысын да истә тотарга кирәк: уенны башлау һәм тиешле уен мөнәсәбәтләре урнаштыру өчен уйныйсы килү теләге, күтәренке кәеф белән сугарылган аерым халәт булырга тиеш. Л. Т. Ретюнских язуына караганда, уен мөнәсәбәтләре – «субъектларның уен эшчәнлеген тормышка ашыруга юнәлдерелгән интерактив мөнәсәбәтләре»[11] ул. Уен мәйданчыгына кергән бала үзе дә сизмәстән реаль «мин»нән уендагы «мин»гә әверелә. Уендагы «мин» уен мәйданчыгындагы төп актерга әйләнә, уен кагыйдәләре буенча яши, үзенә бирелгән рольне башкара. Шушы уенда ул моңарчы белмәгәннәрен үзләштерә, фантазиягә бирелә, үз мөмкинлекләрен сынап карый, үзен күрсәтә. Шуларга бәйле рәвештә, бала шәхесе социаль рольләренең диапазонын киңәйтә, көчен сыный, хаталар ясый һәм ул хаталарын төзәтә дә. Алай гына түгел, теләгенә карап, бала уенда төрле рольләр уйный ала. Бу яктан караганда, уен баланың тәҗрибәсен арттыручы чыганак булып тора.

Уен мөнәсәбәтләрен формалаштыруда тәрбиясенең дә роле зур. Аның үз эшенә бирелгән, балаларны да артыннан ияртә алырдай шәхес булуы мөһим. Бу контекстта тәрбияче уенны барлыкка китерүче фигура булып тора.

Уен мөнәсәбәтләре формалашканнан соң, уен мәйданы формалаштырыла. Бу этапта балалар уен генераторлары (уенның эчтәлеге, чикләре, кагыйдәләре, андагы рольләр һәм уен предметлары), уенда кулланылачак әйберләр/символлар/уенчыклар белән таныша. Уен предметлары символик мәгънәгә ия, кайвакыт алар үзләре шартлы рәвештә алыштыра торган предметларга тәңгәл дә булмаска мөмкин.

---

[11] Ретюнских Л. Т. Философия игры. М.: Вузовская книга, 2002. С. 10.

Һәм ниһаять, соңгы этап – уен башлану. Аерым тәрбияви максатларга буйсындырылган мәгънәви кыр белән уенда кулланылган предметлар кыры бер-берсенә керешеп китү бу. Уенның ябык дөньясы үз тәртибе һәм үз рольләренә, пространство һәм вакытка, уен предметлары һәм мәгънәләренә ия. Алар уен барышында вариатив рәвештә үзгәрергә дә мөмкин.

Уен башлану – уйнаучыларның, уен предметларының үзара уртак уен хәрәкәтләренә, гамәлләренә керешеп китүе. Бу гамәлнең нигезендә уен мөнәсәбәтләре һәм уен генераторы ята. Уен генераторы уен торышын билгели. Уен операциональ (бөтен гамәлләр дә уйнала) һәм объектлы (уен кырында бары тик уен предметлары гына кулланыла) була ала. Уенның структурасы шундыйрак. Уенның спецификасын белгән очракта, интеллектуаль, эмоциональ, әхлакый, физик һәм башка максатлар куеп, аны һәр оештыручы җайлы гына белем-тәрбия бирү процессында куллана алыр.

Сезгә тәкъдим ителә торган татар халык уеннары антологиясе ярдәмендә, милли компонентны да исәпкә алып, тәрбиячеләр балаларны гаять кызыклы һәм файдалы уеннар дөньясына алып кереп китәчәк. Әлеге халык уеннары белән танышып, алар нигезендә балаларнең яшь һәм үсеш дәрәҗәсенә туры килерлек яңа уеннар да уйлап табарга мөмкин булыр.

Мәсәлән, «Табышмаклар» билгеле бер әдәби әсәргә, шәхескә, ел фасылына, бәйрәмгә һ.б.га багышланган тематик уен булырга мөмкин. Яисә ул бер үк хәрефкә башланган сүзләрне әйтүгә корыла ала. Шуның аркасында ул интеллектуаль яктан үстерешле уен булачак, танып-белү һәм тәрбияви әһәмияте дә артачак, бу аның диапазонын тагын да киңәйтәчәк.

Балаларда Ватанга мәхәббәт тәрбияләгәндә, аларны уен аша татар халкының танылган зыялылары белән акрынлап таныштыра барабыз. XIX гасыр мәгърифәтчесе Каюм На-

сыйрины һәм аның «Әбүгалисина кыйссасы»н (1872) да шулар исәбенә кертергә мөмкин. Бу әсәрне мәктәпкә әзерлек төркемендәге балаларга укырга тәкъдим итеlә. Төрле могҗизаларга бай булуы белән әсәр балаларны үзенә җәлеп итә: аларда сорау артыннан сорау туа һәм үзләре үк шуларга җавап эзли башлый.

Башта тәрбияче балаларны татар галиме Каюм Насыйри (1825–1902) шәхесе белән таныштыра, аның биографиясе белән Әбүгалисина/Авиценнаның (980–1037) тәрҗемәи хәле арасында уртаклыклар шактый. Икесе дә күп кенә фән тармакларында үзләрен күрсәткән галим булганнар. К. Насыйри фикеренчә, «фән кешенең зирәклегенә көч бирә», һәм «бу дөньяда бөтен нәрсәгә дә өйрәнергә мөмкин»[12]. Татар һәм Көнчыгыш акыл ияләренең тормышы авыр була. Еш кына аларның икесен дә каһәрлиләр. Аларның фәнни ачышларына дошманнарча ябырылалар[13]. Бүгенге көндә ике галим турында да мәгълүматлар бик аз сакланган: алар тормышының күп кенә эпизодлары миф һәм риваятьләргә әйләнгән, ә «легендарлыклары гыйбрәтле потенциалга ия»[14].

«Әбүгалисина кыйссасы»н укыганда, балаларның игътибарын әсәрнең уникаль булуына юнәлтергә кирәк: анда Әбүгалисина тормышындагы тарихи һәм легендар эпизодлар кисешә. Алар шәхеснең әхлакый йөзе турында сөйли[15]. Шуңа күрә һәрбер гыйбрәтле эпизодны укыганнан соң, аны

---

[12] Насыри К. Сказания о мудром Абу Али Сине, его брате Абу Али Харисе и невероятных приключениях, которые были с ними. Казань: Татарское книжное издательство, 1981. С. 69.

[13] Гильмутдинова С. Сквозь далекое время // Сказания о мудром Абу Али Сине, его брате Абу Али Харисе и невероятных приключениях, которые были с ними / К. Насыри. Казань: Татарское книжное издательство, 1981. С. 3.

[14] Яковлева Е. Л. Идеи о воспитании в педагогических и художественных трудах Каюма Насыри // Научное обозрение: гуманитарные исследования. 2017. № 4. С. 6–15. URL: https://www.elibrary.ru/item.asp?id=29932235

[15] Насыйри К. Әбүгалисина. URL: https://belgech.ru/proizvedeniya/abugalisina

балалар белән бергәләп аңларга һәм тормышның әхлакый кагыйдәләрен формалаштырырга киңәш итеңә. Тормышның Әбүгалисина һәм К. Насыйри өйрәтмәләре белән аваздаш мөһим компонентлары арасында, түбәндәгеләрне аерып күрсәтергә мөмкин:

– тормышны кызыклы, мавыктыргыч юл дип аңлау;

– тормышның ачык булуы, аның буенча ачык күңел, пакь теләкләр һәм изге ниятләр белән бару яхшырак[16];

– хезмәт итү теләге (кеше беркайчан да мәшәкатьләрсез һәм эшсез калырга тиеш түгел. Әгәр дә син тормыштан ләззәт алырга телисең икән, үз хезмәтең, белемең, фәнең белән яшә һәм хезмәт түгеп ирешелгәннәрне әрәм-шәрәм итеп бетермә[17]).

Шул ук вакытта кеше, бала вакытыннан башлап, гомере буе укырга тиеш, чөнки, К. Насыйри фикеренчә, балачакта алган белемнәр ташка төшерелгән бизәк сыман. Нечкә чыбыкны бөгүе җиңелрәк[18].

Өлкәннәрнең һәм акыллы кешеләрнең киңәшләренә колак салу сорала (олуг акыл иясен тыңламау – бу хәзинәне чүп савытына ташлауга, алтынны бакырга алыштыруга һәм чүлдә тере судан баш тартуга тиң[19]).

Кешеләр белән әхлак саклап аралашу, белгәнең белән уртаклашу, хезмәттәшлек итә белү зарур (акыллы белән дус булсаң, үзең дә акыллы, көчле белән дуслашсаң, үзең дә көчле булырсың[20]).

«Әбүгалисина кыйссасы»н балалар белән бергәләп җентекләп өйрәнеп чыкканнан соң, алдагы этапка – укылган әдәби әсәр нигезендә табышмакларның җавапларын табуга

---

[16] Гильмутдинова С. Сквозь далекое время // Сказания о мудром Абу Али Сине, его брате Абу Али Харисе и невероятных приключениях, которые были с ними / К. Насыри. Казань: Татарское книжное издательство, 1981. С. 69.

[17] Насыри К. Книга о воспитании. URL: http://kitap.net.ru/nasyri.php

[18] Шунда ук. 20 б.

[19] Насыри К. Книга о воспитании. С. 21. URL: http://kitap.net.ru/nasyri.php

[20] Шунда ук. 28 б.

күчәргә мөмкин. Балаларны кечкенә төркемнәргә берләштерә алабыз, бу аларны командада эшләргә һәм анда куелган проблемалар нигезендә үзара аралашырга өйрәтә.

«Табышмаклар» уены өчен әдәби нигез булып татар халык легендалары һәм әкиятләре, мәкальләре һәм әйтемнәре[21], Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Роберт Миңнуллинның балалар өчен язган шигырьләре хезмәт итә ала.

«Фикерләр җыючы» уенын балалар өчен актуаль темага яки проблемага багышларга, нәтиҗәдә аны, ораторлык сәнгате күнекмәләрен үзләштереп, дискуссиягә әйләндерергә мөмкин булачак. Мисалга тагын Каюм Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»на мөрәҗәгать итәргә була. Тексттан бер гыйбрәтле эпизодны сайлап алып, балалар тәрбияче биргән сораулар ярдәмендә хәл-вакыйганы тикшерәләр: ул хәзерге заманда да актуальлеген югалтмаганмы? Герой урынында булса, һәркем ничек һәм нәрсә эшләр иде? Вакыйгалар нинди вариантлар буенча үсәргә мөмкин?

«Фикерләр җыючы» уены өчен әдәби нигез итеп татар халык әкият һәм легендаларын, мәкаль һәм әйтемнәрен, Каюм Насыйриның «Тәрбия китабы»н, Габдулла Тукай, Муса Җәлил шигырьләрен тәкъдим итәргә мөмкин. Татарларның тормыш-көнкүреше һәм бәйрәмнәре турында мәгълүматны Казан инновация университетында А. В. Тимирясова һәм З. Ф. Гаязова редакциясендә чыккан «Сокровища татарской кухни»[22] китабыннан алыгыз.

«Пешми калган җыр» уены кечкенә төркемнәрдә, балаларның барысына да таныш көй астында уйнала. Музыкаль композицияне тыңлау белән бергә, композитор белән

---

[21] Татарское народное творчество. Т. 6: Пословицы и поговорки / под ред. Д. Э. Нигматуллиной. Казань: Татарское книжное издательство, 2017. 368 с.

[22] Сокровища татарской кухни / под ред. А. В. Тимирясовой, З. Ф. Гаязова. Казань: Изд-во «Познание» Казанского инновационного университета, 2020. 216 с.

дә таныштырабыз. Мәсәлән, Салих Сәйдәшев (1900–1954) – профессиональ дәрәҗәдә көй язу белән шөгыльләнгән тәүге композиторларның берсе. Ул гаиләдә унынчы бала булып дөньяга килгән. Ун бала арасынннан нәкъ менә Салих һәм аның апасы Әминә генә исән калган. Малайның музыкаль сәләте бик иртә ачылган, һәм ул 13 яшендә музыкант булarак «Сәйяр» труппасы белән чыгыш ясый башлаган. Бер үк вакытта Салих сәүдәгәр Халитов кибетендә эшләп акча тапкан. Композиторның тормышыннан бер кызыклы фактны китерик: ул музыкаль белемне композитор булып танылганнан соң гына алган. Балаларны Салих Сәйдәшев белән таныштырганнан соң, Казанда һәм Татарстан Республикасында аның белән бәйле истәлекле урыннарны (мәсәлән, Казанда аның музее, һәйкәле, аның исемендәге урам, концерт залы бар) искә төшерергә һәм күрсәтергә була.

Алдагы этап – Салих Сәйдәшев композицияләрен тыңлау һәм аларның берсен җыр язу өчен сайлап алу («Сандугач», «Хуш, авылым», «Кызыл Армия маршы» һ.б.). Уенның бер варианты: һәр төркем үз көен сайлый. Текстны язганда, уенда һәр катнашучы чират буенча аның бер юлын уйлый һәм үзенекен берәүгә дә күрсәтми (каплый). Нәтиҗәдә, иҗат процессында төркем текстны күрми, һәркем үзе уйлаганча яза. Уен һәр төркемнең үз вариантын башкаруы белән тәмамлана. Мондый алым күмәк эш күнекмәләренә өйрәтә.

«Пешми калган җыр» уенына татар халык җырларын (мәсәлән, «Сандугач», «Ал Зәйнәбем» һ.б.) һәм биюләрне (мәсәлән, татар халык биюе «Әпипә»), А. С. Ключаревның музыкаль композицияләрен (мәсәлән, Г. Зәйнашева сүзләренә язылган «Туган җирем Татарстан» җыры), Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетын (мәсәлән, сихерче һәм шайтан биюе, балалар биюе һ.б.), Н. Җиһанов композицияләрен (мәсәлән, татар темаларына сюита, «Алтынчәч» операсыннан бию һ.б.) әдәби нигез итәргә була.

«Дөньяда юк хайван» уенын «Дөньяда юк герой» дип үзгәртергә мөмкин. Бу очракта балалар яраткан әдәби әсәр / нәфис фильм / мультипликацион фильмны сайлап алырга һәм шундагы сөйкемле персонажны рәсемгә төшерергә тиеш. Сүз дә юк, һәр баланың үз сөйкемлесе булачак, һәм нәтиҗәдә, гомумән, бөтенләй таныш булмаган герой килеп чыгуы да бар. Әйтик, балалар белән бергәләп Г. Тукай әсәрләренә («Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык әкияте») мөрәҗәгать итеп була. Әлеге әсәрләрне кечкенәләр төркемендәге балалар да яхшы үзләштерә. Моннан тыш, тәрбияче соңыннан да елга бер тапкыр шул ук уенга әйләнеп кайта ала һәм мәктәпкә әзерлек төркемендә аңа нокта куя. Рәсемнәр нигезендә балаларның сәләтләре һәм командада эшләү күнекмәләре үсешен тикшерергә мөмкин.

«Дөньяда юк хайван» уенын оештырганда, татар халык әкиятләре һәм легендаларына, Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Муса Җәлил, Роберт Миңнуллин, Ренат Харис кебек шагыйрьләрнең балалар өчен язган шигырьләренә таянып эш итү сорала.

Сүзләр белән уеннар балаларның татар телен һәм мәдәниятен белү күнекмәләрен ныгытырга мөмкинлек бирә. Әлеге уен зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балаларына туры килә. Тәрбияче ярдәме белән Татарстан Республикасы мәдәниятенең тарихын өйрәнеп, «Бер хәрефкә сүзләр» уенында катнашучылар тема («Милли бәйрәмнәр», «Сабантуй», «Татар милли әдәбияты», «Татар халык әкиятләре», «Г. Тукай иҗаты» һ.б.) сайлыйлар, аннары билгеле бер вакыт дәвамында сүзләр язалар. Сүзләрне күбрәк искә төшергән һәм дөрес язган команда җиңеп чыга. Бу уенда сүзлек запасын киңәйтү, грамоталы язу һәм вазгыятькә тиз арада үз мөнәсәбәтеңне белдерү күнекмәсе ныгытыла.

Уеннарга безнең тарафтан тәкъдим ителә торган вариатив якын килү тәрбиячене уеннар тупланмасын киңәйтәчәк һәм

уен технологияләрен файдаланунының үз һөнәри алгоритмнарын эшләргә ярдәм итәчәк.

Нәтиҗә ясап, түбәндәге моментларны ассызыклап үтәбез. Бала өчен уен – вакыйгаларга һәм хис-кичерешләргә бай тормыш ул. Бала бөтен күңеле белән күптөрле уен эпизодларына кереп китә, бу исә нәниләр тормышын матурлый һәм хис белән баета, аның офыкларын киңәйтә һәм тәҗрибә тупларга ярдәм итә. Уен, шәхес чикләренең берсе буларак, homo ludens формалаштырырга булыша. Белем бирү-тәрбия процессында яхшы оештырылган балалар уены киләчәккә юнәлдерелгән нәтиҗәгә китерә: ул интеллектуаль, иҗади һәм физик сәләтләрне үстерә, хисләр палитрасын киңәйтә, процесста катнашуга этәрә, коллективизм һәм әхлаклылыкны аңларга ярдәм итә, кагыйдәләрне төшенү һәм үтәү күнекмәләре формалаштыра, максат куярга һәм аңа ирешергә, пунктуаль булырга, әйләнә-тирәдәге вакыйгаларга тиз арада үз мөнәсәбәтеңне белдереп, гамәлләрнең аларга адекват алгоритмнарын табарга өйрәтә, вазгыятькә рациональ якын килеп, импровизацияләү осталыгын үстерә. Санап үтелгәннәр уенны белем бирү-тәрбия процессының мавыктыргыч элементы итә, уен технологияләрен шактый күпкырлы һәм төрле максатларда кулланырга мөмкинлек бирә.

## ЭТНОПЕДАГОГИКАДА ФОЛЬКЛОР УЕННАРЫ ЧАГЫЛЫШЫ

Россия территориясендә дәүләтчелек барлыкка килгән вакытлардан ук йөздән артык төп халык яшәве уникаль факт булып тора һәм гамәлдәге мәдәниятләрнең һәм традицияләрнең гармонияле бәйләнешенең әһәмиятен билгели.

Ватаныбызның күпсанлы байлыклары турында сөйләгәндә, милли мәдәниятләрдә чагылыш тапкан рухи кыйммәтләр турында да онытмасак иде. Нәкъ менә мәдәни берәмлекләрне, аларның тирән эчтәлеген өйрәнү хәзерге буынга төп мәдәни кыйммәтләргә якынаерга мөмкинлек бирә, шуның белән беррәттән үсеп килүче буында толерантлык принципларын һәм мәдәниятләр диалогына омтылышны тәрбияләүгә юл ача. Әлеге бәйләнештә шунысы куанычлы: соңгы вакытта «халыкларның үз милли мәдәниятләрен торгызуга омтылышы, традицияләрне һәм тормышның рухи-әхлакый нигезләрен эзләве»[23] көчәя.

Мәдәни мирасны өйрәнү милләтләрнең социаль һәм мәдәни аерымлыкларына төшенү, шулай ук милләтнең тарихи мирасына сак караш тәрбияләү белән дә турыдан-туры бәйле.

Хәзерге вакытта педагогика фәне әхлакый тәрбия бирүдә нәтиҗәле алымнарга, шәхес формалаштыру чараларын булдыру максатыннан, халыкның тарихи-мәдәни хәтеренә кабат мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә, халык мәдәниятенең һәм халык педагогикасының мәңгелек кыйммәтләрен үз эченә алган күп гасырлык халык зирәклеге үрнәкләре сайлану – табигый.

---

[23] Волков Г. Н. Этнопедагогика. Чебоксары: Чувашкнигоиздат, 1974. С. 10.

Безнең фикеребезчә, этнопедагогика халык фикере һәм педагогик алымнар синтезының үзенә күрә бер квинтэссенциясе булып тора. «Халыкның тәрбияви традицияләре, – дип язды Г. Н. Волков, – фәнни аргументлар һәм дәлилләр белән түгел, ә гамәл, эш, эшчәнлек эзлеклелеге, тәрбияләнүчеләр психикасына тәэсир итү нәтиҗәләре һәм мең еллар дәвамында сайланып алына һәм шомартыла торган әзер фикерләр белән көчле»[24].

## Ритуал һәм халык уены

И. Т. Пархоменко һәм А. А. Радугин фикеренчә, «Традицион мәдәният – тотрыклы, динамик булмаган культура, аның үзенчәлеге шунда, анда үзгәрешләр артык акрын бара һәм шуңа күрә әлеге мәдәниятнең күмәк аңы тарафыннан теркәлми диярлек. Тарихта традицион мәдәният дип атальырга мөмкин булган һәм үзенчәлеге белән аерылып торган мәдәниятләр күп булды»[25]. Мәдәниятнең *традицион* сыйфатламасы, күп буыннар дәвамында аның тарафдарларының кешеләргә исән калуны һәм алга таба иминлекне тәэмин иткән гамәлләр башкаруы турында сөйли. Һичшиксез, динамикага һәртөрле омтылыш мәдәният тарафдарлары ягыннан нормадан тайпылу буларак кабул ителгән, димәк, аңсыз рәвештә киеренкелек, билгесезлектән курку хисе тудырган. Әмма, традицион мәдәниятнең динамик булмаган сыйфаты турында фикер йөртүгә карамастан, аның кысаларында әлеге традиция вәкилләренә алар өчен әһәмиятле булган үсү, шәхес буларак формалашу, билгеле бер җәмгыять кысаларында социаль рольләрне үзгәртү этапларын узарга мөмкинлек бирә

---

[24] Журавлев А. Ф. Славянская этнолингвистика в работах Н. И. Толстого (Предисловие редактора) // Язык и народная культура. Очерки по славянской мифологии и этнолингвистике. М.: Индрик, 1995. С. 7.

[25] Пархоменко И. Т. Культурология в вопросах и ответах. М.: Центр, 2001. С. 10–12.

торган тулы бер чаралар җыелмасы булдырылды һәм гамәлгә ашырылды.

Әһәмиятле вакыйгалар еш кына ритуаль гамәлләр белән үрелеп барды, бу җәмгыятьнең барлык әгъзаларына статусы үзгәрүне кабул итәргә һәм әлеге традициягә кушылырга ярдәм итте.

А. К. Байбурин фикеренчә, ритуал «үз-үзеңне тотуның символик формаларыннан санала; анда, традицион аң күзлегеннән караганда, һич тә шартлылык юк, ә хакыйкать, бердәнбер чынбарлык булган үзенчәлекле реальлек булдырыла. Ритуал әйберләрнең, гамәлләрнең, күренешләрнең гадәти тормышта күренмәгән, беленмәгән якларын ачкан кебек кабул ителсә дә, чынлыкта исә аларның асылын һәм билгеләнешен ачыклый. Шуннан чыгып, барлык күренешләрнең ике төрлелеге; көнкүрештә бертөрле булып, ритуалда башка төрле булу сәләте; көндәлек тормыш, мәшәкатьләр һәм гадәтилек дәрәҗәсеннән актуаль кыйммәтләр дәрәҗәсенә гаҗәеп күчешне тәэмин итә торган ике төрлелек ачыла»[26].

Ритуал үз структурасы буенча нинди дә булса тайпылышларга юл куймый торган төгәл схемадан гыйбарәт. Шулай да ул уен формасында гамәлгә ашырылырга мөмкин булган тайпылышны рөхсәт итә.

Ритуал, гореф-гадәт кебек үк, кешенең тормышта үз-үзен тотышын регламентлаштырса да, әлеге төшенчәләрне аера белү кирәк. Ритуал символик гадәтләр белән тыгыз бәйләнгән, димәк, кылына торган гамәлләрнең тирән мәгънәсен ача, яшәү рәвеше, дөньяны күзаллау хакында сөйли. Моннан чыгып, стереотиплык, стандартлаштыру таләпләре барлыкка килә, алар кеше психикасына турыдан-туры йогынты ясый.

Ритуал вакытлар узу белән үзенең бөтенлеген югалта һәм тышкы яктан нинди дә булса охшашлык күрсәтә, бердәмлеккә

---

[26] Байбурин А. К. Ритуал в традиционной культуре. СПб.: Наука, 1993. 240 с.

ишарә итә алмаган аерым элементларга таркалырга мөмкин. Әйтик, табышмак яки уен еш кына, әлбәттә, яшерен формада, нинди дә булса билгесез, куркыныч әйбергә мөрәҗәгать итү чарасы булып хезмәт итә ала иде. Бүгенге көндә дә без кәләшне «сатып алганда» заманча табышмаклар белән очрашабыз, ләкин җавап бирү кияүнең интеллектуаль сәләтен һәм язылмаган билгеле бер кагыйдәләрне белүен күрсәтү ысулларының берсе булуы турында уйламыйбыз.

Сабантуй уеннары да шундый үзенчәлеккә ия: башта физик җитезлеккә гади ярышлар булса да, символик күзлектән караганда, ярышларның күпчелеге хәрәкәткә нигезләнгән (ат чабышлары, йөгерү, көрәш). XIX гасырда Сабантуйда шаян ярышлар да барлыкка килә: капчык киеп йөгерү, шома баганага менү, салам тутырылган капчык белән сугышу, аркан тарту.

Һәм монда без уенның тагын бер мөһим компонентын – катнашучының физик һәм интеллектуаль яктан өлгергәнлеген күрсәтүен ачыклыйбыз.

Танылган тикшеренүче, этнограф Е. А. Покровский: «Сыйфаты буенча балалар уены организм эшчәнлегенең бер төрен тәшкил итә, ул – тулысынча диярлек җитди хезмәттән аерыла торган эшчәнлек, чөнки һәртөрле җитди хезмәт тормышның нинди дә булса практик бурычларын хәл итү максатыннан башкарыла, шул ук вакытта һәр уен, шул исәптән балалар уены да, алдан бернинди максат куймый, ул, киресенчә, үзе максаттан, гамәлдән, ләззәттән гыйбарәт. Моннан тыш, бу очракта уенда чагылыш тапкан эшчәнлек яшь организмга аеруча хас эчке, физик-психологик ихтыяҗлар һәм уй-ниятләр өчен махсус җайлаштырыла һәм тормышка ашырыла»[27].

Шул ук вакытта уен ритуалның охшатырга тырышу нәтиҗәсендә сакланып калган элементы булырга мөмкин.

[27] Покровский Е. А. Детские игры: преимущественно русские. М., 1897. С. 1–2.

Әлеге нәтиҗә Е. А. Покровский хезмәтендә ныклап исбатлана: «Уенның, охшатырга тырышу гына булып, борынгы йоладан килүе – гадәти күренеш... Балалар уеннарында җәя һәм уклар очраган һәр очракта без алар кайчандыр әлеге халыкның өлкән кешеләре тарафыннан кулланылган дигән нәтиҗәгә килә алабыз»[28].

Тикшеренүче әйткән нигезләмә халык уеннарының зур потенциалын, шул исәптән аның халык тарихы белән бәйләнешен, зур катлаулы берәмлекнең тарихи үсеш процессында югалган «бер кыйпылчык» буларак җитлекмәгәнлеген ачыклый: «... әлегә кадәр балалар уеннарында кулланыла торган үзенчәлекле законнар һәм кагыйдәләр, сөйләм формулалары, рифмалы сөйләшләр, әйтемнәр һәм җырлар, һичшиксез, берничә йөз ел элек кулланылышта һәм күп кенә балалар телендә, ә бәлки аларның кайбер өлешләрен генә безгә китереп җиткергән, юкка чыккан халыклар телендә булган. Шуңа да карамастан, киләсе буын балалары аша балалар уеннары кабатлана, яшь буын хәтерендә яңара һәм һәрвакыт яшәрә, чөнки балалар аларны яшь буынга өйрәтә»[29].

## Фольклор уены һәм аның психологик функциясе

Барлыкка килүе ягыннан шактый борынгы чорларга караган фольклор уены нәрсәгәдер өйрәтү, үгет-нәсыйхәт бирү кебек методик алымнарын турыдан-туры куллана алмаган билгеле. Ул очракта уйнаучылар (яшь буын) әлеге уеннарны кабул итә алмаган, ә олылар аларның кумулятив характерын сиздермәскә тырышкан булыр иде.

Әмма тарихи үсешенең бүгенге көн биеклегеннән чыгып, без тәэсир итү һәм төрле яшь төркемнәрен процесска кушу

[28] Шунда ук. 20–21 б.
[29] Шунда ук.

планында уеннарның кумулятив билгеләнеше һәм киң масштаблы булуы турында сөйли алабыз.

Алга таба уенның асылы һәм психологик функцияләре турында сөйләшербез. Уенның психологик функцияләрен без яшь психологиясе өлкәсендә булган мәгълүматлар ярдәмендә күрсәтербез.

Шулай итеп, төрле темаларга күпсанлы уеннарның булуы уенның «күпмаксатлы» берәмлек икәнлеген дәлилли.

Халык авыз иҗатында тематик төркемнәргә бүләргә мөмкин булган күпсанлы халык уеннары бар. Әмма һәрбер тематик төркем зуррак масштаблы бурычны – уенда катнашучыда теге яки бу вакыйгага реакциянең шомартылган механизмын формалаштыру бурычын хәл итәчәк. Белемнәрне буыннан буынга тапшыруның әлеге формасы үгет-нәсыйхәтнең аз булуы белән аерылып тора. Бу исә билгеле бер авторитар субъектның булмавы һәм шул ук вакытта әлеге ситуациягә кагылышлы әһәмиятле рольләрнең даими рәвештә башкарылып торуы белән бәйле.

«Уңыш бәйрәме» татар халык уенын мисалга китерик. Ул үзенең аталышы белән үсеп килүче буынга уңыш җыюның кыйммәтен генә түгел, билгеле бер тормыш чорын үткәрүнең әһәмиятен дә җиткерергә тиеш. Икенче яктан, кич утырулар авыл хуҗалыгы эшләрен, елның мөһим чорын тәмамлап, башкасына күчкәндә – кышка әзерләнгәндә уздырыла. Әлеге ритуаллык календарь ел дәвамында исәпнең мөһим ноктaларын билгели, вакыт агымындагы барлык этапларны да үтәү зарурлыгын искәртә.

«Кояш туу» турындагы белемнәрнең әһәмиятен күрсәтә торган «Нардуган» уены башкачарак төсмер ала. Уен үз тарихы белән ерак мәҗүсилек чорына барып тоташа, хәзерге вакытта ул онытылган һәм өлкән буын өчен этнографик чаралар оештырганда гына актуальләшә. Аны үткәргән вакытта катнашучыларның зур каршылыгы белән очрашасың, әмма хәзер, безнең карашка, заман кешесе өчен яшерен бул-

ган шактый күп мәгълүматны һәм регламентларны үз эченә алган дөньяның комплекслы тарихи сурәте үзгәреш кичерә.

Күренекле лингвист, этнограф А. Журавлевның да фикере аерым игътибарга лаек, ул халык авыз иҗатын өйрәнүгә генә түгел, аны реконструкцияләүгә һәм системалаштыруга да өстенлек бирә: «...бер яки тугандаш этник гореф-гадәт фактлары белән эш иткән реконструкция (башта эчке) һәм төрле этник материал белән чагыштырып башкарыла торган тышкы реконструкция халык мәдәнияте турындагы фәннең иң мөһим максатларыннан берсе булып тора»[30].

Нәкъ реконструкция һәм методик анализ этник традицияләрне торгызу хисабына хәзерге буынны тәрбияләүгә җитди йогынты ясарга сәләтле, кызганычка, ул үз тамырларыннан, үз тарихыннан шактый нык аерылган. Бу очракта уен балаларны һәм яшүсмерләрне уенның мәгънәсе, тормыш төзелеше, үзара мөнәсәбәтләр төзү кагыйдәләре турында уйланырга мәҗбүр иткән синтезлау чарасы була ала.

Мәсәлән, «Күз бәйләү» уены («Жмурки») кагыйдәләрен өйрәнгәндә түбәндәгеләрне укыйбыз: «Балалар бәйләнгән күзлеләрдән читләшә, чүгәли, дүрт аяклап йөри (әмма качарга яки бик еракка йөгерергә рөхсәт ителми). Әгәр күзләре бәйләнгән бала бәрелергә мөмкин булган берәр предметка якын килсә, аны „ут“ сүзе белән кисәтәләр»[31]. Әгәр без бу кагыйдәләрне игътибар белән укысак, үзебез өчен шактый күп әһәмиятле урыннарны табарбыз:

1. Уен үзең өчен һәм билгеле бер сәбәпләр аркасында мөмкинлекләре чикләнгән кеше өчен (сүз бәйләнгән күзләр турында бара) җаваплы булырга өйрәтә. Һәрнәрсәдә чама

---

[30] Латышина Д. И., Хайруллин Р. З. Этнопедагогика: учебник для академического бакалавриата. 2-е изд. М.: Юрайт, 2014. С. 9.

[31] Раз, два, три, четыре, пять. Русский игровой фольклор / сост.: М. Ю. Новицкая, Г. М. Науменко. М.: Просвещение, 1995. С. 94.

белү кирәклеге турындагы «Син уйна һәм уен белән бик мавыкма» дигән мәкальдә дә бу хәл ачык күренә.

2. «Ут» сүзе мәҗбүри үтәлергә тиешле кагыйдәләр җыелмасы турында сөйли. Кагыйдәләрнең үтәлеше бәйләнгән күзләрне үзгәрткәндә дә күренә.

Уен кысаларында барысы да бу кагыйдәләрне үти, чөнки ул уен нормасына туры килә. Һәм һәр балага үзен башкалар белән тәңгәлләштерергә мөмкинлек бирә.

Тәңгәлләштерү баланың үзидентификация процессын, аның үз-үзен тотышын җайга салу процессын тәшкил итә.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, беренче балалар уеннары бер зур (куркыныч) геройның һәм дошманнан качарга мәҗбүр булган күп кенә кечкенә катнашучыларның үзара каршылыгы аша булдырылган. Безнең фикеребезчә, әлеге каршылык, бер яктан, үз-үзеңне саклау, куркыныч барлыгы турында һәрвакыт истә тоту, куркыныч туганда тиз генә җавап бирү кирәклеге турында мәгълүмат һәм белемнәр бирә; икенче яктан, әлеге логика балаларга үзләрен бер-берсенә тиң итеп күрергә мөмкинлек бирә. Шулай итеп, бала куркыныч туганда үз-үзен тоту модельләрен формалаштыра (әлбәттә, әлеге уеннарда нинди дә булса кагыйдәләрне үтәү турында нигезләмә әлегә юк).

В. Ю. Хотинец язганча, «тәңгәллек барлыкка килү процессы бердәм тулылык булдыру максатыннан балалык еллары дәвамында берничә әһәмиятле идентификацияне гамәлгә кертү ярдәмендә үсеп килүче конфигурация буларак бара»[32]. Әлеге тезис Э. Эриксон тарафыннан бүлеп бирелгән тәңгәллек үсешенең сигез стадиясе белән бәйләнештә тора, аларның өчесе иртә балачак чорында теркәлә; арада иң әһәмиятлесе – дөньяга ныклы ышаныч хисе формалаштыру: «Балага мондый төрдәге мөнәсәбәт аша әниләр үз балаларында сабыйның шәхси ихтыяҗларына тәфсилләп җавап бирүне

---

[32] Хотинец В. Ю. Этническое самосознание. СПб.: Алетейя, 2000. С. 9.: ил., схем., табл. (Библиотека социальной психологии).

һәм аларның уртак тормыш стиленең үзара ышаныч контекстында үз-үзеңә ныклы инануны берләштергән ышаныч формалаштыра. Бу балада тәңгәллек хисләренең башлангыч нигезләрен барлыкка китерә, ул соңрак „барысы да тәртиптә“ дигән хис булып, син – ул син, син башкалар ышанган кеше булачаксың дигән хис булып урнаша»[33].

Әлеге фикерләр, тәңгәллек хисләре формалашу уенда, балалар куркыныч дошман белән очрашкач, бердәм булып чыгыш ясаганда да дәвам итә, дигән нәтиҗәгә китерә. Мондый уеннарда тигезлек хисе ныгый, чөнки аларның асылы катнашучылардан бердәм булуларын таләп итә һәм аларны чагыштыруны һәм кемнең дә булса өстенлеген раслауны күздә тотмый.

Моннан тыш, нәкъ «минем белән бар да яхшы» юнәлеше баланың үз-үзен адекват җайлавына һәм контрольдә тотуга ирешүенә китерә: «Бала үзенең сайлап алуга, нәрсәнедер булдыруга яки нәрсәдәндер арынуга хокуклы булганы өчен үз-үзенә һәм дөньяга ышанычы куркынычка дучар ителмәячәгенә инанырга тиеш. Баланың әйләнә-тирәсендәге чынбарлык аңа „үз аякларында басып торырга“ омтылуда ярдәм итәргә тиеш һәм шул ук вакытта аны оят дип атала торган мәгънәсез оят, җитлекмәгән үз-үзеңне фаш итү һәм икеләнү дип атала торган, икенчел һәм „арттырылган“ ышанычсызлык хисләре – беренче тапкыр барлыкка килә торган читләшүдән сакларга тиеш»[34].

Чыннан да, беренче балалар уеннары катнашучыларның кайсын да булса гаепләү, уенда аның тәртибен хупламау ихтималын тулысынча юкка чыгара. Бу урында рольләрне алмаштыру аша аермалар күрсәтелми. Шул рәвешчә, балалар «Төлке һәм тавыклар» («Лисички и курочки») уенын уйнаганда, төлке

[33] Эриксон Э. Идентичность: юность и кризис. М.: Прогресс, 1996. С. 173. Цитируется по: Хотинец В. Ю. Этническое самосознание. СПб.: Алетейя, 2000. 235 с.: ил., схем., табл. (Библиотека социальной психологии).

[34] Шунда ук. 119–120 б.

тоткан кеше «төлке»гә әверелә. Халык уеннары төзелешен анализлаганда аларның никадәр җентекле, хатасыз һәм дөрес оештырылуына гаҗәпләнәсең. Баланың мөмкин булган хаталарны башта ук аңлавы уенда барлык катнашучылар тарафыннан теркәлә, әмма нормадан тайпылу буларак сыйфатланмый: ул рольләрне алыштыру өчен сәбәп була. Вакыт узу белән еш кына рольләрне алмаштыру баланы үз гамәлләрен планлаштырганда (хәрәкәт траекториясен сайлаганда) игътибарлырак, җыйнаграк булырга өйрәтә. Әмма бу аңлау акрынлап, үз хаталарын катгый булмаган анализлау барышында килә һәм аңның билгеле бер трансформациясен булдыра.

Бу очракта иң әһәмиятлесе – уен аша баланың ата-анасы, туганнары һәм тагын да киңрәк – әйләнә-тирәдәгеләр белән үзенең бердәмлеген аңлау ярдәмендә тәңгәлләштерү функцияләрен тормышка ашыру. Әлеге аңлау балага тынычлык хисе бирә һәм үз-үзеңне җайлау һәм үз-үзеңне контрольдә тоту элементларын барлыкка китерә. «Уеннарда балага куелган бурычлар аның фикерләве өчен зур тәрбияви әһәмияткә ия һәм аның асылына бала белми торган уенкөлке һәм күңел ачу түгел, киресенчә, өйрәнүләрнең барлык үзлекләре һәм акыл хезмәтенең мәгънәсе салынган. Балалар уеннары – ул фикерләү мәктәбе, ә аларда чагыла торган иҗат һәм фантазия – фикерләү эволюциясенең төрле фазалары. Уеннарда төрлечә катнашу баланың акыл үсешендәге авырлыкларны шактый җиңеләйтергә мөмкин»[35].

Әйтелгән теоретик нигезләмәләргә иллюстрация буларак «Буш урын» уенына мөрәҗәгать итик. Кагыйдәләр буенча, барлык катнашучылар түгәрәк эченә баса һәм үз урыннарында әйләнә.

Алып баручы түгәрәкнең тышында йөри-йөри болай ди:

[35] Покровский Е. А. Детские игры: преимущественно русские. М., 1897. С. 30.

*Саескандай чыйкаклап,*
*Мин йөримен өй саклап,*
*Каздай булып кыйгаклап,*
*Сиңа тиям, син әбәк!*

Һәм кинәт кенә бер баланың аркасына суга да түгәрәк буенча йөгереп китә. Ә кемгә сукты, шул бала, урыныннан торып, аңа каршы яктан йөгерә башлый. Алданрак килеп җиткәне буш урынга баса. Урынсыз калганы алып баручы була, уен дәвам иттерелә.

Икенче мисал – «Габдулла, Гөлбану» уены. Балалар түгәрәкләнеп кулга-кул тотынып басалар. Санап, араларыннан бер кешене алып баручы итеп билгелиләр. Әгәр малай кала икән – Габдулла, кыз кала икән – Гөлбану була.

Түгәрәктәгеләр алып баручы күрсәткән хәрәкәтләрне кабатлыйлар.

Габдулла белән балалар диалогы:

Балалар: *Күрсәт әле, Габдулла, ничек бодай чәчәләр.*
Габдулла: *Менә шулай, менә шулай, шулай бодай чәчәләр.*
Балалар: *Күрсәт әле, Габдулла, ничек үлән чабалар.*
Габдулла: *Менә шулай, менә шулай, шулай үлән чабалар.*
Балалар: *Күрсәт әле, Габдулла, егетләр (кызлар) ничек бииләр?*
Габдулла: *Менә шулай, менә шулай, менә шулай бииләр.*

Уен бер үк вакытта берничә төрле эш-хәрәкәт башкарырга, бер-берсенә хөрмәт белән карарга, татар сүзләрен, исемнәрен истә калдырырга өйрәтә. Ул театральләштерелгән тамаша кебек кабул ителә, балаларның күңелен күтәрә, аларны физик яктан да, интеллектуаль яктан да үстерә.

Төрле хәрәкәтләр башкарыла, җырлап-биеп уйнала торган «Кунаклар» уенын да нәниләр бик яратып кабул итә.

Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар, бер бала уртага чыга. Кырыйдагы балалар түгәрәк буенча әйләнеп җырлыйлар:

*Ямьле бәйрәм көн иде,*
*Чакырдык без кунаклар;*
*Кунакларны сыйларга,*
*Салдык майлы коймаклар,*
*Чыж-пыж итеп коймаклар*
*Җәелде, әй җәелде.*

Шулай җырлаганнан соң, коймак җәелгәнне күрсәтеп, балалар кулларын як-якка җәяләр.

Үзләре баскан түгәрәкне кечерәйтеп, бераз кысылалар:

*Менә тагын кечкенә*
*Булып калды, җыелды.*

Кулларын югары күтәреп:

*Җыелды, әй җыелды,*
*Аннан ары кабарды.*

Чүгәләп:

*Кабарды, әй кабарды,*
*Шиңде, юп-юка калды.*

Баш ияләр:

*Пеште инде коймаклар,*
*Сыйландылар кунаклар.*
*Тордылар, баш иделәр,*
*Таралдылар, әй шатлар.*

Бииләр:

*Бииләр, ай-яй шатлар.*

Әлеге уенның тагын бер уңай һәм файдалы ягы: балалар җыр сүзләрен тиз истә калдыралар һәм бик яратып җырлыйлар. Бу аларның сүзлек байлыгын үстерә, татар җырлары белән кызыксынуларын арттыра.

## Үсеп килүче буынны тәрбияләү чарасы булараk халык уеннары

Югарыда әйтелгәнчә, халык уены ритуал, психологик формалашу белән тыгыз бәйләнгән. Моннан тыш, халык уенының тәрбияви потенциалы бик зур. Уеннар аша балалар бик күп нәрсә үзләштерәләр, бер-берсе белән мөгамәлә корырга, кешеләр арасында үзләрен дөрес тотарга өйрәнәләр: «...әгәр кешегә башкалар белән аралашу төрле яклап үсәргә, камилләшергә ярдәм итә, зиһенен үстерә, күңеленә рәхәтлек бирә, яшәртеп җибәрә икән, бала өчен шундый ук аралашуның никадәр файдалы һәм мөһим булуын күз алдына китерү авыр түгел, чөнки бала әйләнә-тирәсендәге үзе белән бертигез итеп күргән кешеләрдән күпме нәрсәгә өйрәнә ала бит»[36].

Тәрбияви потенциал турында сөйләгәндә, уенның билгеле бер мохит барлыкка китерүен һәм әлеге мохиттә катнашучыларның үзләрен төрле рольләрдә сынап каравын, үз бурычларын намус белән башкарырга өйрәнүен, һәрвакыт «алай итсәм дөрес булырмы – болай итсәмме?» дигән дилемма алдында калып, аны уңышлы гына чишәргә өйрәнүләрен аңларга тиешбез.

[36] Покровский Е. А. Детские игры: преимущественно русские. М., 1897. С. 35.

Тәрбия потенциалы бер куркыныч субъектны һәм бердәй дәрәҗәдәге катнашучылар төркемен үзара капма-каршы куйган уеннар аша тормышка ашырыла дип уйларга кирәкми. Биредә балачакның икенче чорына (7–12 яшьлекләргә) исәпләнгән, билгеле бер рольне башкару өчен катнашучыларга үз араларыннан берәр кешене сайларга кирәк булган уеннар турында сүз бара.

Мисал өчен, уенга «шобага салу» төшенчәсе кертелә. Шобага салып, уенның башлануын, тәмамлануын, шулай ук уенны (яки аның билгеле бер өлешен) алып баручыны, кагыйдәләрнең дөрес үтәлешен күзәтеп торучыны билгеләргә мөмкин. Җирәбә бу очракта катнашучылар арасында бәхәсләрне, кагыйдәләр үтәлмәгән моментларны булдырмый калырга ярдәм итә. Шобага салудан тыш, уенга җәза төшенчәсе кертелә, чөнки уен кагыйдәләрен бозу, аның шартларын үтәмәү очраклары булса, бу, һичшиксез, кисәтелергә тиеш.

Шобага салу санау ярдәмендә дә башкарылырга мөмкин. Этнографлар фикеренчә, элек катнашучылар ничә булса, шуның кадәр санарга кирәк булган һәм бу санаучыдан искиткеч зур игътибар таләп иткән. Тора-бара санау гадиләшә барган. Бүгенге көндә санамыш кайсы кешегә җиткәч әйтелеп бетә, шул кеше алып баручы һәм башкалар була. Мәсәлән:

*Бер тай, ике тай, өч тай, дүрт тай, биш тай, алты тай, җиде тай, сигез тай, тугыз тай, ун тай – чыгып тай!*

яисә

*Әлчи, бәлчи,*
*Әби күлмәк үлчи.*
*Үлчи торгач җитмәде,*
*Кисә торгач бетмәде.*
*Чәүкә, чыпчык,*
*Син кал, бу чык.*

Шобага салуда берничә бала катнашырга да мөмкин. Диалог рәвешендәге андый санамышлар балаларның игътибарлылыгын арттыра, хәтерен яхшырта. Мисал өчен:

*– Зәйни, Зәйни, Зәйнәбем,*
*Атны кая бәйләдең?*
*– Алмагачка бәйләдем.*
*Алма төште «шап» итеп,*
*Зәйнәп чыкты «ялт» итеп*[37].

Балаларга кызык булсын өчен, мондый әйтешләрнең күбесе төрле кошлар, хайваннар белән сөйләшүгә корылган:

*Аю, кая барасың?*
*Мин базарга барамын.*
*Син базарда нишлисең?*
*Тәмле прәннек аламын.*
*Тәмле прәннек беткән бит.*
*Әни мине уятмыйча,*
*Иртүк эшкә киткән бит*[38].

яисә

*Төлке, төлке, Төләмби,*
*Төнлә кая барасың?*
*Теләнергә барамын.*
*Теләнеп нәрсә аласың?*
*Бер кабымлык ит алам.*
*Ул ит белән нишлисең?*
*Тимер мичтә кыздырам.*

---

[37] Ягафаров Р. Ф. Татарский детский фольклор. Казань, 2007. С. 138.

[38] Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 268 б.

*Кулың пешсә нишләрсең?*
*Салкын суга тыгармын.*
*Агып китсәң нишләрсең?*
*Сикереп ярга чыгармын*[39].

Кайбер очракларда алдан сайлап алынган таякка кул куеп шобага салганнар. Җирәбә салуда кем җиңәчәген катнашучылар башта ук сөйләшеп куя торган булганнар. Командаларга тупланырга кирәк булган чакта, кайвакыт җитезлекләре, осталыклары буенча бер-берсенә туры килә торган балалар парлашып, үз исемнәре урынына уйлап чыгарылган исемнәр әйтеп, команда капитанына шул исемнәрнең берсен сайларга тәкъдим иткәннәр.

Димәк, шобага салулар уенның гадел баруын тәэмин иткән, билгеләнгән кагыйдәләрне үтәргә өйрәткән. Нәтиҗәдә, балалар үзләре үк барысын да контрольдә тоткан, теләсә нинди кагыйдә бозылу уйнаучыларда канәгатьсезлек хисе тудырган (бу аларның яшь үзенчәлекләренә һәм формалашып килә торган кыйммәтләренә дә бәйле). Һәм бу аңлашыла да, чөнки биредә уен баланың коллектив белән уйнарга өйрәнә торган тирәлеге, мохите ролен үти.

Җәза бирү теге яки бу төбәктәге кануннар нигезендә башкарылган. Мәсәлән, түбәндәге җәза төрләре кулланыла алган:

1) гаебе булганнарга берничә тапкыр туп ыргытканнар;

Әлеге җәзаны бирүчеләр үзләре дә гадел булырга тиеш:

«...гаеплене йөзе белән коймага каратып бастыралар. Ул уң кулы белән үзенең сул колагын тота, ягъни, шул рәвешле боҗра ясый, һәм шул боҗрага сул кулы белән астан туп ташлый. Уенчылар туп төшкән урынга барып басалар һәм шул урыннан барысы да бер-бер артлы гаепле баланың аркасына туп ыргыталар. Туп атучылар тупны һичшиксез тидерергә тиеш. Ә кем тидерә алмый, гаепле бала белән урыннарын

---

[39] Шунда ук. 267 б.

алмашалар да, ул бала шул ук ераклыктан аның үзенә туп ыргыта. (Нократ губернасы)»[40]. Безнең фикеребезчә, әлеге эпизод катнашучыларны уен кагыйдәләрен үтәргә генә түгел, ә гаеплеләрне кызганмаска да өйрәтә. Бу исә балаларга үз эш-гамәлләре өчен җаваплы булырга кирәклекне төшендерә, чөнки җәза бирүчеләр дә балалар үзләре;

2) гаебе булган бала билгеле бер араны йөгереп узарга тиеш булган;

3) гаебе булган бала башкаларны аркасына утыртып йөрткән;

4) гаебе булган баланың борыныннан тартканнар.

Вакытлар узу белән уен кагыйдәләре йомшара төшкән. Хәзер югарыда санап үтелгән җәза төрләре кулланыла торган җир бармы икән?! Җәза урынына күп вакыт шелтә генә белдерелә, бу, әлбәттә, кеше аңының эволюциясе, аның рухи үсеше турында сөйли.

Бүгенге заман тормыш шартлары күзлегеннән караганда, мөһим тәрбияви аспектларның берсе – балаларның хәрәкәт активлыгын арттыру. Бу исә уенның шартлары буенча үзеннән-үзе башкарылырга тиеш. Чөнки нәкъ менә хәрәкәт кеше организмының сәламәт булуын тәэмин итә, аңа көч һәм энергия бирә.

«Шуны онытмаска кирәк: организм никадәр яшь, хәрәкәтчәнлекне, сыгылмалылыкны тәэмин итә торган процесслар анда шуның кадәр тизрәк бара. Ә ул, үз чиратында, күбрәк хәрәкәтләнүне сорый. Менә ни өчен балалар өчен уеннар кечкенәдән үк аларны хәрәкәтләндерүгә кайтып кала»[41].

Хәрәкәтле уеннар баланың активлыгын балансга тотарга ярдәм итә: әкренләп үз әгъзаларының эшчәнлеге белән таныша бару баланы максатсыз рәвештә бертуктамый хәрәкәтләнеп торырга мәҗбүр итә. Ә уйнаган вакытта билгеле бер систе-

---

[40] Покровский Е. А. Детские игры: преимущественно русские. М., 1897. С. 61.
[41] Шунда ук. С. 94.

малы хәрәкәтләр баланың активлыгын арттыра. Мисал өчен, бала уенда еш кына куркыныч геройдан качып яисә башка уенчыларны эзләп, бер урыннан икенче урынга йөгерә.

«Соры бүре» уенын карап үтик.

Балаларның берсе «соры бүре» булып берәр җирдә посып утыра, башкалары урманга «җиләк җыярга» китә. Алып баручы балаларга сораулар бирә, балалар җавап кайтара:

*– Дуслар, кая барасыз?*
*– Кара урманга барабыз.*
*– Кара урманда нишлисез?*
*– Кура җиләк җыябыз.*
*– Җиләк белән нишлисез?*
*– Җиләктән как коябыз.*
*– Бүре килсә нишлисез?*
*– Урман буйлап чабабыз.*

Аннан соң күмәкләп җырлыйлар:

*Җиләк җыям, как коям,*
*Дәү әнигә бүләккә;*
*Монда җиләк күп икән,*
*Аю-бүре юк икән.*

Яшеренгән җиреннән сикереп чыга да, бүре аларны куа башлый. Кемне тота, шул бүре була.

Игътибар итсәк, әлеге татар халык уенында физик активлык мәҗбүри гамәл итеп түгел, ә үзенә күрә кызыклы бер момент буларак кабул ителә. Физик активлыкның халык уеннарына шулай оста кертеп җибәрелгән булуы фольклор уеннарының җитди потенциалын күрсәтә: балалар уенга бик теләп кушылалар һәм рәхәтләнеп актив хәрәкәт алып баралар, сикерәләр, йөгерәләр, бииләр һ.б.

Халык уенының гамәли һәм теоретик аспектлары – мәдәни, тарихи, психологик, педагогик нигезләре әлеге хәзинәнең баланың комплекслы, һәрьяклы үсеше өчен гаять әһәмиятле, кабатланмас һәм уникаль чыганак булуын күрсәтә.

Халык уенын синкретик мәдәни берәмлек буларак анализлау барышында без «халыкның борынгы мәдәни мирасын үзләштерү, аның белән кызыксыну уяту, фольклорга мөрәҗәгать итү шәхеснең рухи һәм әхлакый үсешенә йогынты ясый» дигән фикергә килдек»[42].

Халык уеннары белән таныша башлаганда ук балада үз милләтенең тарихына, мәдәниятенә кагылышлы сораулар туа, кызыксынуы арта. Халык уенының ритуал гамәлләр белән бәйләнеше проблематикасы булачак педагогларга җитди дисциплинаара тикшеренүләр өчен нигез булып тора.

Халык уеннарын психологик-педагогик аспектта тикшерү һәр халыкның мәдәният үзенчәлекләрен, рухи һәм матди кыйммәтләрен өйрәнүне, үз халкының гына түгел, башка халыкларның да мәдәниятенә, тарихына карата кызыксыну тәрбияләүне күз уңында тоткан халык педагогикасы, этнопедагогика үсешенең яңа офыкларын ача.

[42] Алдошина М. И. Организация школьных праздников. Фольклорные праздники: учебное пособие для вузов. М.: Юрайт, 2022. С. 5.

# ТӘРБИЯЧЕНЕҢ УЕННАР ХӘЗИНӘСЕНӘ:
## уеннар оештыру өчен идеяләр

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә эшләүче тәрбиячеләр игътибарына Татарстан Республикасы мәдәнияте тарихыннан хрестоматия рәвешендә кечкенә фрагментлар тәкъдим итәбез. Уен сценариена кертеп җибәреп яисә биремнәр чыганагы буларак файдаланып, аларны балалар өчен каралган күптөрле уеннарда кулланырга мөмкин. Мәгълүмат сайлауда һәм аларны уен процессына кертүдә тәрбиячеләргә тулы ирек бирелә.

Балаларның яшь үзенчәлекләренә, кызыксынуларына һ.б.га карап, төрле-төрле биремнәр уйлап табарга була. Мисал өчен, фант уеннарындагы биремнәр нигезенә татар халкының төп характерлы билгеләре салына һәм балалар аларны үзләренең күзәтүләреннән чыгып искә төшерергә тиеш. Бу аларның әти-әниләренең, әби-бабаларының, танышларының холык-фигылендәге, үз-үзен тотышындагы һәм башка сыйфатлар. Бер уенчы әлеге сыйфатларны кул хәрәкәтләре, мимика, эмоцияләр ярдәмендә күрсәтә, ә башка балалар аның нәрсә икәнен әйтеп бирергә тырыша. Әйтик, «татар йөреше»нең үзенчәлеген билгеләргә кушылса, аны марш атлап яисә кыю, ныклы адымнар белән йөреп күрсәтеп булыр иде һ.б.
















Татарстан Республикасы һәм Казан символлары арасында **Казан кремле, Ак барс** (җөмһүриятебездә яшәүче халыкларны саклаучы ак барс), **Зилант** (Кабан күлендә яшәп, Сөембикә ханбикә хәзинәләрен саклаучы мифик елан), **Казан мәчесе Алабрыс**, **чәкчәк**, **казан** (Казанның килеп чыгуы турындагы бер риваять буенча, астына ут төртмичә дә казандагы су кайнап чыга торган урын эзләгәннәр).






**Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»** поэмасы кулъязма рәвешендә XIX гасырга кадәр халык арасында йөргән. Ул хәтта татар кызлары бирнәсендәге мөһим атрибутларның берсе саналган.

# ТАТАР РӘССАМНАРЫ

Татар рәсем сәнгате үсешенә зур өлеш керткән күренекле рәссамнар турында кыскача мәгълүмат.



**Урманче Бакый Идрис улы** (1897–1990) – РСФСРның һәм ТАССРның халык рәссамы, скульптор, фотограф.

Әти-әнисе Бакыйда кечкенәдән үк рәсем ясауга, хезмәткә, кул эшләренә мәхәббәт тәрбияли. Рәсем ясарга өйрәнү теләге белән ул 10 яшендә үк Казанга килә. Тик ул вакытта әле татарлар өчен сәнгать мәктәбе ишекләре ябык була, Бакый укуын мәдрәсәдә дәвам итә. Соңрак аңа төрле шәһәрләрдә шахтер, эшче, укытучы булып эшләргә туры килә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында Урта Азиядә хезмәт итә. 1918 елда Глазов сәнгать студиясендә беренче рәсем дәресләрен ала.

1941–1956 елларда Казакстанда фән һәм мәдәният эшлеклеләренең портретлар галереясын төзи. Шулай ук бу чорда ул скульптура белән мавыга, аның иң яхшы үрнәкләрен Татарстанга кайткач ясый.

Аеруча танылу алган түбәндәге картиналарын атарга мөмкин: «Ак эшләпәле татар», «Бану», «Габдулла Тукай һәм Фатыйх Әмирхан», «Лия Заһидуллина портреты», «Ибн Фазланның Болгарга килүе» һ.б.



**Фәттахов Лотфулла Әбделмән улы** (1918–1981) – РСФСРның халык рәссамы, график.

Лотфулла кечкенәдән рәсем ясарга, шигырьләр, хикәяләр язарга ярата. 13 яшендә Казанга укырга килә һәм сыйныфташы Х. А. Якупов (соңыннан ул танылган рәссам булып китә) гаиләсендә яши. Алар Казан

сәнгать училищесына да бергә укырга керәләр, тик тәмамлый алмыйлар – сугыш башлана.

Бөек Ватан сугышында аларның часте немецлар тарафыннан камап алына, Лотфулла Линген концлагерена эләгә. Берничә тапкыр омтылыш ясаганнан соң, Франциягә кача һәм Каршылык хәрәкәтенә кушыла.

Лотфулла Фәттахов сугыш вакытында да рәсем ясавын туктатмый. Ә сугыштан соң җиң сызганып картиналар язу эшенә керешә.

Әйтергә кирәк, Лотфулланың тормышы авыр була, ул бик иртә әти-әнисен югалтып, ятимлек ачысын татый. Аңа рәсем ясарга яратуы һәм ачык, җиңел холкы ярдәм иткәндер. Холкының бу сыйфатларын ул гомер буе саклый.

Рәссамның гомере бик озын булмый, ул 1981 елда бакыйлыкка күчә. Әмма Лотфулла Фәттахов картиналарының бәйрәмчә рухы әле бүгенгә кадәр халыкның күңелен күтәреп, рухын баетып тора.

Танылган хезмәтләре: «Сабантуй», «Яшьлек» картиналары, әкиятләргә иллюстрацияләр һ.б.



**Якупов Харис Габдрахман улы** (1919–2010) – РСФСРның, СССРның халык рәссамы.

Х. Г. Якупов Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1948–1951 елларда Казан сынлы сәнгать училищесында укыта. 1976–2007 елларда Россия сәнгать академиясенең Казандагы иҗат остаханәсен җитәкли.

Тарихи картиналар, портретлар, пейзажлар («Хөкем алдыннан», «Ирекккә очу», «Бәби туе», «Чаллы сылулары», «Иделдә яз», «Татарстан алтыны», «Габдулла Тукайга истәлек», «Көчле кешеләр» һ.б.) авторы.



**Зарипов Илдар Касыйм улы** (1939–2012) – Россия Федерациясенең халык рәссамы, Рус музеенда (Санкт-Петербург) һәм Третьяков галереясында (Мәскәү) хезмәтләре булган Татарстаннан бердәнбер рәссам.

Рәссам Казанны бик ярата. Шәһәрнең һәрвакыт матур һәм яшел булуын теләп, агачлар утырту, шәһәр киңлекләрен яшелләндерү белән шөгыльләнә.

«Гәп куертканда», «Өйдә», «Сугыш икмәге», «Нефтьче Әхәт абый», «Казан чибәре Зөлфия», «Батыр», «Кырлай көйләре» кебек искиткеч жанрлы картиналар аның иҗат җимешләре. Аеруча «Әни», «Сөембикә», «Бәйрәм», «Батыр», «Алтын башак» һәм башка картиналарын аерып күрсәтергә мөмкин.



**Сәйфетдинов Әнвәр Камил улы** (1963) – Татарстан рәссамы.

1974–1978 елларда Казанның Пионерлар сарае һәм балалар сәнгать мәктәбендә, аннан соң Казан сәнгать училищесында, В. И. Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтында белем ала.

1994–1995 елларда Россия сәнгать академиясенең иҗат остаханәсендә «Әнвәр Әлифбасы»н иҗат итә. Әлеге китапны Әнвәр Сәйфетдинов 18 ел яза: өлкән улы беренче сыйныфка кергәндә башлаган була, төпчек улы мәктәпкә кергәч тәмамлый.

Әнвәр Сәйфетдинов Татарстан Республикасының Зур концерт залы түшәмен милли стильдә бизәүгә (1996 ел) зур өлеш кертә. «Намаз», «Кәләш», «Татар кәләше» һәм башка хезмәтләр – аның иҗат җимеше.

# ТАТАР КОМПОЗИТОРЛАРЫ

Татар мәдәниятен бөек әсәрләр белән баеткан талантлы композиторларга кыскача күзәтү.



**Яруллин Фәрит Заһидулла улы** (1913–1943) – татар композиторы.

Ф. Яруллин татар музыка сәнгате тарихына милли балетка нигез салучы буларак килеп керә. Ул иҗат иткән беренче татар балеты – «Шүрәле» (Г. Тукай әкияте буенча) 1945 елда Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә куела. Тик Фәрит Яруллин балет куелышын күрә алмый, 1943 елның октябрендә Бөек Ватан сугышында геройларча һәлак була.

1958 елда аңа (үлгәннән соң) «Шүрәле» балеты өчен Г. Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе бирелә.



**Бакиров Әнвәр Закир улы** (1920–2001) – композитор.

Әнвәр Бакировның иҗади эшчәнлеге 1937 елда язылган «Иртәнге серенада» җыры белән башлана. Аннан соң ул үз иҗат гомерендә чын-чынлап халык җырлары саналырлык ике йөздән артык җыр яза.

Композиторның иҗади эшчәнлеге күпкырлы. Аның иң зур әсәрләреннән берсе – Г. Тукай әкияте мотивлары буенча әзерләнгән «Алтын тарак» балеты. Яңа редакциясендә «Су анасы» дип аталган әлеге әсәр музыкаль образларның байлыгы белән аерылып тора.



**Җиһанов Нәҗип Гаяз улы** (1911–1988) – күренекле татар композиторы, педагог.

Нәҗип Җиһанов Казан консерваториясен һәм аның каршындагы махсус урта музыка мәктәбен, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрын, Дәүләт симфония оркестрын оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе була. Татарстанда профессиональ музыкаль белем бирү системасын формалаштыруда да Н. Җиһановның роле зур. Композитор 8 опера, 3 балет, 17 эре симфоник әсәр, сюиталар, җырлар, күпсанлы камера, вокаль һәм инструменталь әсәрләр авторы.



**Сәйдәшев Салих Җамалетдин улы** (1900–1954) – татар композиторы, татар профессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе.

Салих Сәйдәшев иң элек гармунда уйнарга өйрәнә. Соңрак аңа рояль сатып алалар.

Ул уеннарны да үзе уйлап чыгара: биш яшендә үк мич капкачына агач кашык белән суккалап, үзенчә көйләп, балаларны биетә.

Салих Сәйдәшевне фортепианода уйнарга икетуган сеңлесе Мәрьям Рафикова өйрәтә. Аның өйрәтү ысулы да уникаль була: «...кечкенә Салихның бармакларын үз бармакларыма бәйләп куям. Аннары итәгемә утыртам да аның белән бергәләп әкрен генә берәр җыр уйный башлыйбыз. Минем бармакларым белән бергә аның бармаклары да клавишаларга баса, көйнең тактына һәм темпына иярә. Бер үк көйне күп тапкырлар кабатлагач, ул үзе дә шул клавишаларга баса башлый һәм уйнарга тиз өйрәнә иде»[43].

---

[43] URL: https://vk.com/wall-37132547_3456

8 яшендә үзен сәүдә эшенә тарта башлагач, сату эшен яратмаган Салих якыннарына болай диярргә мәҗбүр була: «Мине кибеткә кума әле, әни. Бармыйм мин анда. Минем кулларыма музыкант кагылды бит. Ә кемнең кулларына музыкант кагыла, ул кеше һичшиксез музыкант булачак. Мин дә музыкант булам!»[44]

Салих Сәйдәшев апаларында яши. Апасының ире Шиһаб Әхмәров татар зыялыларының бер вәкиле була. Аларга кунакка килеп йөри торган Габдулла Тукай да Салихның уйнавын тыңларга ярата. Киткәндә ул, сокланып: «Шәп уйный бит, каһәр! Музыкант булыр!» дия торган булган.

Габдулла Тукайның мәдәни миссиясен символик рәвештә Салих Сәйдәшев кабул иткән дигән сүзләр дә йөри. Сәйдәшевнең гармунына чахотка белән авыручы Габдулла Тукайның каны эләккән була. Якыннары моны аерым бер билге итеп кабул итә һәм Салихның язмышы да татар шагыйренең язмышы кебек, бер үк вакытта авыр да, уңышлы да булачак дип уйлый. Шулай булып чыга да.

Салих Сәйдәшевнең иң танылган әсәре булып «Кызыл Армия маршы» санала: ул «Татарстан» (Казан – Мәскәү) поездын озатып кала.



**Мозаффаров Мансур Әхмәт улы** (1902–1966) – татар композиторы, педагог.

Мансур Мозаффаров «Галиябану», «Зөлхәбирә» операларын язган. Бу опералар халык җырлары мотивлары нигезендә иҗат ителгән. «Галиябану»ның премьерасы 1940 елда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында була.

---

[44] Шунда ук.



**Монасыйпов Алмаз Закир улы** (1925–2008) – композитор, дирижер.

Ул Казан музыка мәктәбендә, училищеда һәм консерваториядә виолончельдә уйнарга өйрәнә.

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнаша.

Иң танылган әсәрләре: «Муса Җәлил» (аның музыкасына 1971 елда «Үлмәс җыр» балеты куела), «Бәйрәм бүген!» һәм «Идел-йорт», «Салих Сәйдәшевкә музыкаль бүләк» симфония-поэмалары һ.б.



**Садыйкова Сара Гариф кызы** (1906–1986) – татарның беренче хатын-кыз композиторы, актриса һәм җырчы. Таланты өчен аны «татар сандугачы» дип йөрткәннәр. Мәскәү сәнгать академия театрының юбилеендә чыгыш ясаганда аңа танылган режиссер К. С. Станиславский алкышлый.

Сара Садыйкова Фатиха Аитованың данлыклы кызлар гимназиясендә белем ала. Аны тәмамлагач, Казан педагогика техникумында, П. И. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясендә укый.

400 гә якын җыр, 18 спектакльгә музыка, «Мәхәббәт җыры» һәм «Кияүләр» музыкаль комедияләрен яза.



**Гобәйдуллина София Әсгать кызы** (1931) – композитор, РСФСРның, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Дөньяда иң танылган татар композиторларының берсе.

Ул Чистайда туган, Казан консерваториясендә фортепианода уйнарга өйрәнгән, шунда үзенең беренче әсәрләрен яза башлаган.

София Гобәйдуллинаны авангард композиторлар исәбенә кертәләр. Аның музыкасы стилистик һәм авторлык оригинальлеге, жанр киңлеге белән аерылып тора.

Германиядә яши.

Йөздән артык симфоник әсәр, солистлар, хор һәм оркестр, инструменталь ансамбльләр, театр, кино һәм мультфильмнар өчен музыка авторы.

## ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Әлеге исемлектә татар әдәбиятының кайбер классиклары китерелә.



Үзенең кыска гына гомере эчендә **Тукай** (1886–1913) халык алдында очраклы рәвештә бер тапкыр гына чыгыш ясый. Бер журналист белән әңгәмәсендә ул шаяртып кына халык иҗаты турында лекция темасын кузгата. Тик әлеге шаяру җитди кабул ителә: журналист газетада белдерү бастыра һәм Габдулла Тукайга лекция язып авыл клубында чыгыш ясарга туры килә.

27 яшендә вафат булган Габдулла Тукай үз иҗат җимешләре белән генә түгел, А. С. Пушкин, И. А. Крылов, А. В. Кольцов һ.б.ның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итүе белән дә танылa.

Балаларга «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән сарык» әкиятләрен, «Сабыйга», «Эш беткәч уйнарга ярый», «Бала белән күбәләк» һәм башка шигырьләрен уку кызык булачак.



**Муса Җәлил (Җәлилов Муса Мостафа улы)** (1906–1944) – бөек татар шагыйре, публицист, оста оештыручы.

Җәлил узган гасырның 30 нчы елларында татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләренең берсе була.


Муса Җәлилнең беренче иҗат җимешләре сакланмаган. Тугыз-ун яшьләрендә үк яза башлаган булса да, «Бәхет» исемле беренче шигырен ул 1919 елда гына бастыра.

Казанда опера һәм балет театры ачылгач, әлеге зур сәхнәдә куяр өчен Муса Җәлил татар телендә либретто яза.

Яшерен эшчәнлеге һәм хәрби әсирләрнең күпләп качуларын оештыруы өчен кулга алына. Җәза вакыты җиткәнче аңа Мобит төрмәсенең бер кешелек камерасында утырырга туры килә. Ул газета кырыйларыннан өч кечкенә блокнот тегә һәм сорау алулар, җәзалаулар туктап торган арада шунда 125 шигырь язып калдыра. Өченче блокнотның язмышы әлегә кадәр билгеле түгел.

Муса Җәлилнең төрмәдә язган шигырьләре шагыйрь Константин Симоновка килеп эләгә. Аның ярдәме белән Муса Җәлил барлык ялган шикләнүләрдән азат ителә һәм 1956 елда шагыйрьгә «Советлар Союзы герое» дигән мактаулы исем бирелә.

Җәлилнең балалар өчен язылган шигырьләре: «Ишек төбендә», «Батыр егет турында җыр», «Кызыл ромашка» һ.б.




**Миңнуллин Роберт Мөгаллим улы** (1948–2020) шагыйрь, журналист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе.

Шигырьләрне балачакта ук яза башлый.

Роберт Миңнуллин үзен беренче чиратта балалар шагыйре дип саный, үсеп килүче буынның таләпләрен аңлап, балачакның матур хатирәләрен үтемле итеп тасвирлый. Бик күп шигырьләре юмористик формада язылган.

Балалар өчен китаплары: «Акбай цирк карый» (1978), «Айга очтык!» (1982), рус телендә «Глядит в окошко человек» (1986), «Дөньядагы иң зур алма» (1992), «Көчтәнәч» (1995), «Балачакка ешрак кайтыгыз» (2002), «Сөенсеннәр әле сабыйлар» (2002), «Әни, мин көчек күрдем» (2008) һ.б.



**Абдулла Алиш (Алишев Габдуллаҗан Габделбари улы)** (1908–1944) – татар шагыйре, язучы; балалар өчен шигырьләр, драма әсәрләре җыентыклары авторы.

1939 елда Муса Җәлил аның турында болай дип яза: «Язучы А. Алишның әсәрләре җиңел тел белән язылуы һәм мәгънәле булуы белән аерылып тора. Аның мәктәп укучылары алдында да абруе зур».

Бөек Ватан сугышында ул Муса Җәлил белән бер концлагерьга эләгә. Фашистларга каршы яшерен оешмада катнашкан А.Алиш башка җәлилчеләр белән бергә 1944 елның 25 августында җәзалап үтерелә.

«Отряд флагы» дигән беренче җыентыгы 1931 елда басылып чыга. «Якты күл буе» повесте, «Дулкыннар» исемле хикәяләр җыентыгы, «Илгиз белән икебез», «Минем абый» исемле шигырь җыентыклары А. Алишны балалар язучысы итеп таныта.

А. Алишның әсирлектә язган шигырьләре, рус теленә тәрҗемә ителеп, «Три поэта-воина» җыентыгына кертелә.



**Ренат Харис (Харисов Ренат Мәгъсүм улы)** (01.04.1941) – шагыйрь, әдәбият тәнкыйтьчесе, драматург, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе.

Ренат Харис Дәүләт флагын, Дәүләт гербын, Дәүләт гимнын булдыру буенча ТР Конституция комиссиясенең эшче төркемен җитәкли, Бөтендөнья татар конгрессы, Ф. И. Шаляпин исемендәге опера фестивале идеясе һәм концепциясе авторы.

Ренат Харисның балалар өчен язылган китаплары: «Матур өй», «Лап-лап», «Әбәк» һ.б. Әлеге җыентыклар хикәяләүнең гадилеге, төслелек, ачык образлылык белән балаларны бик тиз үзенә җәлеп итә.

Аның пьесалары буенча Казандагы Яшь тамашачылар театрында «Умырзая» (2008), «Илдус һәм Windows» (2011), Казан курчак театрында «Серле алан» (2011), «Абай-бабай аланы» (2011), «Кәкрүшкә» (2012) спектакльләре куела һ.б.

Р. Харисның «Шигырь язган каләм белән...» (1998) исемле китап-альбомда тәкъдим ителгән графикалары да аерым игътибарга лаек.

Күпкырлы шәхес үзен тәрҗемәче буларак та таныта. А. Пушкин, М. Лермонтов, Ф. Тютчев, С. Есенин, М. Цветаева, А. Ахматова, Р. Гамзатов һ.б.ның әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

## ФӘН ҺӘМ СӘНГАТЬ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ



**Фукс Карл Федорович** (1776–1846), чыгышы белән немец. Казанны һәм аның халкын бик яхшы белгән. К. Фуксны Казан татарларының көнкүрешен һәм мәдәниятен беренче булып өйрәнүче дип саныйлар. «Казан шәһәренең кыскача тарихы» («Краткая история города Казани», 1817) һәм «Казан татарлары статистик һәм этнографик нисбәттән» («Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях»; 1844) китаплары күпьеллык тикшеренүләренең нәтиҗәсе булып тора. Ул Казанны үзенең икенче ватаны дип саный.

Карл Фукс рус, гарәп һәм татар телләрен камил белә. Ул Казан университетының беренче укытучыларыннан санала, соңрак ректор була.

Казан журналистикасына нигез сала. 1811 елдан аның катнашында беренче җирле «Казанские известия» газетасы бастырыла башлый.

Карл Фуксны татарларның туй йоласына – никахка чакырулы беренче европалы дип саныйлар (мөселман гаиләләре өчен никах ябык тантаналардан санала һәм анда үз кешеләр генә чакырыла).



**Каюм Насыйри (Насыйри Габделкаюм Габделнасыйр углы)** (1825–1902) астрономия, география, математика, тарих, филология һәм башка бик күп фәнни юнәлешләр буенча хезмәтләр калдыра. Күпкырлы эшчәнлеге өчен еш кына аны татарның Леонардо да Винчие дип йөртәләр.

Фәнни эшчәнлегеннән тыш, Каюм Насыйри музыка коралларында уйный, күптөрле халык һөнәрләренә ия була (тегү һәм реставрацияләү, агачтан җиһазлар ясау һ.б.).

Атаклы мәгърифәтче китапларын тулысынча үзе төзи: текстларын яза, иллюстрацияләрен ясый, хәтта зур булмаган тиражда үзе чыгара да. Мөгаллимлек эшчәнлеге белән шөгыльләнә. Үз вакыты өчен шактый алдынгы карашлы кеше булса да, замандашлары аның идеяләрен кабул итәргә әзер булмый, Каюм Насыйриның таланты тиешенчә бәяләнми.

К. Насыйриның фәнни хезмәтләренең күбесе татар халкы тарихын, Россия һәм гомумхалык тарихын өйрәнүгә багышлана. «Казан татарларының ышанулары һәм гореф-гадәтләре» исемле хезмәте аеруча әһәмиятлеләрдән санала. К. Насыйри җитәкчелегендә 1871–1897 елларда «Казан календаре» басылып чыга. Календарьларга хас мәгълүматтан тыш, анда күп кенә фәнни һәм әдәби материал да бирелә.



**Шаляпин Фёдор Иванович** (1873–1938) – дөньякүләм танылу алган җырчы, Республиканың беренче халык артисты (1918); Казанда туган.

Федор Шаляпин 1890 елга кадәр Казанда яши: чиркәү хорларында җырлый, опера, драма һәм оперетта труппаларында статист һәм хор җырчысы була. 1922 елдан чит илдә яши, дөньяның төп опера сәхнәләрендә һәм зур концерт залларында чыгышлар ясый.

Казанда ел саен Ф. И. Шаляпин исемендәге опера фестивале уздырыла.

Төп опера партияләре: Фауст («Фауст» әсәре буенча, Ш. Гуно), Мефистофель («Мефистофель» әсәре буенча, А. Бойто), Сусанин, Руслан («Патша өчен яшәү», «Руслан һәм Людмила», М. Глинка), Иоанн Грозный, Варяг кунагы («Псковитянка», «Садко», Н. Римский-Корсаков) һ.б.



**Шварц Евгений Львович** (1896–1958) – рус язучысы, драматург, сценарист, «Югалган вакыт турында әкиятләр» («Сказки о потерянном времени») авторы; Казанда туган.

Иң танылган әсәрләре: «Иске балалайка хикәясе» («Рассказ старой балалайки»), «Петрушка белән Стёпка-растрёпка сугышы» («Война Петрушки и Стёпки-растрёпки»), «Лагерь» («Лагерь»), «Шариклар» («Шарики») һ.б.

# ГЛОССАРИЙ

**АВТОДИДАКТИКА** (грек теленнән *autos* «үзем» һәм *didasko* «өйрәнәм») – «үзлегеңнән өйрәнү» (Словарь иностранных слов, вошедших в состав русского языка. – Чудинов А. Н., 1910). «Мәктәпкәчә педагогикада уеннарда, уенчыкларларда, әсбапларда автодидактика элементлары булу баланың үзенә, өлкәннәр ярдәменнән башка, биремне дөрес үтәү юлларын табарга ярдәм итә»[45].

**БАЛА ИНИЦИАТИВАСЫ** – «баланың олылар әйтүе буенча түгел, ә үзе берәр нәрсә эшләргә теләп, шуны тормышка ашыру юлларын табарга тырышуында чагыла. Инициативалы гамәл баладан максатчанлык һәм үз эшен ахырына кадәр җиткерүне таләп итә. Шунысын да онытмыйк: мәктәпкәчә яшьтәге балалар импульсив, аларга башка кешеләрнең мәнфәгатьләрен исәпкә алу һәм кагыйдәләргә буйсыну авыр бирелә. Шуңа да еш кына алар үзләрен бик иркен тота һәм өлкәннәр әйткәнне тыңламый. Әмма бу инициатива чагылышы дигән сүз түгел әле. Кеше (кечкенә яки зур) үз ниятен тормышка ашыру өчен нәрсәдер эшли һәм аны эшләү барышында ситуацияне үзгәртә – нидер ясый, яңа кагыйдәләр кертә, үз уенын тәкъдим итә һ.б. икән, шул вакытта гына инициатива турында сөйләшергә мөмкин. Инициативаны үстерү өчен, мөстәкыйльлекне үстергәндәге кебек үк, баланың көнлек режимы аңа үз теләге буенча да нәрсәдер эшләргә вакыт калырлык, ә әйләнә-тирә мохите яңа идеяләр туу, материаллар белән экспериментлар ясау өчен киң мөмкинлекләр бирерлек булырга тиеш»[46].

---

[45] От рождения до школы. Инновационная программа дошкольного образования / под ред. Н. Е. Вераксы, Т. С. Комаровой, Э. М. Дорофеевой. Изд. 5-е (инновационное), испр. и доп. М.: Мозаика-Синтез, 2019. С. 311.

[46] Шунда ук.

**«БАЛА ТАВЫШЫ»** – «кече яшьтәге балаларны тәрбияләү һәм укыту проблемаларына багышланган заманча фәнни хезмәтләрдә кулланыла торган термин. Ул педагоглар алдына баланың шәхси кызыксынуларын, ихтыяҗларын (бала үз теләкләрен сүз белән белдерә алмаган очракта да) аңлау һәм аларны гамәлгә ашыру өчен мөмкинлекләр бирү бурычы куйганда кулланыла. «Бала тавышы»н ишетә белү баланың эмоциональ халәтенә, аның мөстәкыйльлек, иҗат, инициатива чагылышларына игътибарлы һәм ихтирамлы булу, аның шәхси пространствосы, үз фикере, карары, сайлау хокукы булуын тануны аңлата»[47].

**ДИДАКТИК УЕННАР** – «өйрәтү максаты белән махсус ясалган яки җайлаштырылган уеннар. Дидактик уенның үзенчәлеге шунда: шартлы уен планы уку-укыту, тәрбия юнәлеше (алдан планлаштырылу, максаты һәм ирешелергә тиешле нәтиҗәсе булу) белән үрелеп бара. Кагыйдә буларак, дидактик уеннар вакыт ягыннан чикләнгән, уен гамәлләре билгеле бер кагыйдәләргә буйсынган. Дидактик уен кысаларында уку-укыту максатларына уен бурычларын хәл итү аша ирешелә»[48].

**ИРЕКЛЕ УЕН** – «балаларның үзләренә материал сайларга, сюжет уйлап табарга, рольләр бүлешергә, партнерлар сайларга, бер сүз белән әйткәндә, нәрсә һәм кем белән уйнауларын мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә мөмкинлек бирә торган «күз алдына китерелгән» ситуация булдыру. Ирекле уенда олылар да катнаша ала, әмма уйнаучы буларак кына. Үз идеяләрен һәм кагыйдәләрен тәкъдим итеп,

[47] Шунда ук. 313 б.
[48] Бим-Бад Б. М. Педагогический энциклопедический словарь. М., 2002. С. 71.

алар һич кенә дә балаларга үзләренчә уйнарга комачауларга тиеш түгел.

Балалар тарафыннан уенга кабул ителгән олы кешенең роле – кирәк очракта сиздермичә генә сюжетка яңа борылыш биреп, уенны баетып җибәрү, балалар белмәгән мәгълүматны әйтеп кую, берни белмәгән, аңламаган кыяфәт чыгару (балалар ярдәм итәргә, аңлатырга, хәленә керергә, үзләрен зурларча тотарга тырышачак)»[49].

**КАГЫЙДӘЛЕ УЕННАР** – «балалар өчен олылар уйлап тапкан уеннар. Аларга хәрәкәтле, интеллектуаль, музыкаль (ритмик, әйлән-бәйлән, биюле), коррекцион, шаян (күңел ача торган) уеннар, спорт һәм йола уеннары керә. Кагыйдәле уеннар арасында буыннан-буынга килә торган халык уеннары зур бер төркемне тәшкил итә»[50].

**ПРЕДМЕТЛЫ ҮСЕШ МОХИТЕ** – «мәктәпкәчә яшьтәге балаларның һәр яшь этабы үзенчәлекләрен, булган очракта, үсешләрендәге кайбер тоткарлыкларны, кимчелекләрне коррекцияләүне, сәламәтлекләрен саклау һәм ныгытуны исәпкә алып, шуларның барысына да туры килерлек әсбаплар, җиһазлар һәм инвентарь белән тәэмин ителгән махсус мәйданнан (биналар, кабинетлар һ.б.) гыйбарәт укыту, тәрбия бирү тирәлегенең бер өлеше»[51].

---

[49] От рождения до школы. Инновационная программа дошкольного образования / под ред. Н. Е. Вераксы, Т. С. Комаровой, Э. М. Дорофеевой. Изд. 5-е (инновационное), испр. и доп. М.: Мозаика-Синтез, 2019. С. 324.

[50] Дошкольная педагогика с основами методик воспитания и обучения: учебник для вузов. Стандарт третьего поколения / под ред. Ф. Г. Гогоберидзе, О. В. Солнцевой. СПб.: Питер, 2014. С. 250, 251.

[51] Об образовании в Российской Федерации: Федералоьный закон РФ от 29 декабря 2012 г. № 273.

**РЕЖИССЕР УЕННАРЫ** – «аларда сюжет уйлап табу һәм аны үстерү уенчыкларны төрле рольләрдә «уйнату» ярдәмендә башкарыла. Мондый уенда бала төрле уенчык персонажлар исеменнән сөйләшә, аларны уен мәйданында йөртә, кая баруларын, нәрсә эшләүләрен һ.б.ны аңлата»[52].

**СЮЖЕТЛЫ-РОЛЬЛЕ УЕННАР** – «үзенә билгеле бер роль алып, баланың мөстәкыйль рәвештә сюжет уйлап табуына һәм әлеге сюжетны үстерүенә корылган уеннар»[53].

**ТЕАТРАЛЬЛӘШТЕРЕЛГӘН УЕННАР** – «әлеге уеннарда балалар тамашачыларга спектакль күрсәтүче актерлар позициясендә. Спектакльнең сценариен уйлауда, декорацияләр ясауда һәм костюмнар, афишалар, чакыру билетлары бизәүдә дә балалар үзләре катнаша»[54].

**ТӨП ЭШЧӘНЛЕК** [билгеле бер үсеш өчен] – «шәхес үсешенең хәзерге этабында кеше психологиясенә хас төп билгеләр барлыкка килүгә һәм формалашуга йогынты ясый торган эшчәнлек»[55].

**УЕН** – «шартлы ситуацияләрдә төрле предметларны дөрес итеп һәм урынлы куллану буенча җәмәгатьчелек тәҗрибәсен өйрәнүгә, кабул итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек төре. Җәмәгатьчелек тәҗрибәсенең гасырлар

---

[52] Дошкольная педагогика с основами методик воспитания и обучения: учебник для вузов. Стандарт третьего поколения / под ред. Ф. Г. Гогоберидзе, О. В. Солнцевой. СПб.: Питер, 2014. С. 250.

[53] Дошкольная педагогика с основами методик воспитания и обучения: учебник для вузов. Стандарт третьего поколения / под ред. Ф. Г. Гогоберидзе, О. В. Солнцевой. СПб.: Питер, 2014. С. 250.

[54] Шунда ук.

[55] Бим-Бад Б. М. Педагогический энциклопедический словарь. М., 2002. С. 32.

буе формалашкан бер төре буларак, уен кешеләр тормышы һәм эшчәнлеге нормаларын үз эченә ала, аларга буйсыну предметлы һәм социаль чынбарлыкны танып белергә һәм үзләштерергә, интеллектуаль, эмоциональ һәм әхлакый яктан үсәргә ярдәм итә»[56].

**УЕН МОХИТЕН ИРЕКЛЕ КУЛЛАНУ МӨМКИНЛЕГЕ** – «балаларның уеннарны, уенчыкларны һәм материалларны үзләре алып куллану мөмкинлеге булу. Бу уенчыкларны мөстәкыйль рәвештә алып куллану өчен баланың физик мөмкинлеге һәм шулай ук әлеге уенчыклар белән уйнар өчен вакыты җитәрлек булуны аңлата. Кече мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен материаллар ачык киштәләрдә булган очракта гына «ирекле куллануда» санала ала. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның зурлар төркемендәгеләр өчен кайбер материалларның ябык контейнерларда яки шкафларда булуы рөхсәт ителә, әмма уен өчен кирәкле предметлар үзләре мөстәкыйль рәвештә алырлык булырга тиеш»[57].

**УЕНЧЫК** – «баланың күңелен ачу өчен билгеләнгән һәм бер үк вакытта аның психик үсеше өчен иң мөһим чараларның берсе булып хезмәт итә торган предметлар»[58].

**ҮСЕШ АМПЛИФИКАЦИЯСЕ** (грек теленнән *amplificatio* «арттыру», «тарату») – «үзләренә туры килә торган шөгыльләрнең күптөрле булуы, шулай ук яшьтәшләре һәм олылар белән аралашу нәтиҗәсендә, баланың шәхес буларак үсешен мөмкин кадәр баету. Амплификация ясал-

---

[56] Шунда ук. 98 б.
[57] Бим-Бад Б. М. Педагогический энциклопедический словарь. М., 2002. С. 314.
[58] Шунда ук. 99 б.

ма акселерациягә, ягъни бала үсешен мәҗбүри рәвештә тизләтүгә каршы куела.

Амплификация концепциясенең теоретик нигезе булып бала үсешендәге һәр баскычның уникаль һәм үзенчәлекле булуын, кечкенә чагында кичергән барлык хис-тойгыларның аның психологиясенә, шәхси үсешенә искиткеч зур йогынты ясаячагын тану тора» (А. В. Запорожец).

**ҮСЕШНЕҢ СЕНЗИТИВ ЧОРЫ** – «психик функцияләр үсешенең һәм эшчәнлек формаларының чикләрен билгеләп, үстерелешле уку-укыту өчен иң нәтиҗәле вакытны ачыкларга ярдәм итә.

Л. С. Выготский фикеренчә, сензитив чорда ниндидер шартлар (мәсәлән, укыту) үсешнең билгеле бер цикллары тәмамланганчы гына нәтиҗәле була ала. Үсеш тәмамланган икән, әлеге шартларга карата сензитив чор да тәмамланган дигән сүз: «Үсешнең аерым бер процесслары тәмамланмаган булу әлеге чорның билгеле бер шартларга карата сензитив булуы өчен мөһим шарт булып тора». Иң якын үсеш зонасы ноктасыннан караганда, сензитив чорлар баланың материалның эчтәлеген кабул итүгә әзерлеген билгели һәм нәкъ менә әлеге яшь стадиясендә олылар белән үзара «хезмәттәшлегенең» нәтиҗәле формаларын табарга ярдәм итә[59].

[59] Шунда ук. 325–342 б.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Алдошина, М. И. Организация школьных праздников. Фольклорные праздники : учебное пособие для вузов / М. И. Алдошина. – Москва : Юрайт, 2022. – 130 с.

2. Байбурин, А. К. Ритуал в традиционной культуре / А. К. Байбурин. –Санкт-Петербург : Наука, 1993. – 240 с.

3. Бим-Бад, Б. М. Педагогический энциклопедический словарь / Б. М. Бим-Бад. – Москва, 2002.

4. Волков, Г. Н. Этнопедагогика / Г. Н. Волков. – Чебоксары : Чувашкнигоиздат, 1974.

5. Гильмутдинова, С. Сквозь далекое время // Сказания о мудром Абу Али Сине, его брате Абу Али Харисе и невероятных приключениях, которые были с ними / К. Насыри. – Казань : Татарское книжное издательство, 1981.

6. Дошкольная педагогика с основами методик воспитания и обучения : учебник для вузов. Стандарт третьего поколения / под ред. Ф. Г. Гогоберидзе, О. В. Солнцевой. – Санкт-Петербург : Питер, 2014. – 464 с.

7. Журавлев, А. Ф. Славянская этнолингвистика в работах Н. И. Толстого (Предисловие редактора) / А. Ф. Журавлев // Язык и народная культура. Очерки по славянской мифологии и этнолингвистике. – Москва : Индрик, 1995. – 512 с.

8. Исәнбәт, Н. Балалар дөньясы / Н. Исәнбәт. – Казан : Татар. кит. нәшр., 1970. – 216 б.

9. Исәнбәт, Н. Балалар фольклоры / Н. Исәнбәт. – Казан : Татгосиздат, 1941. – 188 б.

10. Латышина, Д. И. Этнопедагогика : учебник для академического бакалавриата / Д. И. Латышина, Р. З. Хайруллин. – 2-е изд. – Москва : Юрайт, 2014. – 532 с.

11. Левада, Ю. А. Игровые структуры в системах социального действия // Системные исследования. – Москва, 1984. – С. 273.

12. Насыйри, К. Әбүгалисина. – URL : https://belgech.ru/proizvedeniya/abugalisina (мөрәҗәгать итү вакыты: 14.06.2022).

13. Насыри, К. Сказания о мудром Абу Али Сине, его брате Абу Али Харисе и невероятных приключениях, которые были с ними. – Казань : Татарское книжное издательство, 1981.

14. Насыри, К. Книга о воспитании. – URL : http://kitap.net.ru/nasyri.php

15. От рождения до школы. Инновационная программа дошкольного образования / под ред. Н. Е. Вераксы, Т. С. Комаровой, Э. М. Дорофеевой. – 5-е изд. (инновационное), испр. и доп. – Москва : Мозаика-Синтез, 2019. 336 с.

16. Пархоменко, И. Т. Культурология в вопросах и ответах / И. Т. Пархоменко. – Москва : Центр, 2001. – 334 с.

17. Покровский, Е. А. Детские игры: преимущественно русские / Е. А. Покровский. – Москва, 1897.

18. Приказ Минобрнауки России от 17.10.2013 № 1155 (с послед. изм.) «Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования» (Зарегистрировано в Минюсте России 14.11.2013 № 30384) // Российская газета. – 2013. – № 265. – 25 нояб.

19. Раз, два, три, четыре, пять. Русский игровой фольклор / сост. М. Ю. Новицкая, Г. М. Науменко. – Москва : Просвещение, 1995. – 224 с.

20. Развивающие детские игры татар: по страницам журналов начала XX века / под ред. А. В. Тимирясовой. – Казань : Казанский инновационный университет, 2017. – 148 с. (Серия «Сокровищница Татарстана»).

21. Ретюнских, Л. Т. Философия игры / Л. Т. Ретюнских. – Москва : Вузовская книга, 2002.

22. Сокровища татарской кухни / под ред. А. В. Тимирясовой, З. Ф. Гаязова. – Казань : Изд-во «Познание» Казанского инновационного университета, 2020. – 216 с.

23. Татарское народное творчество. Т. 6: Пословицы и поговорки / под ред. Д. Э. Нигматуллиной. – Казань : Татарское книжное издательство, 2017. – 368 с.

24. Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 334 б.

25. Федеральный закон РФ от 29 декабря 2012 г. № 273 «Об образовании в Российской Федерации». URL : http://www.consultant.ru/document/cons_doc_LAW_140174/ (мөрәҗәгать итү вакыты: 14.06.2022).

26. Хотинец, В. Ю. Этническое самосознание / В. Ю. Хотинец. – Санкт-Петербург : Алетейя, 2000. – 235 с. : ил., схем., табл. (Библиотека социальной психологии).

27. Эльконин, Д. Психология игры / Д. Эльконин. – Москва : Владос, 1999. – 360 с.

28. Эриксон, Э. Идентичность: юность и кризис / Э. Эриксон. – Москва : Прогресс, 1996. – 334 с.

29. Ягафаров, Р. Ф. Татарский детский фольклор / Р. Ф. Ягафаров. – Казань, 2007. – 172 с.

30. Ягъфәров, Р. Ф. Уен – күңел бәйрәме: Татар халкының уен фольклоры / Р. Ф. Ягъфәров. – Казан : Мәгариф, 2009. – 159 б.

31. Яковлева, Е. Л. Идеи о воспитании в педагогических и художественных трудах Каюма Насыри // Научное обозрение: гуманитарные исследования. – 2017. – № 4. – С. 6–15.

32. URL : https://vk.com/wall-37132547_3456__ (мөрәҗәгать итү вакыты: 14.06.2022).

# ПРЕДМЕТЛАР КҮРСӘТКЕЧЕ


Арт белән узыш 28, 90, 93
Аю янында кара урманда 11, 60, 69, 71, 72
Бар, юк 50, 58
Безнең капка төбендә 14, 71
Белмәсәң, үзең җырларсың 43, 59, 97
Бер аяк белән көрәш 28, 55, 83, 90
Бер-береңә әйбер тапшыру 22, 56, 71, 90, 95
Бер хәрефкә сүзләр 51, 105
Буш урын 27, 55, 90, 92, 93, 95, 116
Бүре 36, 60, 81
Дөньяда юк хайван 32, 96, 105
Җиләк-җимеш базары 48, 58, 76, 77, 96
Җир, су, һава һәм ут 49, 58
Җитез бул 23, 55, 83, 90, 94, 95
Игезәк иҗекләр 45, 46, 96
Ишкән баулар 19, 56, 90, 93, 95
Йонлач көчек 13, 60, 66, 67, 69, 71
Йөзек табу 27, 56, 90, 92, 95
Карга 26, 60, 90, 91, 95
Качыш-табыш 40, 79, 83
Ком – со – мол 42
Коткаручы таяк 23, 55, 83, 90, 95
Кызылармиячеләр 19, 55, 71, 73, 88, 89
Куык 13, 55, 65, 69, 71
Куян 29, 60, 65
Куянны тот 22, 55, 66, 71, 73
Көлдерүче 79
Күз бәйләү 71, 90, 95, 113
Күп мәгънәле сүзләр 45, 46, 96
Маэмай почмакта 36, 60, 71, 72
Музыканы нык тыңла 42, 59, 85, 97
Мәрьям әби малайлары 15, 55, 84
Ни өчен һәм шуның өчен (чөнки) 31, 96
Нык уйла 40, 74
Оча 47, 58, 76, 77, 96
Очучылар 18, 55, 71, 88, 89, 90, 95
Почмаклар 34, 55, 82, 90, 94, 95
Пешми калган җыр 54, 103, 104
Рәсемдә нәрсә сурәтләнгәнне бел 39, 76, 96
Табышмаклар 39, 58, 96, 100, 103
Тавышсыз музыка 31, 59, 85, 97
Тиз уйла 43, 58
Тот, тот 20, 55, 71, 83, 90
Туп яшереш 55, 90, 95
Төзәгечкә тидер 90, 95
Узышчылар 55, 83, 90, 95
Фант уены 32, 79
Фантлар 30, 96
Фикерләр җыючы 51, 103
Хайваннар авызыннан 35
Хикәя 53, 58, 96
Шаян казлар 16, 55, 71
Шулай, әйе һәм юк 48, 58
Эзләр буйлап 24, 58
Эндәшмә 30, 58
Ярты сүз 52, 58
Яңача мәче һәм тычкан уены 37, 60, 71, 72, 81
Әтәч кычкырды 34, 60, 90, 92, 95
Өзлексез 49, 58
Өч сүз 47, 58, 96

*Уку-укыту басмасы*

«Татарстан хәзинәләре» сериясе

# ТАТАР ХАЛЫК УЕННАРЫ

*XX гасырның беренче яртысы татар халык уеннары җыентыгы*
*һәм әлеге уеннарны уйнату өчен методик ярдәмлек*

А. И. Скоробогатова, Р. Ф. Гатауллина, В. В. Тертычная,
Д. О. Хәбибуллина, Д. М. Козина, Е. Л. Яковлева, Р. Р. Ханмурзина

А. В. Тимирясова редакциясендә

Нәшриятның баш мөхәррире *Г. Я. Дарчинова*
Мөхәррир: *Э. И. Сафина*
Техник мөхәррире: *С. А. Кәримова*
Корректорлар: *Э. И. Сафина*
*Л. Г. Шәрифуллина, Г. А. Тарасова*

Иллюстрацияләр, тышлык бизәлеше: *Г. И. Загретдинова*

ISBN 978-5-8399-0763-8

Басарга кул куелды 03.08.2022. Формат 60×84/16
Гарнитура PT Astra Serif, 12. Уч.-изд. л. 8,8
Тиражы 1000 данә. Заказ № 68

CERTIFIED IQNet MANAGEMENT SYSTEM

ЗНАК ИНФОРМАЦИОННОЙ ПРОДУКЦИИ 6+ ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ЗАКОН № 436-ФЗ ОТ 29.12.2010

В. Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университетының «Познание» нәшрияты
420111, Казан шәһ., Московская ур., 42
Тел. (843) 231-92-90; e-mail: zaharova@ieml.ru

Әзер оригинал-макеттан «ТЦО «Тәгълимат» ҖЧҖ типографиясендә бастырылды
420108, Казан, Зайцев урамы, 17 йорт